КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

# Мәдәни Җомга

№8
8 сентябрь
1995 ел

1995 елның июленнән
башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы

## БҮГЕНГЕ САНДА:

**2** *Рафаэль ХӘКИМ.*
Ничәмә-ничә еллар дәвамында үзен «чын демократ» дип атаган бәндәбез тоталитар алымнар яклы булып чыкты.

**5** *Лена ШАГЫЙРЬҖАН.*
Ә нишә соң хәтта изге Китап — Коръәндә дә шагыйрь сүрәсе бар?

**8** *Әхәт ГАФФАР.*
«Кәгъбә бодае» — арзан ит, май, сөт, йомырка. иң яхшы цен кәр ул.

**10** *Коящ ТИМЬИКОВА.*
Телдән телгә, күцелдән күцелгә күчә килгән халык җырларында бөтен тарихыбыз чагыла.

**14** *Рабит БАТУЛЛА.*
Тукай киләчәк буыннар өчен Алып батырдай биек-калку булып күренер, чөнки Ул — үз иҗаты белән Алып, үз шигыре белән каһарман.

**17** *Фәнис ЖИҺАНША.*
Милләтебезнең йөзек кашы булган «Шүрәле» балетын бар яктан да камил итеп сәхнәгә мең тергезәләр, бу хезмәт ошбу труппаны дөньяга ныграк танытыр иде.

**18** *Равил ГАЙНЕТДИН.*
Ислам дине әдәп-әхлакның сафлыгына, мәдәниятнең үсешенә, җәмгыятьнең гаделлек белән яшәвенә, тормышның нигезе дөрес булуга ярдәм итә.



*Идел-йортның җан авазы*
*Күчкән гармун теленә...*

## МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

Кадерле дуслар! Әти-әниләреннән, кардәш-ыруыннан еракта яшәүчеләр! Язып салыйк әле якыннарыбызга сәлам хаты, мөмкин булса, телефоннан шалтыратып алыйк. Алар безнең исәнлек хәбәребезне, җылы сүзебезне көтәләр. Зарыктырмыйк.

Мансуров / Зиннур МАНСУРОВ /

## МИН ӘЙТТЕМ

**Рафаэль ХӘКИМ,**
Татарстан Президентының дәүләт киңәшчесе

# Казан белән Мәскәү арасы...

Казан белән Мәскәү арасындагы мөнәсәбәтләр һәрвакыт көндәшлек төсендә булды. Хәер, бу хәл инде бик борынгы заманнардан ук килә. Һәм Русия йә тоталитарлыкка кайтуны, йә демократиялəштерүне дәвам итүне сайларга тиеш булган бу тарихи көннәрдә Казан белән Мәскәү арасында бәхәс бара. Шулай туры килде инде — Мәскәү Грозныйны штурмлаганда Татарстан башлангычы белән Гаагада бер төркем элекке совет дәүләтләренең тынычлык акциясе үткәрелде. «Гаага башлангычы» дәүләт төзелеш проблемаларын хәрби юл белән хәл итүгә альтернатива булу белән генә түгел, Татарстанның беренче җитди тышкы сәяси акциясе буларак та әһәмияткә ия. Хәзер Казан дөнья аренасына халыкара башлангычлар субъекты буларак чыкты.

Русиянең перспективалары нинди һәм яңа сәяси хәлдә Татарстанны нәрсә көтә?

16 февральдә без Борис Ельцинның ел да Федераль Җыенда укыла торган нотыгын тыңладык. Ул сәяси һәм икътисади кризис көчәйгән вакытта яңгырады. Илнең үзендә дә, чит илләрдә дә зур киеренкелек белән Русиянең кай тарафка юл тотачагын көттеләр. Һәм бу юлы да Б.Ельцин үзенең демократик курс яклы булуын белдергән иде кебек, әмма бу аңа җиңел генә бирелмәде.

Ичкерия илне үз йогынтысы астына алырга омтылган «сугыш партиясе» өчен көч сынау урыны булды. Форсат уңайлы иде — халыкның тормыш дәрәҗәсе түбәнәя, җитештерүчәнлек кими, эшсезлек арта бара, шуның белән бергә демократик реформаларга карата да канәгатьсезлек хисе үсә. Әмма реванш барып чыкмады.

Империяне торгызырга тырышучы көчләрне туктатып калган берничә мөһим факторны билгеләп үтәргә мөмкин:

— халык тарафыннан яклау тапкан чечен гаскәрләренең сугышчан сәләте. Мөгаен, Грозныйда сугыш хәрәкәтләре башланганчы, алар «хәрби формированиеләр» булганнардыр, әмма бүген аны без регуляр, мобиль, хәрби шартларда өйрәтелгән һәм яңа бәрелешләргә әзер, шуның өстенә Русиянең хәрби машинасын акылга утырткан армия буларак беләбез. Сугыш хәрәкәтләре кем файдасына гына тәмамланмасын, Мәскәү Ичкериядәге сугышта оттырды, чөнки сәяси мөнәсәбәтләрдә көч куллану факторы үз эшен эшли алмады;

— массакүләм мәгълүмат чараларының зур күпчелеге чечен кризисын көч куллану юлы белән хәл итүгә каршы чыкты. Алар үзләрен тиешле дәрәҗәдә бәйсез һәм демократия принципларын яклаучылар итеп күрсәттеләр;

— Ичкерия йөзендә үз хокукларына кул сузганнарын күргән республикаларның кискен позицияләре. Идел буе һәм Урал республикалары җитәкчеләренең Чабаксарда игълан иткән белдерүләре күп кенә кайнар башларны суындырды;

— ниһаять, җәмәгатьчелек, аналар комитетлары, төрле партияләр фикере. Чечнядагы хәрби операцияне Жириновский һәм Шахрай партияләре генә турыдан-туры һәм берсүзсез яклап чыкты. Калганнары исә теге яисә бу рәвештә ара тоттылар, бу хәрби акцияне, аны тормышка ашыру алымнарын кискен гаепләделәр. Хәер, күпләр моны конъюктур фикерләрдән чыгып эшләделәр.

Социологик мәгълүматлар буенча, Татарстанда респондентларның нибары 8 проценты гына әлеге низагны тәртипне ныгыту өчен кирәк, дип санады. Шул ук вакытта респондентларның 2 проценты чечен кризисына битараф булып чыкты. Нәтиҗәдә, аларның 90 проценты Чечнядагы сугышка каршы булуын белдерде («Известия Татарстана», 1995 ел, 21 февраль). Барча партияләр һәм хәрәкәтләр дә үзәкнең Чечнядагы гамәлләрен гаепләп чыксалар. Дәүләт Думасы депутаты Иван Грачев бөтенләй икенче төрле фикердә торуын белдерде. Оят, әмма бу чыннан да шулай. Ничәмә-ничә еллар буенча үзен «чын демократ» дип атаган бәндәбез тоталитар алымнар яклы булып чыкты. Тарихи масштабта империянең киләчәге юк, әмма аны торгызырга тырышучылар булыр. А.Солженицын Русиядә төп идеолог булып торган вакытта бигрәк тә Төп көрәш 1996 елда Президент постына кандидат булу өчен барачак. Бер төркем сәяси хәрәкәтләрнең Ельцинга каршы көрәштә берләшергә омтылулары бик мөмкин. Асылда бу позиция шовинистик рухта булачак. Болар барысы да заманында А.Сахаров идеяләрен күтәреп чыккан демократларның алардан баш тартулары нәтиҗәсе.

Моңа кем каршы тора алыр? Бу мәсьәләгә бер генә яклы итеп карарга ярамас. Бүгенге көндә «демократик көчләр» инде бердәм фронт хасил иттеләр һәм үзләренең реформаторлык потенциалларын шактый дәрәҗәдә юкка чыгардылар. Әлбәттә, алар башкаладагы дәрәҗәле урыннарда утырулары һәм күп кенә мәгълүмат чараларын контрольдә тота алулары аркасында сәясәткә һаман да йогынты ясауларын дәвам итәләр. Әмма, кызганычка, алардан яңа башлангычлар көтү мөмкин түгел.

Башлангычлар аста — төбәкләрдә барлыкка киләчәк. Реформалар иң әүвәле республикаларны кызыксындыра. Демократия һәм федеральләштерү алар өчен сәяси һәм икътисади статусны саклап калуның төп шарты булып тора. Бу инде перспективалар да булачак дигән сүз. Соңгы вакытларда булган вакыйгалардан күренгәнчә, Идел буе һәм Урал республикалары үзләрен бүген иң актив сәяси көч буларак күрсәтәләр. Һәм бу аңлашыла да. Алар шактый зур икътисади потенциалга һәм чуар этник составка ия. Әлеге республикалардагы проблемаларны инде Солженицын күрсәткән юллар белән хәл итеп булмый.

Көнбатыш дәүләтләре дә Русиядә демократлаштыру процессын дәвам иттерү ягында. Шулай да аларның үз-үзләрен тотышлары демократияне корбан итеп булса да тотрыклылыкны саклап калу теләге белән билгеләнә. Алай да анда Русиядәге тоталитар «тотрыклылык»ның дөньядагы тотрыксызлыкка китерергә мөмкин булуын да аңлыйлар. Шуңа күрә дә бу дәүләтләрнең үз-үзләрен тотышлары еш кына эзлеклелеген югалта.

Халыкара җәмәгатьчелекнең «чечен» кризисындагы роле бик яхшы күренә. Б.Клинтон һәм Аурупа илләре җитәкчеләре тарафыннан яклау тапкан Грозныйдагы операция хәрбиләрнең кулын чишеп җибәрде. Көнбатышның позициясе дә республикаларда канәгатьсезлек уятты. Әмма тыныч халык бомбага тотылгач һәм дә вәхшиләрчә хәрби операцияләрдән бөтен дөнья калтыранып куйгач, Аурупа сәясәтчеләренең күпчелеге үз позицияләрен үзгәртә башлагач, Б.Ельцинда сугышка икенче төрле характер бирү теләге туды. Аурупа Советының Парламент Ассамблеясе 1995 елның 2 февралендә кабул иткән 1055 нче Резолюциясендә шундый кискен фикер әйтте: «Ассамблея Чечня белән Русия



Федерациясенең үзәк хакимияте арасындагы низагны эчке эш дип санаса да, әлеге хакимият тарафыннан кулланыла торган алымнар Русиянең халыкара йөкләмәләрен бозу буларак бәяләнә». Аннары Ассамблея берничә пунктта Русиянең үз өстенә алган халыкара йөкләмәләрне һәм элементар кеше хокукларын бозуын күрсәтеп уза.

Сәясәтчеләр принциплардан бигрәк мәнфәгатьләргә тәңгәл рәвештә эш йөртәләр. Файдасы булганда, алар Югославия республикаларының үзбилгеләнүләрен һәм СССРның таркалуын яклап чыктылар. Хәзер алар Абхазиянең, Приднестровьеның һәм Чечняның аерылып чыгарга дигән дәгъваларын кирәкагалар һәм территориаль бөтенлек принципларын бозарга ярамаганлыгы турында сөйлиләр. Төрле халыкларга ике төрле стандарт аша карау сәяси тормышта чынбарлык булып тора. Ап-ачык ки, бу җирдә тынычлык урнаштыруда ярдәм итми. Көнбатышның Чечнядагы хәлләргә карашы 1949 елда Женева конвенциясе, аның 1977 елгы беркетмәсе, шулай ук 1994 елда Русия тарафыннан кабул ителгән ОБСЕ тәртип кодексында каралган кеше һәм халык хокукларының күпләп бозылуына китерде. Бәлки моны Көнбатышның бер генә лидеры да көтмәгәндер. Әмма нәкъ менә алар Русиянең «сугыш партиясе»нә индульгенция бирделәр. Һәм бу канлы сабактан тиешле нәтиҗәләр чыгарырга кирәк.

Беренче нәтиҗә. Югославия тәҗрибәсе һәм элекке совет дәүләтләрендәге низаглар сугышның беркемгә дә уңыш китермәвен күрсәтәләр. Сугышка тартылган яклар җиңгән очракта да тупыйкта калалар. Димәк ки, хәрби операцияләрнең эчке характерда булуларына сылтау ясап, аларны акламыйча, низагларны халыкара җәмәгатьчелек карамагында булган барча чаралар ярдәмендә дә булдырмаска омтылырга кирәк.

Икенче нәтиҗә. Тыныч халыкка карата көч куллану чикләре бар. Шулай булгач, территориаль бөтенлек абсолют характерда була алмый. Аны куллануның табигый чикләре бар. Ул — кеше һәм халыклар хокукларын бозу.

Өченче нәтиҗә. Халыкларның үзбилгеләнү принципларын сәяси лидерларның теләсә нинди гамәлләрен, көч куллануларын аклаучы принциплар дип аңларга ярамый. Ләкин әгәр дәүләт халыкны газаплый башласа һәм аны юкка чыгару куркынычы астына куйса, үзенең халыкара йөкләмәләрен үтәмәсә, үзбилгеләнү әлеге халыкның дәрәҗәсен саклап калу гарантиясе буларак тормышка ашырылырга тиеш. Халыкара җәмәгатьчелекнең бу очрак өчен халык ихтыярын билгеләүче демократик процедураларга ия булуы зарур.

(Ахыры 8 нче биттә).

ҖИДЕГӘН 5 6 7 1 2 3 4
ВАКЫЙГАЛАР ХӘБӘРЛӘР ЯҢАЛЫКЛАР

# Казан телескобы — Төркиядә

Шәһәрнең «ОМО» заводында Казан дәүләт университеты заказы белән көзгесенең диаметры 6 метр тәшкил иткән үзенчәлекле телескоп ясалды. Бу телескоп Төркиягә җибәрелә. Ул курортлары белән дан тоткан Анталия шәһәреннән 100 чакрым еракльктагы тау башына урнаштырыла. Казан галимнәре бу тауны Галәмне тикшерү максатында иң җайлы урын дип таптылар. Казанлылардан тыш, әлеге телескоп аша төрек астрономнары да йолдызлы күк серләрен өйрәнәчәкләр. Төркиянең үзендә мондый телескопның әлегә булганы юк иде.

# Кунакны кабул итү

*Төркия дәүләт архивларының генераль директоры Исмәт Бинаркның Казанга рәсми визит белән килгәнен хәбәр иткән идек инде. Төркия кунагын Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.Харис, Премьер-министр урынбасары И.Хәйруллин, Татарстан Фәннәр академиясе президенты М.Хәсәнов, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе академик И.Таһиров кабул итте.*

# Казанда коелачак, Ырынбурда куелачак

**Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты соңгы вакытта үзләренә килгән кунакларны журналистлар белән очраштырупы гадәткә кертте. Бу юлы Төньяк Осетия-Алан Республикасыннан килгән Г.Тукай исемендәге «Капкай» мәдәни үзәге рәисе Ирфан Якубов, Ырынбурның баш архитекторы Радик Гайнуллин һәм шәһәр иҗтимагый үзәге рәисе Зиннур Шакировлар белән кызыклы әңгәмә булды.**




**Ирфан Якубов Владикавказда яшәүче татарлар тормышы белән таныштырды.**

— Владикавказның өч исеме бар, — дип башлады ул сүзен. — Элек ул Алтын Урданың Капкай шәһәре булган. Осетиннар аны Дзауҗикгау, урыслар Владикавказ дип атый. Кавказ төбәге бүген кайнап тора. Грозныйда сугыш барганда иҗтимагый үзәк әгъзаларына мәдәни эшләр белән шөгыльләнергә туры килмәде. Без урыс армиясендә хезмәт иткән милләттәшләр һәм Грозныйда яшәүче татарларның язмышы белән мәшгуль булдык. Осетиннар белән ингушлар арасындагы низаг та тынычлыкны алды, аларны татуландыру өчен дә шактый көч куярга туры килде.

Тыныч вакытта иҗтимагый үзәк үз тирәсенә милләттәшләрне туплый, балаларга туган тел өйрәтә, ясле-бакча, татар сыйныфлары ача. Бөтен Кавказдагы иң матур мәчетне дә 1900-1907 елларда татарлар төзеткән булган, шуны үзләренә кайтарганнар, күптән түгел татар зираты өчен дә җир алганнар. Осетиннарның татарларга мөнәсәбәте әйбәт. «Капкай» мәдәни үзәге Татарстанда даими вәкиллек ачарга ниятли.

Ырынбур татарлары да үз уй-хыяллары белән яшәп икән. Зиннур Шакиров һәм баш архитектор Радик Гайнуллин якташлары Муса Җәлилнең 90 еллыгына менә дигән һәйкәл салачаклары турында әйттеләр. Шәһәр хакимиятенең ярдәме зур, архитекторларның күбесе — татар кешеләре.

— Скульптура конкурс нигезендә сайлап алынды. Анда 20 ләп скульптор катнашты. Җиңүче дип Нәбил Ишмөхәммәтов табылды, — диде Радик әфәнде. — Һәйкәл 1996 елның 15 февралендә Постников урамында куелачак. Без, ярдәм сорап, Татарстан хөкүмәтенә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләргә дә мөрәҗәгать иттек. Хөкүмәт җитәкчеләре безне бик яхшы каршы алдылар һәм булышырга вәгъдә иттеләр.

Ырынбур кунакларын Казанга тагын бер сәбәп китергән. Бирелә ачылган һәйкәл коючы тәҗрибә-җитештерү заводы заказларны бер ай эчендә үти икән. Димәк, Җәлил һәйкәле Казанда коелачак.

Һәйкәл салу өчен акчаны аерым кешеләр, предприятиеләр, күмәк хуҗалыклар да түбәндәге исәп-хисап счеты буенча җибәрә алалар: р/с № 000700304 МФО 284019 в Ленинском филиале ОрИнд-Банка г.Оренбурга, п/с № 800161113 с пометкой «Памятник Джалилю».

Рәсимә СИБГАТУЛЛИНА.

● Капкайдагы татар мәчете.

# Халыклар дуслыгы, дип лаф органчы...

Казан дәүләт педагогия университетының урыс филологиясе факультеты каршында ачылган чуваш теле һәм әдәбияты бүлегенә быел 28 студент кабул ителде. Алар берьюлы ике белгечлек — урыс теле һәм әдәбияты, шулай ук чуваш теле һәм әдәбияты укытучысы белгечлекләрен алып чыгачак. Мәгълүм булганча, әлеге бүлек узган ел Татарстандагы чуваш мәктәпләренә милли белгечләр әзерләү өчен ачылган иде.

# Күзгә көйләр

**«Илдан» фирмасы каршында эшләп килүче «Лик» модалар театры үзенең яңа сезонын Бөтендөнья матурлык конкурсына багышланган «Күзгә көйләр» дигән программа белән ачып җибәрде. Анда тамашачылар «Илдан» фирмасының яңа модельләре белән таныштылар. Программада шулай ук Татарстанның атказанган артисты Мнир Соколов һәм Бөтенроссия конкурсы лауреаты «Сюрприз-квинтет» ансамбле чыгышлары да каралган.**

**Ә итагатьле ир-егетләр сезон ачылган көнне биредә үзләренең сөйгәннәренә «Флора — дизайн»ның нәзакәтле чәчәк бәйләмнәрен дә бүләк итә алды.**

# «Яшьлек»кә Әнкара да якын

Башкалабызның Химиклар мәдәният сарае каршында эшләүче «Яшьлек» халык биюләре ансамбле Әнкарада узарга тиешле 11 Халыкара халык биюләре фестивалендә катнашачак. Ул анда Төркиянең яшьләр мөнфәгатьләре идарәсе чакыруы буенча бара.

Әлеге фестивальдә «Яшьлек» тамашачыларга татар биюләреннән тыш, башкорт, төрек милли биюләрен дә күрсәтәчәк.

# Җомгадан — җомгага

## Җөмһүрият елъязмасына җөмләләр

Татарстан Республикасының дәүләт мөстәкыйльлеге турындагы Декларациясе кабул ителүгә 5 ел тулу уңаеннан Президент М.Шәймиев исеменә Саха, Абхазия, Кабарда-Балкар, Мари Иле, Молдованың Днестр буе республикалары Президентлары М.Николаев, В.Ардзинба, В.Коков, В.Зотов, И.Смирнов, Түбән Новгород, Свердловски өлкәләре губернаторлары, АКШның «Женерал Моторс» корпорациясе президенты, мөселманнарның Үзәк Аурупа Диния нәзарәте идарәсе рәисе Р.Гайнетдин, профсоюзлар конфедерациясе рәисе В.Щербаков, Идел буе хәрби округы командующие А.Сергеевтан һ.б. котлау телеграммалары килде.

Президент М.Шәймиев Зеленодол районының Осиново бистәсендә яңа мәктәп ачу тантанасында катнашты.

**Дәүләт Советы Рәисе В.Лихачев Түбән Камада өч яңа мәктәпне ачу тантанасында булды.**

Быел Татарстанда 27 яңа мәктәп төзелде. Ел дәвамында тагын 25 мәктәп сафка басачак.

**Җитештерүче предприятиеләр продукциясе үрнәкләрен Измирда (Төркия) үткәрелгән 64 нче халыкара күргәзмәгә куйган Татарстан делегациясен шәһәр мэры Борһан Озфатуро кабул итте.**

Президент М.Шәймиев Кремльдә Татарстан Республикасына эш визиты белән килгән «Женерал Моторс Корпорейшн» һәм «Интернэшнл Моторс Лимитед» компанияләренең җитәкчеләреннән торган делегация белән Алабуга автомобиль заводы җирлегендә «Шевроле-Блейзер» җиңел автомобиле җитештерү буенча уртак предприятие булдыру мәсьәләләре турында сөйләшү алып барды.

**Республикабызның нефтьчеләр шәһәре Әлмәттә «Нефть һәм нефть-газ чыганакларын эшкәртү, аның торышы, проблемалары һәм аларны хәл итү юллары» дигән мәсьәләне тикшерүгә багышланган Бөтенроссия киңәшмәсе булып узды.**

*«Татар-Информ», авторларыбыз һәм башка чыганакларның хәбәрләре файдаланылды.*

# Балаларга — хокук нигезләре

...ная каласының 64 нче ...тәп-гимназиясендә ...ры сыйныфлар өчен ...ук фәннәре нигезлә... өйрәтүче яңа класс ...лды. Шәһәр мәктәп...ре һәм гимназияләре ...ндагы шушындый ...че класска Татар... Эчке эшләр министр...гы академиясе, баш...ндагы Мәскәү районы ... хезмәт бүлеге ...лык итә.

# Рәссам хисап тота

...кт-Петербургтагы ...мнар берлегенең ...змәләр залында ... Гыйләҗевның күр...ргәзмәсе булды.

...ргәзмәгә рәссамның 101 картинасы ...йзажлар, натюрмо...р һәм портретлар ...лган иде.

# Шикәр чиренә дәва бар

...анда шикәр чирен...ганучылар өчен ма...газа ачылды. Анда ...өчен махсус пешере...ртлар, пирожный... ...ни сатылачак.

## Рудольф Нуриевны Венада да зурлыйлар

*Венада үткәрелә торган традицион җәйге музыка фестивале Ратхаусплац мәйданында Чайковскийның «Аккош күле» фильм-балетын күрсәтү белән тәмамланган. Бу спектакльдә төп рольне заманында Рудольф Нуриев башкарган.*

*Фестивальнең соңгы көнендә халык аеруча күп җыелган, чөнки бу көн XX гасырның иң данлыклы биючесе һәм хореографы Рудольф Нуриев истәлегенә багышланган булган. «Аккош күле» балетын ул 1966 елда Вена дәүләт опера театры сәхнәсендә куйган. Рудольф үзе бу балетта принц ролен уйный, ә Одетта-Одиллия партиясен мәшһүр балерина Маргот Фонтейн башкара. Кино тасмасына язып алынган бу спектакльгә күпләр елның иң яхшы спектакле дигән бәя биргән. Анда Рудольф Нуриев композиторның үлемсез музыкасының матурлыгын гына түгел, ә бәлки изгелекнең явызлык өстеннән тантана итүен, каһарманнарның хис тирәнлеген дә аеруча нәзакәтле итеп әйтеп бирә алган.*

## «Түгәрәк өстәл» таләбе

Татарстан Республикасының дәүләт мөстәкыйльлеге турындагы Декларация кабул ителүгә 5 ел тулу уңаеннан «Түгәрәк өстәл»гә керә торган сәяси фиркаләр һәм иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләр тарафыннан Казанда уздырылган халык җыенында: шәһәр пассажир транспортында йөрү бәясен кискен күтәрүгә каршы чыгарга; Өфе, Ульян, Таганрог, Пермь, Миасс калалары үрнәгендә шәһәр транспортында бушлай йөрүне кертергә; Татарстан Республикасындагы бюджеттан акча алып эшләүчеләргә хезмәт хакын Русия Федерациясендәге «бюджетник»ларныкы белән тигезләүне таләп итәргә, дигән резолюция кабул ителде.

## Башкортстанда — татар гимназиясе

**Башкортостанның Бәләбәй шәһәрендә беренче татар гимназиясе ачылды. Быел анда 200 дән артык бала белем алачак. Бу уңайдан ике йөз меңнән артык милләттәшебез яшәгән Уфада да, ниһаять, татар гимназияләре ачыла башлар, дигән өмет туа.**



## Шәркый гыйлем аласыгыз килсә...

**Заманыбыз буталчык, болгавыр. Кичәге кануннар бүген инде гамәлдә түгел, бүгенгесе дә иртәгә үзгәрергә мөмкин. Шуңа күрә дә, тормыштан артта калмас өчен, аларны көндәлек рәвештә өйрәнеп барырга кирәк. Әлбәттә, хәзер моңа күпләрнең вакыты да җитми торгандыр. Ник дигәндә, иң беренче нәүбәттә тамак туйдыру турында уйларга кирәк бит. Бу очракта инде безне юристлар коткара. Нинди генә сорау белән мөрәҗәгать итмә, барысына да җаваплары әзер. Бөгелмәдәге Көнчыгыш икътисад, гуманитар фәннәр, идарә һәм хокук институтының юридик факультеты нәкъ менә шундый белгечләр әзерли дә инде. Әлеге факультетта 16 яшьтән алып 50 яшькә кадәргеләр төрле һөнәр ияләре белем ала. Араларында Русиянең төрле өлкәләреннән, БДБ илләреннән һәм хәтта Әфганстаннан килгән кешеләр дә бар. Бер сүз белән генә әйткәндә, Көнчыгыш институты — тизләтелгән уку программасы буенча юристлар гына түгел, икътисадчылар, журналистлар, укытучылар һәм башка төрле һөнәр ияләре әзерли торган югары уку йорты ул. Имтиханнар бирү зарур булмаса да, укырга керү җиңел түгел. Шәкертләр барча факультетларга да тестлар, әңгәмәләр нигезендә кабул ителә. Анда көндезге һәм читтән торып уку бүлекләрендә белем алырга мөмкин. Уку өчен түләү бәясе исә башка югары уку йортларындагыга караганда күпкә арзанрак. Ятим балаларга, инвалидларга, Чернобыль фаҗигасен кичергән, Әфганстанда хезмәт иткән кешеләргә ташламалар (15 проценттан алып 30 процентка кадәр) каралган.**

**Кабул итү комиссиясе һәр көнне (якшәмбедән кала) 10 сәгатьтән 17 сәгатькә, шимбә көннәрне 10 сәгатьтән 15 сәгатькә кадәр эшли. Белешмәләр өчен түбәндәге адрес белән мөрәҗәгать итәргә: Бөгелмә шәһәре, Я.Гашек ур., 8 нче йорт, сәүдә-кооператив училищесы бинасы. Телефоннар: 5-30-06; 5-30-55.**

● *Институтның техник фәннәр кандидатлары: Рәвис Шәфигуллин (уңда) һәм Петр Носов.*

## Япон әдибе — Дәүләт Советында

Татарстан Дәүләт Советы Рәисенең беренче урынбасары, шагыйрь Ренат Харис Япониядән кунак булып килгән япон язучысы һәм галиме Токудзи Акамацуны кабул итте. Бу япон язучысының Казанга икенче тапкыр килүе. Беренче тапкыр ул мәркәзебездә биш ел элек булган иде.

Токудзи Акамацу Кобэ шәһәрендә яши һәм чит телләр өйрәнү институтында эшли. Ул урыс телен өйрәнүче студентларга Русиядәге милли әдәбиятлар тарихын укыта. Гыйльми-педагогик эшчәнлегендә татар мәдәниятен өйрәнүгә дә зур әһәмият бирә. Ул япон укучыларын Муса Җәлил шигырьләре белән беренче буларак таныштырды, аның шигырьләрен япон теленә тәрҗемә итеп, газет-журналларда бастырып чыгарды. Үзе язган дәреслекләрдә дә ул М.Җәлил иҗатын пропагандалый, аларны япон студентларына өйрәтә.

Токудзи Акамацу бу юлы Казанга татар мәдәнияте белән тагын да ныграк танышу җәһәтеннән килде. Ул Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институтының кульязмалар бүлегендә М.Җәлилнең шәхси архив материаллары белән танышты. Япон галиме Җәлил һәйкәле янында каһарман-шагыйрьне һәм җәлилчеләрне искә алу митингысында да катнашты. Казандагы Тукай һәм Җәлил музейларында булды, укучылар, галимнәр белән очрашты.

Очрашуда япон һәм татар әдәбиятлары арасындагы бәйләнешләрне тагын да көчәйтү, ныгыту турында сүз барды, бу юнәлештә конкрет чаралар билгеләнде. Анда Татарстан Фәннәр академиясенең әгъза-мөхбире профессор Нил Юзиев тә катнашты.

ӘЛЕГЕ ДӘ БАЯГЫ

# Күңел көзгесе — китап, китап сөйсәң — күңел ак...

*Әйе, «Әлеге дә баягы: чәчкә диеп кулым сузам, ә ул — шайтан таягы», — дип язган бер шагыйрь. Әле беренче адымнарын гына атлап киткән «Мәдәни җомга»га «Ак барс» банкы һәм Республика яшүсмерләр китапханәсе арасында дәвам иткән бәхәскә кушылу, бәлки, кирәк тә булмагандыр. Әмма сүз китап турында, яшь буын хакында бара икән, мәдәни газета читтә кала аламы? «Ак барс» банкы идарәсе рәисе Т.Абдуллинга зыялыларыбыз язган ачык хат та, Тәлгать әфәнде Абдуллинның җавап хаты да газетабызда әнә шул җөмләдән урын алды. Ә хәзер менә китапханә хезмәткәрләренең хаты. Бу хатка 17 кеше кул куйган.*

Хөрмәтле Тәлгать әфәнде!

«Мәдәни җомга» газетасының 5 нче санында хата сүз язып, Сез безне шаккатырдыгыз, гаҗәпләнүебезне чиктән ашырдыгыз. Без Сездән моны көтмәгән идек.

Елдан артык бер бина өчендә эшләү дәверендә, Сез безнең белән, эшебез белән танышкансыздыр, китапханәгә хөрмәтегез арткандыр, дип уйлаган идек. Сез, бу бинага укучылар түгел, чыпчык та керә алмаслык шартлар тудырсагыз да, без яшәүдән туктамадык, укучыларыбызны югалтмадык. Хезмәткәрләребез шушы гомер өчендә 18 күчмә китапханә оештырды. Бездә «Әдәби кунакханә», «Лира» вернисажы, «Чишмә» исемле музыкаль, яшүсмерләрнең психологик аралашу клублары, видео-университет эшләде. Без кичәләрне, очрашуларны гимназияләргә, мәктәпләргә, яшүсмерләр һәм балалар үзәкләренә барып үткәрдек. Татарстан китап нәшриятының 75 еллыгына багышланган кичә, «Мин яшәгән шәһәр» исемле интеллектуаль уен, туган якны өйрәнү, этика дәресләре шулай узды. Китапханә хезмәткәрләре, методик ярдәм күрсәтеп, республика районнарында семинарлар һәм күргәзмәләр оештырды.

Шулай ук китапханә, республикабыздагы талантлы яшүсмерләребезнең иҗатларын җыеп, «Шигъри альманах» чыгарды, шәһәребезнең яшь интеллектлар клубын оештырды. Кызганыч, безнең бу эшләребезгә дә нокта куелды, без урамда калдык.

Әгәр дә газетадагы сүзегез дөрес булып, Сез безгә, чыннан да, берәр бина тәкъдим иткән булсагыз, без халкыбызның изге угълына мәдхия җырлар идек. Ләкин Сез санап үткән тәкъдимнәр безгә мәгълүм түгел. Бәлки, ул Сезнең запас вариантыгыз булгандыр? Алай дисәң, Сез монда санап киткән О.Кошевой урамындагы 183 нче, «Соцгород» тирәсендәге балалар бакчаларын без үзебез әбиләрдән сораша-сораша таптык, безгә аларны бирәү дә тәкъдим итмәде, киресенчә, үтенечебезне кире кактылар.

Дөрестән дә, без Кадышев урамында урнашкан завод администрациясе бинасындагы мәйданнан баш тарттык. Моның җитди сәбәпләре бар иде. Яшьләрнең аралашу үзәге булырдай китапханәне Каф тавы артына илтеп ыргытмыйлар. Кайсы ата-ана газиз баласын шунда җибәрсен инде? Бу китапханә яшүсмерләргә килеп йөрергә уңай урында, шәһәр үзәгендә урнашырга тиештер бит?!

Сез безне үзегезгә карата уңай булмаган фикер йөртүдә гаепләп ялгышасыз, Тәлгать әфәнде! Безнең әлеге бинадагы урын өчен елдан артык көрәш алып барганны Сез генә түгел, республика халкы белә. Район мәдәният учакларыннан, безгә ярдәм кулы сузып, күпме телеграммалар, хатлар килде.

Бу килеп чыккан аңлашылмаучанлыкка да карамастан, без Сезнең олы җанлы булуыгызга ышанабыз. Сезнең ярдәмегез белән менә дигән бина алып, яшьләребезне шатландырырбыз дип өметләнәбез.

**Республика яшүсмерләр китапханәсе хезмәткәрләре.**

***Шагыйрь!.. Шагыйрь... Кем ул?! Аның җәмгыятьтә тоткан урыны нинди? Үзе генә йолкынып, бәргәләнеп яшәүче кызганыч бер затмы ул, әллә бөтен җәмгыятьнең, яшәешнең серле бер көзгесеме? Кешеләр көзгесез яши алалармы?..***

***Мин — шагыйрь. Һәм мин «Шагыйрь кем ул?» — дигән сорауга җавап эзлим. Мин үземнең кем булуымны, ягъни тормыштагы урынымны аңларга, белергә тиеш. Үземнең гомеремне, язмышымны багышлаган бу шөгыльнең, Табигатьтән йөкләнгән шушы миссиямнең кешеләр өчен ни дәрәҗәдә мөһим булуын исбатларга бурычлы. Бу — масаю да, тәкәбберләнү дә, башка һөнәрләрне икенчерәк дәрәҗәгә куярга тырышу да түгел. Бу — бары тик үз эшенә чын бирелгәнлектән һәм аны хөрмәт итүдән, күп еллар буе аңа гашыйк булып (димәк, бу — Мәхәббәт!) һәм җаваплылык тоеп яшәүдән генә килә.***

***Кайберәүләр шагыйрьләрне чеметеп үтәргә, аның бәясен төшерергә азапланалар. Янәсе, ул эш кешесе түгел һәм беркинди дә матди файда китерми...***

***Ә нигә соң хәтта изге Китап — Коръәндә дә Шагыйрь сүрәсе бар? Ә нигә соң тарихта тирән эз калдырган олуг патшалар да шагыйрьләргә гаять зур игътибар биргәннәр? Алай гына да түгел, үзләре шагыйрь булган патшалар турында да укып, ишетеп беләбез бит! Шулай ук нигә соң әле теге яки бу халыкның кемлеген танытканда, аның шагыйрьләрен телгә алалар?..***

***Әйе, Шагыйрь — серле зат, хикмәт иясе.***

***Мин үземнең көндәлекләремнән шагыйрь һәм шигырь турында төрле елларда һәм төрле рухи халәтләрдән чыгып язып барган үз фикерләремне бөртекләп җыеп утырдым һәм аларны шигырь сөючеләргә — укучыларыма тәкъдим итәргә булдым. Алар — минем озак еллар дәвам иткән иҗатым дәверендә шагыйрь буларак, үз йөрәгемнән, үз тәҗрибәм аша сөзелеп чыккан уй-фикерләрем. Алар — минем үз сорауларым, үз җавапларым, эзләнүләрем, табышларым. Күңелемнең балкып-балкып киткән чакларында ашыга-ашыга язып куйган хис-кичерешләрем... Кемнәрнеңдер шагыйрь бакчасына таш ыргытуына җавап йөзеннән ургылып чыккан әчке бер протест авазым... Бәлки, алар искитмәле ачыш та түгелдер. Ләкин, ихлас күңелемнән әйтәм: алар минем үз йөрәгем аша узган уй-фикерләрем. Дөньяда нинди генә философлар һәм шагыйрьләр нинди генә хикмәтле, канатлы сүзләр язып калдырмаган! Минем язмаларым да, бәлки, моңарчы үзем укырга өлгергән төрле әсәрләр, фәлсәфи хезмәтләр һәм көндәлекләрнең аңыма вә җаныма уелып калган тирән тәэсире нәтиҗәседер... Ләкин мин аларны беркемнән дә махсус күчереп язмадым. Алар минем инде үз «казаным»да кайнап чыккан үз сүзләрем, үз тәҗрибәм. Һәм шуның белән алар минем өчен кадерле дә.***

Лена ШАГЫЙРЬҖАН

# Шагыйрь һәм Шигырь

Шулай итеп, Шагыйрь кем ул? Һәм нәрсә ул Шигырь?..

Шагыйрь ул — искиткеч нечкә, моңлы һәм гариб күңелле, тиз җәрәхәтләнүчән, кагылсаң, уалырга гына торган нәзберек җан. Шул ук вакытта ул үзенең рухы вә Сүзе белән арысланнардан да гайрәтле, хакимнәрдән дә көчлерәк бер Зат...

Шагыйрь — гомере буе уйланып яшәүче философ. Ул — чын мәгънәсендә Уйдар, уйларга яратучы, уйсөяр. Уйларга сәләтле булсаң, кешеләргә әйтер сүзең һәрвакыт булачак.

Шагыйрь Күкләр белән аралашучы, элемтәдә торучы пәйгамбәр кебек тә ул...

Шагыйрь — Укытучы. Остаз. Тәрбияче.

Хикмәтле Сүз тәмен белүче, телче-лингвист һәм телне камилләштерүче...

Халык иҗатыннан көч алучы һәм үзе дә аңа зур өлеш кертүче фольклорчы да ул.

Шагыйрьләр, кыргый җәнлекләр сыман, үз «авыру»ларын — күңел җәрәхәтләрен һәм рухи газапларын үзләре, шифалы сүзләр белән дәвалыйлар. Һәм — үзләренекен генә дә түгел! Шуңа күрә Шагыйрь ул — кеше рухын вә җанын савыктыручы табиб та.

Шагыйрь искиткеч үткен телле һәм зирәк сәясәтче дә була ала. Халыкны берәр күмәк эш-гамәлгә өндәгәндә, шигырьдән дә үтемлерәк әмәл бармы икән?!. Билгеле шартларда һәм кирәге чыкканда, аның бу сыйфатыннан бик оста файдаланучылар да табыла... Ләкин Шагыйрь хакимлеккә омтылмый, ул бары тик гаделлек өчен көрәшүче генә.

Шагыйрь — кешеләргә җан азыгы бирүче, рухи азык белән «тукландыручы» да.

Шагыйрь — тарихчы. Күпме шагыйрьләрнең әсәрләрендә чын тарихи вакыйгалар чагылыш тапкан...

Шагыйрь ул — тәнкыйтьче. Ул, гомумән, бөтен җәмгыять тормышына гадел тәнкыйть күзе белән караучы. Алай гына да түгел, ул әдәбиятның үзен дә күзәтеп, саклап, бәя биреп торучы.

Шагыйрь — трибун, оратор, нәфис сүз остасы ул.

Аннан килеп, Шагыйрь — халыклар дуслыгы җырчысы, бөек интернационалист һәм ватанпәрвәр. Ул — чын гуманист. Нинди генә шагыйрьләр нинди генә шагыйрьләрнең әсәрләрен тәрҗемә итмәгән! Димәк, әле ул тәрҗемәче, тылмач һәм илче дә...

Шагыйрь — чын художник, рәссам шикелле үк сурәтләү остасы: тел ярдәмендә илаһи бизәкләр, нәкышләр чигүче, портретлар язучы.

Шагыйрь, музыкант кебек. Нинди генә ритмнарда иҗат итми, нинди генә шигъри симфонияләр тудырмый ул! Шигырьнең эчке музыкасы — гаҗәеп нәрсә...

Шагыйрь ул — артист та. Зур шагыйрьләргә артистизм хас.

Шагыйрь — моң баласы, моң чишмәсе, җыры.

Һәм ул — билгеле бер халыкның, милләтнең бөтен акыл һәм рухи дөньясын — менталитетын чагылдыручы бер көзге.

Шагыйрь — милләтнең асыл вәкиле.

Ул — кешедәге психологик кичерешләр һәм эмоцияләрне теркәп баручы да. Кабатланмас хис-кичерешләрне, хәтта онытылмасын өчен генә булса да, шигырьгә салып, «туплап» бару гаять мөһим. Бу — кеше психологиясенең никадәр катлаулы һәм нечкә булуын чагылдырып баручы бер кардиограмма кебек. Хис-тойгыларның бай һәм четрекле нюанслары гына кызыклы лирик-драматик әсәрләр тудырырга мөмкинлек бирә. Әнә шуларны сурәтли белү, бу эштә үзеңнең осталыгыңны сынау — ул зур сәнгать... Шагыйрь бик тә нечкә, сизгер психолог булырга тиеш. Шунда гына ул философ та була ала. Ә менә психологияне чарлау, нечкәртү — аның үзе бер мәсьәлә. Бу — тәрбиядән, әйләнә-тирә мохиттән, табигатьтән һәм кешенең гомыштан килгән үзенчәлекләреннән, белем һәм зәвыгыннан тора.

Нервларның бик сизгер булуы да психологик нәзакәтлелек билгесе. Әйтик, М Горький композитор Д Шостаковичны яклап Сталинга язган хатында аның бик тә гасаби, нервлы булуына аеруча басым ясаган... Тәнең бик сизгер булса гына, җаның да сизгер буладыр. Тиресе калыннар һәм нервлары артык нык вә сау бәндәләр бервакытта да шагыйрь булып китми...

Шагыйрь — Матурлыкка өндәүче һәм аны саклаучы. Матурлык тудыру зур көч-җегәр сорый. Шуңа күрәдер, матурлык, ягъни сәнгать әсәрләре, үзләре дә әйләнә-тирәгә энергия чәчеп торалар...

Шагыйрь — ул белүче түгел, сизенүче. Шагыйрь «шигырь сулап» яши, «һавадан алып» яза. Ул «һава хәлен», атмосфераны «борыны белән» сизә... Шуңа күрә элек-электән шагыйрьләрнең белүеннән түгел, сизенүеннән куркалар

Шагыйрь теле, ягъни Шигырь — эчпошыргыч гади сөйләмнән качу, котылу чарасы. Гел бер рәвешле генә сөйләү туйдырыр иде. Шигырь — ул «кызык» һәм нәфис итеп, көйгә салып «сөйләшү» әмәле дә. Нәкъ менә операда җырлап «сөйләшү» кебек...

Ниһаять, Шагыйрь — йолдызлар белән дә сөйләшә, космик фикер йөртә белүче Галәм баласы һәм Җирнең бөтен гүзәллеген — диңгез-таулар, елга-чишмәләр, урман-далалар серен «ишетүче», сандугач һәм акбүз атлар «телен» аңлаучы; үзе дә Канатлы атта очучы биниһая киң карашлы Җир кешесе дә ул...

Кеше үз теләге белән генә шагыйрь булып китә алмый. Күпләр искәрткәнчә, шагыйрь булып туарга кирәк!. Димәк, аңа Табигать һәм Тәңре шул бурычны йөкләгән. Шагыйрь — кояштан, һавадан, судан, җирдән... Чын зур шагыйрьләр ел саен туып тормый. Алар — Җирнең гансык балалары. Илаһи эшне илаһи шәхесләр генә башкара. Сирәк бәхет — сирәкләргә. Шунда гына аларга ихтыяҗ вә кадер булачак та.

Шул рәвешчә, «шигырь кирәкме?» дип баш вату ул — «дин кирәкме?», «белем кирәкме?» һәм, ахыр чиктә, «тормыш үзе кирәкме?» — дигән мәгънәсез сорауга кайтып калыр иде. Шигърияткне читкә кагып, Базарны гына үзәккә кую — күңелсез хәл. Чөнки шагыйрьләр үзләре базарлардан элегрәк барлыкка килгән. Беренче Шагыйрь кояш баеган чакта барлыкка килгән, дип язган бер акыл иясе. Димәк — матурлык һәм моннан...

Шигъриятсез яшәгән кешене мин Сабантуйсыз калган авыл белән тиңләр идем. Яисә — беркайчан да көзгегә күз салмаган кеше белән... Яки — курчак уйнамаган бала... Дәва эзләмәгән хаста... Төш күрмичә генә йокы симертү... Тәм тапмыйча гына ашау... Кызыкмы? Күңеллеме? Аллам сакласын!..

Йөзгә кадәр дә шигырь язарга мөмкин... Моны мин «утыздан соң шигырь язу көлке» дип сөйләнүчеләргә әйтәм. Җамбуллар да булган. Һәм алар гына түгел, әлбәттә. Иң мөһиме — кешенең җан хәрәкәтен, рухи үсешнең кызыклы этапларын һәм мизгелләрен чагылдыру ..

Үз шигыренә Ана да, Хуҗа да булырга кирәк. Ягъни — аны сакларга, кешеләргә илтеп җиткерергә һәм аның өчен җаваплы булырга Мин — үз шигырьләремнең Анасы...

Шигырь сатылмый. Аның тик әҗере генә булырга мөмкин...

Мәхәббәт җитми башлаган җирдә Шигырь туа башлый булса кирәк. Бушлыкны тутыру өчен...

Кешелекле җәмгыять Шагыйрьне сакларга һәм якларга да тиеш. Нәкъ менә шул җәмгыятьнең җимеше булганга күрә. Аннары Шагыйрь ул бит үз җәмгыятенең санитары да... Чирләсә — диагноз куючысы...

Шул ук вакытта талантлы һәм чын профессиональ, ягъни уйланып яшәрлек һәм язарлык вакыты да, тәҗрибәсе дә булган җитди әдипләр генә, хәтта ки чиргә сабышырлык дәрәҗәдә нечкә психологик кичерешләр һәм катлаулы фәлсәфи фикерләр җирлегендә иҗат итүче, яисә шундый хис-тойгыларны аңлый, сизә белгән язучы-шагыйрьләр генә, җәмгыятьне тазарту көченә ия булалар.

Балыклы күлдән балык тотып була. Алтын ятмаларыннан алтын чыгаралар... Ә бит шигырь, бер караганда, юк җирдән туа. Могҗиза бит бу! Димәк, иҗатчы — тылсым иясе ул.

Шагыйрь ачышлар ясап ятучы галим түгел. Иң иске нәрсәләр хакында да өр-яңа итеп әйтә белергә кирәк.

**(Ахыры киләсе санда).**

Әнәс ГАЛИЕВ

# Тимәгез минем әнигә!

**(Яңа романнан өзек)**

Әбрар авыл тормышына кыенлык белән генә ияләште. Ялгыз калган минутларда бигрәк авыр, күз алдына мәрхүмә әнисе килә дә баса. Ул армиядән кайтканчы гына да исән була алмады, ичмасам...

Әтисе өчен алай ук үзәге өзелми. Ул сугышта хәбәрсез югалды. Фронтта һәлак булучы бер аның әтисе генә түгел. Бик кечкенә иде шул әле Әбрар әтисе сугышка киткәндә. Алар аны әнисе белән басу капкасына кадәр озата бардылар. Әтисенең аерылганда әйткән соңгы сүзләре һич исеннән чыкмый:

— Улым, батыр булып үс, әниеңнең сүзен тыңла! — диде дә, кулына күтәреп, ике битеннән үпте. «Әниеңнең сүзен тыңла!». Әлегә кадәр шушы сүзгә җавап таба алмый баш вата Әбрар. Нишләп алай дип әйтте икән ул, ничек инде бала әнисенең сүзен тыңламаска мөмкин?!

Сугыштан соңгы берничә ел аеруча авыр булды. Ачлык теңкәгә тиде. Кырга барып өшегән бәрәңгене казып алып ашадылар. Өйне җылытырга бер агач түмәре дә юк. Кысыр калган колхоз басуында котырып әрем үсә. Әбрар шул әремне ташып ягулык әзерләде.

Бер елны аларда колхоз рәисе булып районнан җибәрелгән кеше эшләде. Шул Хатип исемле адәм, көн аралаш килеп, әнисенең үзәгенә үтте. Үзе лаякыл исерек була. Әнисе тәрәзәдән сикереп төшеп каравыл кычкыргач кына килүдән туктады мәлгунь.

Иген өлгергәч, ач халык, колхоз басуына чыгып, башак уып тамак ялгый иде. Әбрар да шунда барып тамак туйдыра башлады.

Бер көнне кырда йөргәндә аны колхоз рәисе тотып алды. Алар районнан килгән бер кеше белән тарантаска ат җигеп махсус башак җыеп ашаучыларны каптырырга чыкканнар. Әбрар шулкадәр мавыгып башак җыя иде ки, янына җигүле ат килеп туктаганны сизми дә калды. Районнан килгән кеше милиционер булып чыкты. Ул, тарантастан төшеп, Әбрарны тотып алды. Әбрар, ачыргаланып кычкырып җибәрде дә, милиционерның кулыннан ычкынды. Куышып йөри торгач, тагын тотылды. Аны дилбегә белән бәйләп, тарантас артына тактылар. Киттеләр басу юлы буйлап. Ат урыны-урыны белән юыртып алгалый. Әбрар — яланаяк. Ул ниндидер каты әйбергә сөртенеп аяк бармагын канатты. Авылга кайтып кергәндә тиргә манчылган күлмәге сыгып алырлык булган иде. Кәнсәләргә алып кереп, берәр бүлмәгә ябып куярлар инде, дип уйлады ул. Юк, анда алып кермәделәр. Башкаларга гыйбрәт булсын өчен, тарантас артына тагып, урам буйлап чаптырып йөрттеләр. Бераздан әлсерәп әнисе килеп җитте. Милиционер аны малае янына якын да җибәрмәде.

— Синең үзеңне җавапка тартачакбыз, — дип акырды ул, — малаеңны урлашырга өйрәткәнсең...

Аларның икесен дә бергә кәнсәләргә алып кайттылар. Милиционер озаклап беркетмә төзеде. Аңа шаһитлардан кул куйдырырга кирәк иде. Халык эшнең нәрсәдә икәнен сизеп, тиз генә кәнсәләрдән чыгып сызды. Шаһит булып бердәнбер кеше — Хатип үзе кул куйды.

— Каберен якын булмасын бу авылдагы халык белән, — дигән булды, — үлгәндә авызыңа су салучы табылмас.

Әбрарның әнисе Нәфисә елады да елады. Авызын ачып сүз әйтерлек хәле калмады. Рәис аңа ташланды:

— Җирбит икәнсең. Каракларга колхозда урын юк, авылдан кудырам мин сине.

Нәфисә яхшы аңлый: рәис шулай җикеренеп янына яткырып йоклатмаган өчен үч ала.

— Тимәгез минем әнигә, — диде Әбрар, — ире сугышта үлгән хатынны мыскылларга хакыгыз юк!

— Кара әле син бу әнчекне! Хәбәрсез югалган әтисен сугышта һәлак булды, дигән була! Бәлки, Власов армиясендә Германиягә хезмәт итеп ята торгандыр ул...

Нәфисә улына рәис белән әрләшергә ирек бирмәде, тизрәк кәнсәләрдән алып чыгып китү ягын карады. Шуңа күрә беркетмәне укып та тормастан кул куйды. Эш шуның белән беткән булса, әллә ни бирешмәс тә иде. Ләкин алай гына бетмәде бу эш...

Күргәзмә судка күрше авыллардан да кешеләр килде.

Прокурор, Нәфисәне иреген нән мәхрүм итеп, улы Әбрарны балалар йортына җибәрүне таләп итте. Имеш, ана кеше бердәнбер баласын җәмгыятькә яраксыз итеп тәрбияләгән, урлашырга өйрәткән.

Клубта алма төшәрлек тә урын юк иде. Халык хөкем карарын тын да алмый тыңлады.

Улы социалистик милеккә кул сузган өчен Нәфисә иң каты җәзага тартылырга тиеш булса да, иренең Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югалуын исәпкә алып, суд аны алты айга мәҗбүри эшкә хөкем итте. Аның хезмәт хакының егерме проценты дәүләт файдасына тотып калынырга тиеш.

Хөкем карарын игълан иткәндә Нәфисә чиктән тыш дулкынланды. Йөзенә мәет төсе керде, аягында басып торырлык хәле калмады. Аны өенә җитәкләп алып кайттылар.

Өендә хатынны тагын да зуррак кайгы көтә иде. Йортта бер кабарлык та ризык юк, алга таба ничек яшәмәк кирәк?

Ярый әле күршесе Гаҗби карчыкның кәҗәсе бар. Ул, көтү кайткач, яңа сауган сөт кертте. Аргы яктагы озын Мәрьям бербөтен икмәк белән бераз бал чыгарды. Бал кабып җылы кәҗә сөте эчкәч, хәл кереп киткәндәй булды Нәфисәгә.

Иртәгә нишләргә, дигән сорау туды аның башында. Улын җитәкләп хәер сорашырга чыгаргамы? Юк, юк, мондый хәл булырга тиеш түгел! Кайчандыр чибәрлеге белән авылның йөзек кашы саналган хатын хәер эстәп түгел, эшләп ашарга тиеш. Нәфисә чәче белән җир себерергә әзер. Эш табарга кирәк, эш! Бертуган Шәрәфи абыйсы авылда булса, ул бу кадәр авыр хәлдә калмас иде. Ләкин ул өйдә юк. Акча эшләргә дип читкә чыгып китте.

Әбрар да, әнисе өчен үзәге өзелеп, төне буе йоклый алмады. Сиздермичә генә елап та алгалады. Аның хәле көннән-көн начарлана. Ул үлеп китсә, Әбрар ничек көн күрер?! Дөньяда бер ямь дә калмаячак.

Түбән оч Галие Әбрарга эш тапты. Дөнья бәһасе кеше Гали абый! Ятимнәргә, фәкыйрьләргә гел ярдәм итә.

Каз көтеп йөрүче акылга туймаганрак Миңхәйретдин исемле яшүсмер егет көннән-көн ныграк гилерә башлады. Беркөнне ул бодай кырына кергән каз бәбкәләренең муенын борып ыргыткан. Нигә шулай кыланасың, дип сүгә башлагач та, аптырап калмаган, җавабын тапкан: «Мин аларга социалистик милеккә борын сузган өчен җәза бирдем», — дигән.

Миңхәйретдинне тиләләр йортына озаткач, Гали аның урынына Әбрарны тәкъдим итте. Хезмәт хакын натуралата түләргә килештеләр. Өстәвенә, көтү кайткач, каз хуҗалары аны чират буенча көн саен бер мәртәбә ашаталар. Шулай итеп, аларның тамак ягы көйләнеп китте. Тик менә әнисе Нәфисә генә тернәкләнә алмады. Фәкыйрьлекнең аерылмас юлдашы — үпкә авыруы белән газап чигә башлады.

Әбрарның, үпкә авыруына иң яхшы дәва кәҗә сөте, дип ишеткәне бар иде. Тиенләп җыйган акчасына кәҗә бәти алып кайтты. Әнисе бик сөенде, башы күккә тигәндәй булды.



Әбрар, дөнья куа торгач, егет булып үсеп җиткәнен дә сизми калды. Армиягә каралырга баргач, әнисенең авыруын сәбәп итеп, берәр елга калдырып торуларын сораган иде. Тик аның бу үтенеченә берәү дә колак салмады.

Ул армиягә алынып бер ел да узмады, Нәфисә дөнья белән хушлашты. Әбрар аны күмәргә кайта алмады. Телеграмма хәрби комиссариат тарафыннан расланмаган дип, өенә җибәрмәделәр. Ул заманда гади халык мондый нечкәлекләр белән таныш түгел иде шул әле.

Әнисенең гүр иясе булуына ике атна узгач кына авылга кайта алды Әбрар. Әнисенең үлеменә һич ышанасы килмәде. Ишегалдына, урамга чыгып һаман әнисен күзләде. Ул каядыр якында гына йөридер төсле тоелды аңа. Әнисен эзләп йөри торгач, Миңхәйретдин төсле саташа башламагаем, дип өенә кереп китәргә ашыкты.

Туган йортны, тәрәзәләренә аркылы-торкылы такта кадаклап, ташлап китүдән дә авыр нәрсә бар микән бу дөньяда? Адәм баласы барысына да түзә шул.

Зиратка кереп, бик озак әнисе кабере янында утырды, белгәннәрен укып дога кылды. Анда ятучы башка мәрхүмнәрне искә төшерде. Әнисе аңа аларны догадан калдырмаска куша торган иде.

Ул бүтән беркайчан да авылга кайтмаска сүз биреп чыгып китте. Ярый әле бу уйларын беркемгә дә сөйләмәде. Эчендә җаны бар адәм туган җирен онытамы соң?! Поездга утыру белән өзелеп-өзелеп авылын сагына башлады. Кырлары, болыннары турында әйткән дә юк, каз көткәндә йөргән сукмакларына кадәр күз алдына килеп баса.

Армия хезмәте шулкадәр авыр узды ки, көне — ай, ае ел кебек булып тоелды аңа.

... Менә, ниһаять, ул яңадан туган авылында. Өй ишеген ачып кереп бераз вакыт узгач, күршеләре Гаҗби карчык пәйда булды.

Улым, исән-сау кайттыңмы! — дип ул ике кулын биреп күреште дә, сәке кырыена барып утырып дога кылды.

Әбрар югында шул карчык өйгә күз-колак булып торды инде. Югыйсә, әллә кайчан бөтен өйне ваклап ташып бетергән булырлар иде.

Әбрар, капчыгыннан матур гына яулык чыгарып, карчыкка тоттырды. Хезмәт итә башлагач та, әнисенә алып куйган иде ул аны. Менә кемгә насыйп булган икән яулык.

Яулыкны кулына алгач, Гаҗби карчык елап җибәрде:

— Улым, зур бүләк алып кайткансың, мондый хөрмәтне үз туганнарымнан да күргәнем юк иде.

Аннары карчык тиз генә өенә чыгып чәй куйды, төче коймак әмәлләде. Бик озак сөйләшеп утырдылар. Гаҗби карчык Әбрардан алдагы көндә ничек тормыш итәргә уйлавы турында сорашты. Аның авылда калырга теләге юклыгын белгәч, бик хуплады тагын.

— Ничек булса да шәһәргә китеп урнашырга тырыш инде, — диде ул, — анда эшләгән кеше уч тутырып акчасын ала.

Бу сүзләр Әбрарның болай да иләс-миләс күңелен җилкендереп җибәрде. Гаҗби карчык яныннан чыгып өенә кергәч, ул тәрәзә каршына басып урамны күзәтә башлады. Күңелгә, йөрәккә якын ямьле күренеш! Кызганыч, ләкин китәргә кирәк. Гаҗби карчык дөрес әйтә, авылда яшәүдән мәгънә юк.

Почмак яктагы, әнисеннән калган сандыкка күзе төшкәч, аның эче жу итеп куйды. Анда әнисенең киемнәре тутырылган булырга тиеш. Курка-курка гына сандык капкачын ачты. Исән, барысы да исән! Монда әле чит кеше кулы кермәгән. Иң өстә — кара плюш жакет. Ул аны кеше арасына чыкканда гына кия иде. Бердәнбер күлмәге ин... ул аның. Көмеш беләзек тә исән. Әбрар аны бик яхшы хәтерли. Бу беләзекне әнисе беркайчан да кулыннан төшермәде. Туй көнне бүләк иткәннәр аны. Кырык ямаулы күлмәкләренә кадәр шушында. Барысы да юылган, пөхтә итеп тутырылган. Үләргә җыенмаган әнисе, җиргә нык басып яшәргә тырышкан.

Йортны утынга сүтеп сатса, нигез корыячак. Сандыкны кая куеп торырга? Әнисеннән калган истәлекне юкка чыгарыргамы? Үзе исән чагында Әбрар аларны сакларга тиеш. Шәрәфи абыйсында калдырып торса, ничек булыр икән? Бер көнне ул, шул турыда сөйләшеп карарга ниятләп, аның янына барган иде. Әмма Шәрәфи абыйсы авылны ташлап китү турында ишетергә дә теләмәде. Аны колхоз рәисе янына алып барды. Тракторчыларга мохтаҗлык зур, ничек инде күрәләтә торып бер дигән механизаторны читкә җибәрергә кирәк?

Әбрарның тракторчы икәнен белгәч, колхоз рәисе Галләм эшне бик кызу тотты. МТС директоры белән элемтәгә кереп, аны авылдашлары Мөбә... рәкша бригадасына эшкә урнаштырды.

Армиядән кайткан егетләр гадәт... иркенләп ял итәләр. Ә Әбрар икенче көнне үк эшкә керешә. Барысы да хә... ителгән — ул авылда кала!

## Тукай клубына рәхим итегез!

*14 сентябрьдә Язучылар берлегенең Габдулла Тукай исемендәге клубы нәүбәттәге эшен башлый. Бу кичә шигырь һәм проза китаплары авторы, бигрәк тә «Намус кушканча» повесте һәм «Авылдашлар» романы белән укучының аеруча зур хөрмәтенә лаек булган өлкән язучыбыз Әнәс Галиевка 75 яшь тулуга багышлана. Газаплы да, кызыклы да тормыш юлы узган Әнәс Галиев сезне кызыксындырган сорауларга җаваплар бирәчәк.*

*Кичәдә хөрмәтле җырчыларыбызны да тыңларсыз. Кичке сәгать 6 да Тукай клубына рәхим итегез!*

# Багышлаулар

* * *

**Зиннур Хөснияргә**

Чапты атлар... Бераз чалуладык
Кайчан гына очкын очырган чак
Мәңге кайтмас булып артка калды
Очак инде безгә һәрбер кочак

Үгте, үтте яшьлек Күпме ирен
Тун бөре күк ачылмады Ә без
Арыш басуына килеп чыктык.
Зәңгәр урманнарны күзәтәбез

Дөнья кайчак хакны ялган итә,
Алдашу да чыгар, бәлки, чынга?
Бик тиздән бит кошлар канат җилпер,
Пәрәвезләр очар баш очында.

Япанчасын урап чаба һәркем
Әллә еллар шундый, әллә юллар?
Һәммәбезнен юкса буран ерып
Япа-ялгыз офык эзлисе бар...

Мәңгелек яр яулык болгый кебек,
Китә микән, кайта микән бәндә?
Без белербез моны барлык өмет
Шигырь юлы төсле өзелгәндә.

Беребез дә Таһир булалмадык!
Һәм, әлбәттә, булалмадык Мәҗнүн.
Яратабыз, диеп лаф орсак та,
Һәр сүзебез торган бугай бик юнь

Бу дөньяны ни коткарыр икән?
Матурлыктыр, бәлки? Мәхәббәт, наз?
Каракош күк нәфрәт канат җәя,
Безне инде берни коткаралмас.

Ә шулай да бу гөнаһлы җирдә
Бәйләп тора әле шома җепләр
Дошман күрерлек тә нечкәдер ул? —
Мин алдасам, Тәңре үзе җәпләр

* * *

**Марсель Галигә**

Ык өстеннән күләгәләр шуа,
Төнне йоткан уйчан әрәмә
Кайсы кошның гавышын сон укшый? —
Хәләл дә ул безгә, хәрәм дә...

Кылыч болгап җәйдагайлар үтә,
Тояк гавышлары -- дөп тә дөп...
Актарылып керә нинди заман? -
Ай каядыр китә кителеп

Яулары да шул ук, аулары да...
Без битараф инде... Кем уяу?
Кайсы канатдыны ымсындырып
Чакыра шулай өскә Чатыр тау ..

Тоныкъ кына күкрәү ишетелә.
Килер еллар безне бер аклар.
Шыпырт яла сыман яр астына
Егылалар кәрлә куаклар

Күкрәү килә. Эчендәге кинә
Яшен ташы булып бер чыксын.
Кузгатсын ул гомер көзләрендә
Сүнгән өметләрнең җырчысын

Бар да узар. Таллар гына һаман
Ык ярына ятып сулкылдар
Без әйтергә теләгән сүз кебек
Суырылып чыгар суырлар

* * *

**Бакый Урманчега**

Хәрәкәттә туктап калган сылу
Мизгел булып үтәр гасырлар.
Мөлдерәтеп күзен тукымада
Рәссамыннан бер көн җан сорар

Тими микән саф гәненә аның
Бу залларның шыксыз салкыны?
Һәрбер тыннан, һәрбер ишарәдән
Күләгәләр куя калкынып

Татар кызын шул Мәңгелек ярны —
Яратып ул судан, утлардан.
Кайсы яудан йолып алган икән,
Кайсы золымнардан коткарган?

## Ркаил ЗӘЙДУЛЛА



Бүгән гелдә сокланабыз аңа.
Үзгә күзләр бирә бәясен
Татар кызы кан гамырын гүгел.
Кулыбызны хәзер бәйләсен

Туктап калган әнә хәрәкәттә
Мизгел булып узар гасырлар
Мөлдерәтеп күзен рәссамына,
Кайсы гелдә сылу җан сорар?

Чәчеп ташлар безне Ахырзаман,
Йә җил белән килеп, йә силдә
Урманченың җаны иңәр кызга,
Дәвам кирәк булгач нәселгә

## Фәннур Сафинның соңгы монологы

Яңагымны гырный бу Яңа ел никтер!
Чыршыларны буа һәрбер өйдә ютәл
Яңа йолдыз гуа сискәндереп мине,
Пыялага кемдер чәчәк сылап үтә

Түшәмемдә үшән шәүләләрне шәпләп,
Күз яшьләрен йотып озак яттым чалкап
Сөенсеннәр! диеп җырлар чыгарганмын,
Ә иң мөһим сүзем әйтелмичә калган

Хәмер көткән касә сыман зыңлый гәрәш
Килмәс төннәремнең эче гәме телдә
Офык белән офык кавышырга гели,
Ялгыз көймә кебек мин чайкалам җилдә

Яңа елда калам . Инде хушыгыз сез!
Аерылу сездән булмас монда читен
Яшәешкә таба ап-ак әләм төсле,
Ләхетемнән сузылып чыгар сыек төтен

* * *

**Газинур Моратка**

Әйткән сүз — аткан ук.
(Мәкаль)

Зынлап гора һава бу далада,
Сызгырып ла керә җырыма
Кылганнарга мыштым песи сыман
Күләгәләр килеп орына

Бер офыктан бер офыкка габа
Чабып йөрим Авам Биртеләм.
Кысылам да янә киңәям мин
Үзем генә белгән серемнән

Чит-ят күзгә көлке тоеламдыр
Чаң геледәй кемне чакырам?
Гасырлардан килгән хәбәр кебек,
Бүре чыга иске чагырдан

Дәвер дә юк монда, чорлар да юк
Берни үзгәрмәгән бу якта
Җәя тартам Мәрәй шул ук иске
Ә ук кими бара садакта

Бер офыктан бер офыкка габа
Чабып йөрим Аткан укларны
Кире җыяр өчен авам җиргә,
Ә алар юк, габам юк-барны...

Сибелделәр черек копнәр кебек
Әрәм. дидем Алар асылда
Офыкларга кереп югалганнар
Газәлләрнен кабыргасында

Ә далада тагын ук сызгыра,
(Исән әле, исән чуралык),
Күздән җуела
Дастан атларының
Калын ялларына чорналып

Җан азыгы була аламы ук?
Эзләгәндә аның азымы
Кешеләрнең күңеленә гия
Күтәрмәслек шагыйрь язмы

Көлсә-көлсен мәнсез чит-ят күзләр
Көлсә-көлсен Әмма сизмәсен —
Эзләр гөшә Барысы үксиячәк
Шул җайдакта танып үзләрен

Сынган булыр җәя, садак бушар
Дала калыр бары, җыр калыр ..
Аг сагынган ялгыз җайдакларга
Күләгәләр килеп уралыр

* * *

**Зөлфиягә**

Дарумы бу? Әллә агуы соң?
Дөнья нәрсә сузды, йа Раббы?
Манарамның гамырына төште
Яшәешнең ачы шәрабы

Тагын бер кат аска егылдым мин
Шул ук мәгарә бу .
Караңгы
Манарамның очына ук менде
Яшәешнең татлы шәрабы

# Казан белән Мәскәү арасы...

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Хәзерге вакытта бер генә дәүләт тә изоляцияләнүгә дәгъва кыла алмый. Бөтен халыкара җәмәгатьчелек өчен дә бердәм халыкара хокуклар бар. Конъюнктур фикерләрдән чыгып, аның аерым бер положениеләрен җинаятьчел эчке сәясәтне аклауда файдаланырга ярамый. Ахыр чиктә, бу конкрет дәүләткә генә түгел, бөтен кешелек дөньясына да тотрыксызлык һәм сугыш рәвешендә зыян гына китерә.

Аурупа илләренең, аеруча АКШ аналитикларының инде ничәмә-ничә еллар Русиядәге хәлгә дөрес бәя бирә алмаулары һәм гомумдемократик традицияләргә сыешмаган күп кенә вакыйгаларны аклаулары турында да аерым әйтеп үтәргә кирәк. Мәсәлән, Русия Федерациясенең законнар чыгаручы органын тупка тоткан өчен Б.Ельцинга мәдхия җырланды Ә бу чечен вакыйгаларына кереш сүз булып чыкты. Нәкъ менә шул вакытны Русия җитәкчеләре оппозициягә каршы киләчәктә дә танклар куллану мөмкинлегенә инанып, сәяси юл белән хәл итәргә мөмкин мәсьәләне хәрби юл белән хәл итәргә алындылар.

Экспертлар реаль фактлар турында Мәскәү гәзитләре аша гына фикер йөрттеләр, республикаларда булмадылар диярлек. Республикаларны «консерватив провинция» дип атап, фәкать үзәк хөкүмәткә юнәлеш тоттылар. Русиянең яңа Конституциясе турында мактау сүзләре генә яңгырап торды. Юкса, аның маддәләрендә чечен синдромын да күрергә була иде. Халыкара экспертлар хәзергә үз законнарын системалы рәвештә бозуны норма итеп куйган Русиянең сәяси мәдәниятен анламамышка салышалар. Яңа лидер килүгә үк Русиядә янә яңа Конституция кабул ителергә мөмкин. Русиядә федеральләштерү һәм демократия гарантияләрен законнарда түгел, ә сәяси көчләрнең урнашу тәртибендә күрергә кирәк.

Америка экспертлары үрнәк итеп үзләрендәге федерация формасын күрсәтәләр һәм Мәскәүдәге бер төркем сәясәтчеләрнең Русияне территориаль билгеләр буенча үзгәртеп корырга тырышуларын аклыйлар. Чынында исә бу тотрыклылыкка бик зур куркыныч белән яный. Русиядә «боснизация» башланды инде. Республикаларның статусларын янсә чикләрен үзгәртергә омтылулар, көч куллануның тоталь характер алуына китереп, дөньяны гаять авыр сынауларга дучар итәргә мөмкин.

Демократияне Мәскәү теләгәнчә генә урнаштырып булмый, дөньяда федерациянең әзер формалары юк, Русияне демократик башкалага һәм консерватив провинцияләргә бүлү әхлаксызлык ул. Мәгәр Көнбатыш экспертларының, халыкара оешмаларның фикерләре шулкадәр әһәмиятле булмаса, бу мәсьәләдә махсус тукталып тормасаң да ярар иде, әмма алар Русиянең киләчәге өчен билгеле бер дәрәҗәдә җаваплы булып торалар.

Гыйнвар аенда «Уолл стрит джорнал»да Клаудия Россетның «Татарстан аю кочагында бии» дигән мәкаләсе басылып чыккан иде. Әлеге мәкаләдә төрле карашлар күрсәтелсә дә, анда тулаем алганда, чынбарлык дөрес яктыртылмаган. Иң беренче нәүбәттә, автор татар халкының тарихын бозып, аңа ихтирамсызлык күрсәтә. Ул татарлар хәзерге туфракны 500 ел элек яулап алганнар һәм соңыннан ислам динен кабул иткәннәр, дип яза. Тарихи чыганаклардан мәгълүм булганча, безнең ата-бабаларыбыз инде IY гасырда ук Идел буенда төпләнә башлаганнар, ә 922 елда исламны кабул иткән Казан татарларының беренче дәүләте булган куәтле Болгар ханлыгы барлыкка килә. Ярый, автор тарихны начар белә, дип уйлыйк. Әмма аның «республиканы реформалардан читтә калдырырга» омтылган Татарстан Президенты эшчәнлегенә биргән тискәре бәясе, шулай ук Татарстан Республикасы икътисады «Русия реформаларыннан калыша» дип әйтүе бик нык гаҗәпкә калдыра. Чыннан да, нигә дип Русия реформаларын эталон итеп алырга әле? Миңа, мәсәлән, алар хаосны хәтерләтә. Сүз унаеннан әйтим, монда «шок терапиясен» тәкъдим иткән Америка киңәшчеләренең дә гаебе аз түгел.

---

АВЫЛЫ БАРНЫҢ КАВЕМЕ БАР

Әхәт ГАФФАР

# КӘГЪБӘ БОДАЕ

Олы Елга авылындагы «Кама» күмәк хуҗалыгының бер басуында кыр иңләп тугыз комбайнның ашлык урып бетереп йөргәнен күргәннең соңында рәисләре — аксакаллардай акыл иясе, чын хуҗа Хәким Кәримуллиннан:

— Боларның ничә ай буена хезмәт хакы алганы жук. Нимә дип эшлиләр соң? — дип сорадым.

Ул сабыр гына:

— Үзләре беләләр инде, — диде. — Күрәләтә кырда калдырсыннармыни? Үзләренеке ич.

«Нинди үзләренеке?» — дип уйласам да, эчемдәгеп әйтми калдырдым. Әҗерләрен әз-мәз бирделәр инде бирүен. Тик бит... тик бит... Шуннан алда гына идарәләре төбендә ир-ат белән сөйләшеп торганыем. Сабыр алар. Әх, сабыр да соң.

Ә ничә ай тиешле акчаларын кытыршы учларына йомарлап чыгып киткәннәре, «Менә булды. Иншалла, җитеп торыр әле!», дигәннәре юк бит.

Ярар. Сәфәремне дәвам итеп, ары киттем. Лаеш районына — Имәнкискәгә. Карап йорим. Әзмәвердәй эре сөякле, кырыс та, көләч тә рәисләре Рифкать Аббазов югарыдан эш кешеләрен көтә икән. Мин ары-бире боларның ындыр табагында сорашкан-белешкән, халык белән сөйләшкән арада килеп тә төштеләр. Иң әүвәл араларындагы гыраадирдай берәүсе – ак чәчле, комач йөзле, гадәттә мин авылларга чыккалаганда кешечә булмас дип элми торган «женси» ыштан кигәне, килеп төшү белән мине шатыр-шотыр фотога төшерергә тотынды. Ул арада утырып килгән машиналарыннан кукуруз чәкәннәре соратып алды да, кулыма тоттырып, тагын шылт та мылт сурәтемне алды. Кырлар, басулар, ындыр табаклары, болыннар буйлый торгач тәмам уңып беткән кара түбәтәем комачтай кызарып чыкты дип торам. Хикмәти Хода танышкач, белгән кадәре ике-өч татарча әйткәне соңында гына сүз катты ул:

– Әхәтҗан, яз! — диде.

Бу – Гельмут Коль янсә бездәге вице-премьер, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Фатыйх Сибагатуллин зурлыгындагы олпат адәм заты – кукуруз игүче «Пионер» фирмасының эш башкаручы баш директоры Велимир Недельковић булып, аны әлеге оешманың Татарстандагы координаторы Таһирҗан Әхмәев, «Кукуруза» дигән фәнни-житештерү системасы җитәкчесе Барый Садыйков озатып, басуларны күрсәтеп йөри икән.

Аны-моны сөйләшеп торгач, тегe Велимир әфәнде миңа:

Яз, – диде. Кукуруз – яшәү ул

Хәлбуки, без фәкыйрьләрнең ул кукуруздан гайрәте тәмам чиккән иде инде (Безнең халыкта кукурузны икенче төрле «Кәгъбә бодае» дип тә йөртәләр). Ни үзебездә, ни Кара диңгез буенда, ни Балтыйк буйларында, ни бәгъзе чит илләрдә йөргән чакларында урамнарда пешерелгән чәкәннәрен саталар иде. Кызык өчен генә берзаманны алдым да, кимереп карагач, төкереп аттым. Ияләшенмәгән тәм. Хрущев заманында әти Казаннан ипи алып кайта иде дә: «Кукуруз кушканнар, хәерсезләр», — дия торган иде. Авылда әти-әнигә печән чабып кайту тыелган заманнарда печән булсынга бөтен кукуруз басуын без — трусиклы малайлар, күлмәкчән кызлар — бушлай утый торган идек. Безне аннан да пыр туздырып кудылар. Аның каравы Татарстан радиосыннан болайрак җырлаганнарын берегез дә онытмагандыр әле:

**Җәй буена карга кудым**
**Кукуруз басуыннан...**

Яки бүтән бер җыр:

**Үсә кукурузларым,**
**Соям ферма кызларын...**

Ярый... Соңгы биш-алты елда җөмһүриятебез Президенты да, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры да «кукуруз» дип бик күп сөйли башладылар. Соң, җәмәгать, «кукурузчы» Никита Хрущевны шул кукуруз аркасында бетермәделәрмени? Валюнтарист! Ул аны төньякта да үстерттереп, АКШның Айова штатын уздырып җибәрттермәкче иде. Бактың исә, шул кукуруз аның башына житкән бер иген булды түгелме? Сәясәте дә бар иде барлыкка, тик авыл агае аны кукуруз иктереп азаплаганы өчен яратмады булса кирәк.

Бактың исә, ул һич тә җүнсез булмаган икән бит. Велимир әфәнде Недельковичның: «Кукуруз — яшәү ул!» — дип, сәгать ярым армыйча потык сөйләве бик кызык булды. Лаеш районының «Державино», Имәнкискәдәге «Маяк», Кече Елгадагы «Кама» хуҗалыклары, Балык Бистәсе районына караган Олы Елгадагы «Победа» күмәк хуҗалыгының кукуруз басуларын ул яратып, шатланып карап йөргән, машинага чәкән үрнәкләре тутырган.

— Алтын бу, — диде ул. — Әйт, язучы, кайсы иген гектардан 600-800 мең долларлык уңыш бирә ала?

Шуңа күрә В.Недельковић елның 250 тәүлеген төрле илләрдә, озак сәфәрләрдә йөреп үткәрә икән. Һәр кыйтгада була, һәр айны Америкага барып кайта. Һәр елның 60 көнен хәзер Татарстанда үткәрә, эшли, йөри, элемтәләрне яңарта. Таһир Әхмәев тә быел 20 көн буена Австриядә Недельковић әфәндедә булып, байтак фермерлар белән танышкан, кукуруз игүдәге тәҗрибәләрен өйрәнеп йөргән. Хәзер үзебездә аларның ысулларын гамәлгә кертү уе белән янып яши, эшли.

— Кукурузны кайда белеп үстерәләр, Велимир? — дип сорадым.

— Татарстанда, Татарстанда инде...

Һәм өстәп куйды:

— Кукуруз — арзан ит, май, сөт, йомырка ул, — диде. — Дөньяда иң яхшы май — кукурузныкы.

Барый Садыйков:

— Көнбагыш, зәйтүн мае түгелмени? — дип сорады. Дөрес ич инде, без шуңа күнеккән.

Ә Велимирның үз туксаны туксан:

— Яз, — дип ишарәләде. — Иң яхшы шикәр — кукуруз шикәре. Америка шикәрнең 53 процентын кукуруз фруктозыннан ала. Кока-кола нигә бөтен дөньяны баскан? Ул да фруктоза белән баллылана. Шуңа күрә ул шикәрнекеннән йөз тапкыр татлырак Кукуруз спирты Айова штатындагы бензинның 60 процентын гәшкил итә. Шулай итеп, кукурузның мөмкинлеге иксез-чиксез.

Аның сүзен Таһир Әхмәев куәтләде:

— Уэллс әйткән: «Кукуруз — хәерчелек белән ачлыкка каршы торырдай бердәнбер чара», — дигән.

— Әнә, — ди Велимир, — чаралары булмагач, Япониядә 100 грамм ит 50 доллар тора. Ә кукуруз уңышы ризыкны арзанайта, бәясен җайлап, көйләп тора.

Беләсезме, Имәнкискә, Кече Елга басуларындагы алтындай чәкәннәрне, читтән караганда аралары тарак тешләренә охшаган туп-туры, тип-тигез рәтләрне карап йөргәндә, Велимир Недельковичның мактау сүзләрен ишеткәндә, үз эшенә канәгать горурлануын күргәндә «Без дә төшеп калган малайлардан түгел бит әле, рәхмәт төшкере!» – дип уйладым.

Велимир аерата татар халкының эшчәнлеген, кунакчыллыгын зур рәхмәт хисләре белән рухланып сөйли, Президент Минтимер Шәймиевнең алдан күреп, акыл белән эшләвен кайта-кайта әйтә. Чыннан да, венгр-мажарларның «Скандия» дигән гибрид яки үтә дә тиз өлгерә торган «Пионер» сортларын шушылай җиренә житкереп эшкәртә, үстерә белгән Имәнкискә механизаторы Газинур Шәрәпов кебекләр булганда, кунаклар гәпләшкән чагында тыйнак кына елмаеп торган өр-яңа рәис Рифкать Аббазов барында җөмһүриятебезнең авыл хуҗалыгы өчен тыныч өмет белән рухланып торасың икән ул, җәмәгать!

Балта остасы. Э.ЗАРИПОВ рәсеме.

# Әйдә, Этнә, атла алга, даның китсен еракка!

Этнә яклары гаҗәеп матур. Юллары да такыр хәзер. Әле үргә менгән, әле түбән таба йөгергән асфальт тасманың як-ягында игеннәре җыеп алынган басулар нингидер моңсулык тарата, яңа тишелеп чыккан хәтфә уҗымнар күзне иркәли. Тау итәгенә сыенып утырган җыйнак авыллар сиңа сәлам биреп кала.

Этнә ягы — пөхтә һәм кунакчыл як. Бу төбәктә татарлардан башка бүтән милләт вәкилләре яшәми. Кайсы гына авылга сугылма, һәркайсында чәйгә чакыралар. Туфраклары бик уңдырышлы булмаса да, халкының тырышлыгы нәтиҗәсендә этнәлеләрнең тормышына, тьфү-тьфү, күз тимәсен. Кайсы гына авылга килеп кермә — аның үз йөзе, үз тарихы. Күлле-Киме урта мәктәбендә Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәким музее оештырылган. Музейны оештыручы, яңа экспонатлар җыюда бар көчен куйган мәгариф отличнигы Луиза Шәмсиева биредә 40 ел әдәбият укытучысы булып эшләгән.



Ул шагыйрь турында сәгатьләр буе сөйләргә әзер.

Менә без район үзәгендә. Балалар китапханәсе — укучыларның иң яраткан урыны. Биредә утыз мең китап бар, ә китапханәгә ел саен мең ярымнан артык укучы йөри. Китапханәче Җәүһәрия Мәрдәнова һәркемне кызыксындыра белә, һәркемгә яраткан китабын табарга булыша. Җәүһәрия Гайнулла кызы (өстәге рәсем) Этнә халык театрының иң күренекле артисткасы да. Ул күп спектакльләрдә баш рольләрне хәтта кайбер профессионаллар көнләшерлек итеп башкара ала. Аңа Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем әнә шул фидакарь эшләре өчен бирелгән.



Гомәр Мәрдәновны (астагы рәсемдә) районда белмәгән кеше юктыр: ул 1959 елдан алып халык театры режиссеры булып эшли. Гомәр Ханнан улы сәхнәгә куйган «Миңнекамал», «Гармун уйныйм», «Уракчы кыз» һ.б. бик күп спектакльләрне халык яратып кабул итте. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Гомәр Мәрдәновның мәдәният өлкәсендә эшли башлавына 9 сентябрьдә 50 ел тула. Аны чын күңелдән котлыйбыз һәм иҗади уңышлар телибез!

Муса Җәлил исемендәге күмәк хуҗалыкның иң хөрмәтле кешесе кем? Тимерче Сәгъдулла Закиров, әлбәттә. (Өстә, уңдагы рәсем). Юк, ул гади тимерче генә түгел — рәссам да. Үз өенең капкасын, диванын үз куллары белән бизәкләп-нәкышләп ясаган. Бу көннәрдә Сәгъдулла абзыйга 65 яшь тула, әмма ул һаман эш белән мәшгуль. Рәсемгә төшерү өчен без аны ындыр табагыннан алып кайттык.

Түбән Көек авылы мәчетенең үзенә күрә кызыклы тарихы бар. Күп еллар элек манарасын кисеп, аны клуб иткәннәр. Соңгы елларны авыл халкын алыштырып куйдылармыни — «Долой клуб! Мәчет давай!» дип даулый башлыйлар. Клуб шулай яңадан ике манаралы өр-яңа мәчеткә әйләнә. Указлы булмаса да, муллалары бар хәзер, теләгән кеше иркенләп җомга намазына йөри. Авыл нурланып китте.

Фотообъектив Гөлбикә әби Лотфуллинаны оныгы Илгизәрне колхоз көтүен көтәргә җибәргәндә «эләктергән». Тырышып эшлә, улым!

Инде сезне Люция Әхмәтҗанова белән дә таныштырыйк (астагы рәсем). Һөнәре белән укытучы, хәзер район советы рәисе урынбасары. Җиңел аяклы, җиңел сөякле кеше. Без танышканда пыр туздырып Казанга ярминкәгә бару мәшәкатьләрен көйләп йөри иде.

Эш сөючә күркәм Этнә халкына уңышлар, сәламәтлек телибез.

**Әсрар ШАКИРҖАНОВ.**
**Автор фотолары.**

ТАТАРНЫ МОҢ ЯШӘТӘ

Кояш ТИМБИКОВА

# Әчкә сыймас

Әдәбият һәм сәнгать әсәрләренең миңа иң нык тәэсир иткәне, мөгаен, жырдыр. Аларның да халык жырлары дип йөртелгәннәре. «Халыкныкы», дигән тә, аны бит, башлап, берәү чыгарган инде. Үз исемен әйтергә, жырчыга бирергә яки матбугатта бастырырга гына «башына килмәгән»: Аның жыры телдән-телгә, күңелдән-күңелгә күчеп, үзгәрә, шәбәя барган. Тәмам сәнгать әсәре дәрәжәсенә үсеп житкән. Шулай булмаганда, халык жырлары дөнья буйлап яңгырар идемени?! Бу жырларда безнең гомуми кичерешләр, үсеш баскычларыбыз, бөтен тарихыбыз чагыла. Бик борынгыларына әллә ни тукталып тормыйча, үземне сихерли башлаган жырларга гына игътибар юнәлтәсем килә, ягъни сугыш чоры һәм аннан соңгы бинихая кыен дәвердә яңгыраган жырларга.

Никадәр генә кыенлыклар кичерелсә дә, ул еллар минем күңелдә ифрат якты истәлекләр калдырган. Бик борынгы татар авылы. Жәйге кич. Иртән көтү озатудан башлап кичке эшләрне түгәрәкләгәнче (су ташулар, бакчадагы чүп үләнен утаулар, терлекләрне каршы алу, аларны эчертү-ашату һ.б.) шактый йончылган. Картларның бер ише намазга осган, кайберләре яту-йоклау хәстәрен күрә башлаган. Минем ике апа исә мыштым гына клубка чыгып сызу ягын чамалыйлар. Әти аларга гына чыгарга рөхсәт итә, миңа, әлегә, бу юл бөтенләй тыелган. Мин иркен чоланыбызның киң такта караватына урын җәям, сукыр лампаны көйлим дә кулга китап алам. Китапны әтидән яшерәм, чөнки ул минем әле генә китапханәдән алып кайткан әсәрне өнәмәде. Бу — Лев Толстойның «Яңадан туу» романы. Мин бит әле икенче классны гына тәмамлаган. Минем яшьтәгеләргә Масловалар язмышы белән танышырга рөхсәт юк. Яшереп укыйм.

Бераздан авылның төнге сәнгати тормышы башлана. Мин китабымны куям, утны сүндерәм. Чолан түбәсендәге тишектән ай нуры гына күренә. Кеп-кечкенә якты бер нокта ул. Мин шул яктылыкка күз текәп көтәм.

Ниһаять, башлана! Иң әүвәл аръякта яшәүче Нәжметдин абый сыздырып жибәрә. Шуны гына көткән кебек, түбән оч малае, минем классташ Сәгыйть гармунының тавышы ишетелә, аннары бездән ерак түгел генә яшәүче Әпсәли бабай улы Шәфукъ... Авылның айлы төненә адәм баласы чыдап тора алмаслык авыр хезмәт көнен уздырган ир-егетләрнең иске гармуннарыннан моң еибелә. Моны караңгы чоланда тыңлап ятуның ни-нәрсә икәнлеген икенче берәүгә аңлату мөмкин түгел. Мин моны үзем дә хәзер генә тоеп бетерәм кебек әле. Шунысы хикмәтле: гармунчыларның өчесе дә бер үк көйне суза, әмма — өчесенеке дә үзгә, берсенекеннән-берсе моңлырак. Мин беләм инде: алар клубта да, күп очракта, өчәүләшеп уйныйлар. Берсен-берсе тулыландыралар. Чөнки күргәнем бар. Олы апам өйдә юкта, уртанчы апам клубка жыена башласа, әти-әни мине дә аңа ияртеп жибәрә. Авыл яшьләре элекке мәчет бинасындагы клубта иркен бер мәйдан булдыралар. Өч гармунчы өчесе өч якта урын ала. Иң түргә аръякта яшәүче дөм-сукыр Исмәгыйль абыйны утырталар. Ул — скрипкачы. Беренче чыгыш аныкы. Исмәгыйль абый бик бирелеп, һәркемнең үзәгенә үткәрерлек иттереп борынгы бер көйне сыза. Ай ул көй, ай ул моң, ай ул скрипка! Бу көйне минем әнием яхшы белә, бәйрәмнәрдә сәхнәдән дә жырлый, өйдә дә сузгалый, шунлыктан мин сукыр скрипкачы уйнаган жайга, эчтән генә, шул сүзләрне әйтеп утырам:

... Жанкай-жанаш киттә, ай, сунарга,
Ашказаркай буена чәшкегә.
Чәшкеләргә китеп, вафат булды,
Башкынаем калды ла яшь кенә...

Гармунчыларыбыз исә замана жырларын хубрак күрә иде. Әй бу халыктагы моң, без мәңге аңлап-бәяләп бетерә алмаслык осталык! Алар, әлеге гармунчылар, һич тә уйлап-нитеп тормыйча гына, теләсә нинди көйне башламыйлар иде. Һәммәсе замана мәшәкатьләренә, шул чор кешеләренең кичерешләренә авазадаш. Бу дәвернең биш-алты еллары эчендә генә дә илнең бөтен тарихын эченә алган берничә көй белән алар авыл халкының уй-фикерләрен, кайгы-хәсрәтләрен күкләргә яңгыратып яшәделәр.

Сугыш чорының башлангыч афәтен, минемчә, безнең авылга «Идел» жыры ачып бирде. Хәзер әлеге жырны, ниндер, «Су буйлап» дип йөртәләр. Бездә ул — «Идел». Һәм мин аның ни өчен шулай аталганын да беләм шикелле. Минем район Чулман буена урнашкан. Аны халык, зур су булганга, барыбер Идел дип йөртә. Сугышка чакырылганнарны Чулман буйлап йөзүче баржаларда озаталар иде. Һәм бу озатулар йөрәкләргә кан саудыра. Минем абыйны да, унжиде яшеннән, шул якка алып киттеләр. Чистай пристанена. Беренче көнне, бер арбага төялеп, бөтен гаиләбез белән аны озата киттек. Тик тиешле баржа килеп житмәгән икән. Булачак солдатлар яр буенда калды, без Чистайдан ун-унике чакрымдагы авылыбыз Наратлыга кайтып киттек. Әти икенче көнне, кайнар аш алып, тагын пристаньга юнәлде. Өченче көнне дә... Тик бу юлы әни пешереп жибәргән аш кире кайтты, абыйларны озатканнар, әти барып өлгерә алмаган икән. Бусы — мин белгән кадәресе генә. Мондый аерылышулар меңнәр башыннан, ничәмә-ничә аналар йөрәге аша узган бит инде. Һәм менә... «Идел» жыры.

... Идел бит ул, тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул.
Караңгы төн, болытлы көн —
Без аерылган көн бит ул.

«Идел»не тыңлап та, жырлап та туймаган идек әле, авылга яңа жыр кайтты: «Кошлар көе». Аны замана түрәләренең таләбенә туры китереп, төрлечәләп жырлап йөрделәр. Әмма безнең Иске Роман авылында бу жыр улын канлы сугышка озаткан ана белән аяусыз көрәштә жан тартышкан баланың үзара сөйләшүе кебек яңгырый иде:

... Һаваларда очкан кошкайларның
Канатлары жиргә кадалды.
Сугыш кырларында ятып калгач,
Канлы гәүдәләрең кем алды?

Бу сорауга ят-чит жирләрдә әсирлектә интегүче бала жавап бирә кебек:

... Һаваларда очкан кошкайларның
Каурыйлары косла жилләрдә,
Туфрагына алтын сипсәләр дә
Житми икән туган илләргә.

Сугышлар тәмамланып, жаннарга өмет чаткылары кунгач, жырларның күңелләләре дә чыга башлады: «Шомыртым», «Арча», «Ачлады тәрәзәнне!» һ.б. Без аларны да яратып тыңлый идек, үзебез өчен генә рәхәтләнеп жырлый идек. Әмма моңлы-сәрле жырлар күңелләрне ныграк били, аларның тәэсире тирәнгәрәк үтә кебек. Шул ук елларда, инде сугыш афәте суына төшкән бер дәвердә өр-яңа бер жыр яңгырады. Мин, аны әлеге караңгы чоланда беренче тапкыр ишеткәч, урынымнан сикереп торып утырдым. Аны да авылыбызның иң мөхтәрәм гармунчылары, өчесе бер булып, бер үк көйгә уйнап жибәрделәр:

... Уфалардан кайткан акбуз атны, Рамай
Аккаенга бәйләп куйсыннар!
Бергә тумасак та, бергә үстек, Рамай.
Каберебезне бергә куйсыннар!

Йа Аллам, тагын ни булган?! Адәм балаларын хәсрәткә салуда бер сугыш кына да сәбәпче түгел, күрәсең...

Жыр дигән сихри көч менә, әнә шул рәвешле, сабый чактан ук әсир итте. Хәзер беләм: әлеге юлларны укучы зур белгечләр, музыка дөньясын тирәннән аңлаучы композиторлар мыек астарыннан гына көләләрдер. Чөнки жыр — музыка галәмендәге иң кечкенә бер утраучык кына ул. Шуңа да олуг композиторларның байтагы аның белән шөгыльләнмиләр дә. Күбрәк опера, балет, симфоник оркестр яки орган өчен язылган әсәрләр, һич югында, оратория ижат итәргә тырышалар. Мондый зур күләмле, аеруча тирән мәгънәле, гадиләргә бик үк аңлашылып та житми торган музыка авторларга дәрәжәне дә тизрәк китерә шикелле. Минем дә Ригада, Аурупаның кайбер илләрендәге зур залларында да орган концертларын тыңлап сәерсенеп утырганым бар. Мөмкинлек чыкканда балетыннан да, операсыннан да, симфоник оркестр чыгышларыннан да коры каласым килми. Әмма жыр!.. Бигрәк тә моңлы жыр — могжиза!

Ригада миңа Балтыйк буе халыкларының жыры турында мондый бер кыйсса да сөйләгәннәр иде. Ерак елларда бу илләрне дошман басып ала, халкын кол итә, хәтта үз телләрендә сөйләшүдән, милли киемнәр киюдән дә тыя. Бер уч халык нишләсен? Баш газиз — ризалашалар. Илнең аксакаллары гына баскыннардан бер рөхсәт сорап карарга җөрьәт итә:

— Без барысына да риза, — диләр алар. — Тик сез безгә елга бер генә мәртәбә жыр бәйрәме уздырырга, шунда, барыбыз бергә жыелып, жырларга рөхсәт итә алмассызмы?

— Әйдә, жырларсыз, тик ел буе безгә бил бөгәчәксез! — дип жавап бирә тегеләре.

Буйсындырылган халык ел буе әнә шул жыр бәйрәменә әзерләнеп яши. Төннәр буе утырып милли киемнәрен тегәләр, чигәләр, жырлый-жырлый челтәр бәйлиләр. Ә теге жыр бәйрәме якынлашыр алдыннан, жәяүләп башкалага юнәләләр, атналык юлда һаман жыр сузалар, берләшә баралар, жырларының матур, гомум яңгырашына ирешәләр.

Һәм нәтижәдә дошман чигенергә мәжбүр булганнан соң шунысы ачыклана: аларның милли гадәтләре дә, телләре дә, бердәмлекләре дә сакланып калган!

Әнә нинди могжиза тудыра ала ул жыр! Безнең халыкның да бөтен тарихы — жырларда. Композиторларыбызның да иң халыкчаннары жырны ят күрмәделәр. Аларның кайбер әсәрләрен халык үзенеке итте: авторын-фәләнен сорап-нитеп тормыйча суза да суза. Бигрәк тә Ж.Фәйзи, Х.Вәлиуллин, Р.Яхин, М.Мозаффаров, А.Ключарев, З.Хәбибуллин, Ә.Бакиров һәм, әлбәттә, Сәйдәш белән Сара ханым көйләре халыкка якын. Яшьрәк композиторларны санап тормыйм. Шөкер, алар күп. Без бай.

Жырларның халыкка ни өчен шул кадәр тәэсирле булуын ачыкларга теләгәндә, миңа үз язмышыма бәйле тагын бер хәлгә тукталырга туры килә. Алдан ук шуны әйтеп куйыйм: һәр жыр авторларның ифрат зур тырышлыгы, фидакарьлеге нәтижәсендә генә туа. Бу хакыйкатьне мин «Азат хатын» журналында эшләгәндә ачыкладым.

Мәгълүм ки, бу журнал бик күпкырлы. Мин анда эшләгән елларда редакциянең ике-өч хезмәткәренә дүртәр-бишәр бүлекне житәкләп алып барырга туры килә иде. Баш мөхәрриребез Асия Хәсәнова миңа, мәсәлән, промышленность, спорт, төзелеш, тегү-чигү, партия һәм... сәнгать бүлекләрен тапшырды. Әмер биргәндә аңлатты: «Беренче санаганнарым шактый четерекле һәм дә житди эшләр, шуңа күрә, бераз күңеллерәк булсын өчен сәнгатьне дә өстим», — диде.

Сәнгатьтәге «күңеллелекләр»нең ни икәненә мин бик тиз төшенеп алдым. Тездән резин итек киеп, бетон түшәүче төзүчеләрме, ут эчендә корыч коючы завод эшчеләреме, әллә артист яки композиторлармы, әгәр ихластан тырышалар икән, — боларның һәммәсенә бик авыр. Мин шуны аңладым. Бу урында әдәби әсәр язучыларга, сәхнә образы тудыручыларга тукталып тормастан, алдан әйткәнемчә, жыр ижатчыларына гына игътибар юнәлтәсем килә.

Жыр — күмәк ижат нәтижәсе. Монда шагыйрь, композитор һәм жырчы катнаша. Өчесендә дә ифрат зур жаваплылык. Сүзгә лаек көй, ул көйне жаны-тәне белән бирелеп башкаручы жырчы һәм әле тагын жырчы белән композитор ижатын куәтләп торучы музыкант та кирәк. Ата — улны, ана — кызны белмәгән бу жәмгыятьтә дүрт ижат кешесенең уртак телгә килүен булдырып кара әле син?!

Бәхеткә, безнең жыр сәнгатендә андыйлар шактый икән. Моң аларны дуслаштыра, берләштерә, аларга дәрәжә китерә. Әйтик, М.Ногман белән Р.Яхин, С.Садыйкова белән С.Хәким, Г.Зәйнашева, И.Ганиева һәм башка бик күпләр, С.Сәйдәшев белән М.Садри, М.Хөсәен... Бу авторлар бер-берсе белән тәмам туганлашып беткәннәр иде. Хәтта М.Ногман белән М.Хөсәеннең Язучылар берлегенә әгъзалыкка кабул ителүенә дә әлеге мөхтәрәм композиторларның жырлары зур роль уйнады кебек. Чөнки язучылар оешмасында шундый бер кырыс чор булып алды — унар-унбишәр китап чыгарган авторларны да әгъзалыкка алмый

# Җырга чыга

интектерәләр иде Җыр исә аларны халыкка барыбер танытты, аларның Язучылар берлегендә түгеллегенә берәү дә игътибар бирми башлады һәм .. аксакаллар чигенергә мәҗбүр булдылар.

«Азат хатын» журналы исә 60 нчы еллардан башлап татар җырын таратуда үзеннән зур өлеш кертте. Монда борынгы җырларга кабат кайту тәҗрибәсе дә, иң оста композиторларның яңа әсәрләрен укучыга җиткерү дә, һәвәскәрләр иҗаты да, башкорт, казакъ, хәтта урыс композиторларының киң таралган әсәрләрен бастыру да — һәммәсе көн тәртибендә торды.

Көннәрнең берендә редакциягә иң актив җыр язучыбыз Сибгат ага килеп керде. Сизелеп тора: кәефе юк. «Ни булды?» — дибез. Ул, гадәтенчә, сабыр гына, салмак кына аңлатырга тотынды:

— Менә-ә, м-и-и-ин, әле генә-ә композиторлар белән бергә Алмаз Монасыйпов язган «Тукай ритмнарында» дигән җиде җырны тыңладым...

— И-и! — дип күтәреп алдым мин. — Менә шәп, Тукайның 90 еллыгы уңаеннан берәрсен бастырырга иде! Шәпме соң, Сибгат ага? — дим.

— Шуңа хәйран калдым да шул: берәү дә күтәреп алмады. Композитор үз ихтыяры белән, бер тиен акча сорамыйча, бер кочак җыр язган, җырчыга өйрәткән, монда килеп, тыңлау оештырган... Хуплаучысы юк...

— Барысын да кызык итәбез! — диде мөхәрриребез Асия ханым. — Алар теләсә нишләсен, ә без бастырабыз да чыгарабыз!..

Һәм шулай эшләдек тә. Сибгат ага кереш сүз язды. Һәм журнал җырларны бастыра башлады. Аларның барысын берьюлы биреп бетерү мөмкин түгел иде, шулай да без эзлекле рәвештә бу кызыклы әсәрләрне укучыга җиткердек. Алар арасында хәтта «Өзелгән өмет» тә бар иде. Аны халык «Тәфтиләү» дип җырлый бит инде. Әмма Монасыйпов «Өзелгән өмет»не тулысынча файдаланган. Әлеге җыр журналның биштән бер өлешен биләп алды (1976 ел, 4 сан), шулай да без бик шат идек. Сибгат аганың «Тукай көтә» исемле мәкаләсендә исә (1975 ел, 10 сан) композиторның бу әсәрләренә зур бәя бирелгән иде: «...Тукай катлау-катлау, — дип язды ул. — Композитор Алмаз Монасыйпов әнә шул катлаулы кичерешләр дөньясына кергән, курыкмый, кыю рәвештә кергән... Барлыгы җиде җыр, җидесе җиде төрле...»

Әлеге төркемнән «Безнең авыл» җыры аеруча киң таралды.

Җырларның язылу тарихы да, халыкка барып ирешүе дә төрлечә була. Мәсәлән, Хөснул Вәлиуллинның Рәшит Әхмәтҗанов шигыренә язылган «Акчарлаклар» җыры кайсыбызның гына күңелен кузгатмый икән?! Тик аның язылуына мөхтәрәм язучыбыз Гариф Ахунов сәбәпчедер дип башыбызга да китермибез бит. Гариф абый Шәриф Камалның «Акчарлаклар» әсәрен сәхнәләштерергә алына. Җыр кирәк булып чыга. Һәм ул үзе якын күргән яшь шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановка шул вазифаны йөкли. «Акчарлаклар» спектаклен хәтерләүчеләр бардыр, яхшы ук килеп чыккан иде ул. Әмма Рәшитнең җыры, үзәк өзгеч әсәр булып, мөстәкыйль рәвештә дә яши. Аны драма сәхнәсендә беренче мәртәбә Нәҗибә ханым Ихсанова башкарган иде. Оттылар да алдылар бит башка былбыллар Зәйтүнә Әхтәмова, Клара Хәйретдинова һ.б.лар әле дә булса, берсеннән-берсе уздырырга тырышып җырлыйлар.

... Сез китмәгез, акчарлаклар,
акчарлаклар!
Чит җирләрдә каерыла
пар канатлар...

Җырның могҗизави көче гомер буе чәчмә әсәр язучыларны да әсир итә. Мин монда сәхнә сәнгатенә гашыйк әдипләребез Т.Миннуллин, М.Әмир, Х.Вахит һ.б.лар тарафыннан язылып, киң таралыш-яңгыраш алган җырларга тукталып та тормыйм. Халык әйтмешли, чеп-чи прозаикларның да берән-сәрән, әмма шактый үтемле җырлары укучыга-тыңлаучыга яхшы таныш. Әйтик, Г.Әпсәләмовның «Гөлшаһидә җыры» кемнәрнең генә үзәген өзмәгәндер?!

... Ак күңел, пакь күңел,
Бу кадәр ярсыма,
Тилереп-шашынып,
Дөньяны тарсынма!
Син чыда барсына.
Сөюең хакына,
Ул килер, баш ияр
Бер заман каршыңда.

Мактанып әйтүем түгел, Гомәр ага Бәширов белән Сара апа язган «Җидегән чишмә»нең «Азат хатын»да (1977 ел, 12 сан) басылып чыгуына да минем катнаш тиде. Җырны Сара апа язучыларның айсаен уздырыла торган җыелышы алдыннан уйнап-җырлап күрсәткән иде. Мин аның янына килдем дә тиз арада редакциягә ноталарны китерүен үтендем.

— Әнә Гомәр абыеңнан рөхсәт ал, ул бик четерекле кеше, — диде Сара апа.

Бергәләп сөйләштек. Гомәр абый каршы килмәде. Берничә көннән җырның сүзләре дә, нотасы да безнең кулда иде, тик... Ул еллардагы гадәт буенча, җырны махсус сәяси тикшерүчегә күрсәтү кирәк булып чыкты. Соңгы строфага бәйләнәләр генә бит. «Бу ни дигән сүз? — диләр, «йөзек», «улак», «сөю» турында матур гына сөйләнә дә, «Без китәбез ерак илләргә», дип бетереп куялар. Моны ничек аңларга? Кем китә, кайсы илгә?»

Сара апа белән сөйләштем. Башта ул дулады. Янәсе, аның сүзләргә катнашы юк, шигырь авторы белән сөйләшергә кирәк, инде болай да Гомәр абый белән бик озак бәхәсләшкән, ниһаять, уртак фикергә килгәннәр, башкача ул һичнинди үзгәрешләргә дә риза түгел. Миңа олуг әдипнең үз хозурына барудан башка чара калмады. Ә ул, тыңлап-тыңлап торды да, шигырь сүзләрен үзгәртүдән баш тартты. Шигъриятне киңрәк аңларга кирәклеген, «башка илгә китү»ләрнең һәрбер адәм баласының башына төшәчәген искәртте. Аксакал, әлбәттә, хаклы иде. Бәйнә-бәйнә шул хакта сөйли торгач, «ерак илгә китүнең» ни икәнлеген «бәйләнчек» тикшерүче — мәрхүмәкәй Даимә ханым да сизәмләде. Рөхсәт бирде.

Чәчмә әсәр иҗат итүчеләрдән Фатих ага Хөснинең «Кошлар тынды» җыры да (Хөснул Вәлиуллин музыкасы) бәгырьне айкап ала:

..., Әллә нәрсә булды, күңелем
тулды,
Әйтер сүзем әйтә алмадым.
Аерылышу шушы булган икән —
Мин соңыннан гына аңладым.

Прозаикларның аеруча хискә бирелеп киткән мизгелләрендә нәкъ менә җыр жанрына мөрәҗәгать итүе миңа яхшы таныш һәм аңлаешлы. Үзем дә, күңелем өзгәләнгән чакларда, берничә җыр яздым. Башта миңа Сара ханым Садыйкова белән дуслык-нык ярдәм итте. «Авылдашлар», «Синсез язлар миңа кирәк түгел» исемле җырларымны ул хуплап кабул итте, көйгә салды, җырчыларга өйрәтте, радиога яздырды. Аннары Луиза Батыр-Болгари, Ганс Сәйфуллин белән бергәләп «Җибәрмә син мине», «Яңа Чишмә»» җырларын иҗат иттек. Сара апа көйгә салып өлгермәгән бер җырым ятим калган иде. Көннәрдән бер көнне телевидение мөхәррире Эльмира Хамматова мине бер тапшыруга чакырды. Сүз иярә сүз китеп, мин аңа яна бер җырымның да барлыгын әйтеп куйдым.

— Көйне кем язды? — ди Эльмира ханым.

— Әлегә язылып ук бетмәгән бугай, өр-яңа тәҗрибә йөзеннән Вафирә ханым Гыйззәтуллинага тәкъдим иткән идем, — дип әйтеп куйдым мин.

Тапшыруга берничә генә көн калган иде инде. Әшнең бик җитди төс алуын аңлап Вафирә дустым баштанаяк иҗатка чумды. Озак та үтмәде, нәкъ Сара апа кебек, телефоннан ук җырлап та күрсәтте.

Ихластан әйткәндә, мин Вафирәнең беренче талпынышында ук миңа бик нык тәэсир итәрдәй җыр чыгара алуына шикләнебрәк караган идем. Хәйран калдым, елый-елый тыңладым. Мин әлеге җырның сүзләрен, замандашларымның алдавыч елларга эләгүен, адәм баласы гомеренең ифрат кыскалыгын күздә тотып, күңелсез уйланулардан чыгып, яшь аралаш язган идем бит. Җырчымның-композиторымның шул тойгыларны аңлап өлгерүенә чиксез шаккатдым.

Телевизион тапшыруга Вафирә ханым турыдан-туры җырларга дип барды, чөнки алдан язылырлык вакыт калмаган иде инде. Баянчы Рамил Курамшин белән бергә бик уңышлы чыгыш ясадылар. Бу тапшыруда катнашкан дусларыбыз Равил Шәрәфиев, Наилә Гәрәева, Нәҗибә Ихсанова, Ренат Ибраһимов иҗатташлары Вафирә Гыйззәтуллинаны яңа өлкәдәге уңышы белән котладылар. Аннан соң җырчы дустым бу әсәрне Казанда да, башка шәһәрләрдәге концертларында да башкарды инде. Радиога язылырга гына һаман туры килми. Бу мөмкинлекне көтеп тормастан, Татарстан Республикасының халык артисткасы Вафирә Гыйззәтуллинаның яңа уңышын мәдәни атналыгыбыз укучылары игътибарына тәкъдим итәсем килә. Таныш булсыннар: менә ул җыр.

## Кышларга да бергә керсәк иде

**Кояш ТИМБИКОВА шигыре**
**Вафирә ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА көе**

**Язлар безне таныштырган иде,
Язы, җәе узды ваемсыз.
Көзләр җитте, алда салкын кышлар —
Былбылларсыз, бодрә каенсыз.**

**Язлар безне ничек шатландырды —
Гүзәл гөлләр, назлы җил анда.
Кышлар бүтән, зәмһәрирләр көтәм,
Адашмабыз микән буранда?**

**Кышларга да бергә керсәк иде —
Бар теләгем хәзер шул гына.
Тирән кардан мин барырмын алдан,
Зинһар, яннарымда бул гына!**



ХӘТЕР КАЙТАВАЗЫ

# Кем ул Михаил Львов?

Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ

Сугыштан соңгы урыс әдәбиятын, бигрәк тә шигъриятен укып-күзәтеп барган кешеләр әлеге сорауга: «Михаил Львов бик үзенчәлекле һәм киң колачлы урыс совет шагыйре», — дип җавап бирер. Һәм андыйлар өлешчә хаклы булырлар. Ләкин күпләр бу талант иясенең тәрҗемәи хәлен һәм иҗат юлын бөтенләй диярлек белмиләр. Ә Михаил Львовның язмышы да, иҗаты да башкаларныкына һич тә охшамаган. Ул шактый кызыклы һәм гыйбрәтле.

Инкыйлабка кадәр Уфа гөбернәсенең Нәсибаш волосте Златоуст өязенә кергән (хәзерге Башкортстанның Салават районы, Нәсибаш авылы) өяз земствосы әгъзасы, химаячы алпавыт Кропочинский (бездән 40 чакрым чамасы ераклыкта Көньяк Урал тимер юлына карый торган Кропочево станциясе бар. Ул — зур тимер юл үзәге) тырышлыгы белән Нәсибашта земство мәктәбе ачылган булган. Балаларын Аурупа мәдәниятенә якынайтырга теләгән күп кенә татарлар аларны нәкъ менә шушы мәктәпкә бирергә тырышканнар. Мәсәлән, Малаяз авылы мулласы Сиражетдин Закиров та үзенең улы Нәкыйне (булачак Нәкый Исәнбәтне) шул мәктәпкә биргән. Минем әтием дә әлеге земство мәктәбен тәмамлаган кеше. Анда аларга Дәүләтша Габитов һәм аның хатыны Гөлҗиһан дәрес биргәннәр. Бу ике мөгаллим заманында Златоуст каласындагы гимназияне тәмамлаганнар. Дәүләтша абый чыгышы белән бүгенге Зеленодол районының Күгеш авылыннан. Гөлҗиһан апа исә атаклы татар авылы Кыйгыда туып үскән. Бу авыл Степан Злобинның «Салават Юлаев» дигән романында да телгә алына. Кыйгылылар кыю, тырыш һәм бик үзенчәлекле кешеләр. Андагы халык һәр сүзгә диярлек «кый» кушымчасын өстәп сөйләшкәнгә күрәдер инде, авылның исеме дә «кый»дан башланып китә.

**Аръякта да Сидыкый, бир якта да Сидыкый,**
**Чакырдым кый, килмәдең кый, җаннарымны кыйдың кый.**

Әткәй белән әнкәйнең сөйләүләренә караганда, бу ике мөгаллимне халык бик ихтирам иткән. Дәүләт абый белән Гөлҗиһан апа бик тату яшәгәннәр. Яшь гаиләдә бер-бер артлы ике бала туган. Олысына Рәшит, кечесенә Рифкать дип исем кушканнар. Тик Гөлҗиһан апа, кинәт бик каты авырып китеп, һич көтмәгәндә үлеп китә. Балалар ятим кала. Олысына — өч, кечесенә бер яшь тә тулмаган була әле ул вакытта. Язмыштыр инде, Дәүләтша абый базардан алып кайткан затлы гына кеш мехында ваба авыруы микроблары булган. Гөлҗиһан апа аны бер генә көн иңенә салып йөри алган.

Озакламый патша самодержавиесе шымчылары Дәүләтша абыйны революцион түгәрәк оештыруда гаеплиләр. Нәтиҗәдә, ул авылдан сөрелә. Ятим калган балалар төрле кешеләрдә, төрле кулларда тәрбияләнеп үсәләр. Соңрак Рифкать абый үзенең балалык еллары турында болай дип яза:

О, деревенские женщины,
Спасибо вам.
Накормили нас досыта:
Меня и Рашита.

Михаил Львов белән мин беренче мәртәбә 1964 елны очраштым. Аңарчы мин аның безнең авылда укыткан мөгаллимнәр Дәүләтша һәм Гөлҗиһан Габитовлар улы Рифкать икәнен бөтенләй белми идем әле. Авылдашым галим Рашат Гайнанов ачты миңа бу серне. Ул елны бер юньсезе Гөлҗиһан апа каберенә куелган мәрмәр ташны үз баласы каберенә куйган, шуңа әткәйнең бик каты кәефе китеп йөргән иде. Менә шуларның барысы да мине СССР Язучылар берлеге идарәсенә — Рифкать абыйга хат язарга мәҗбүр итте. Аның эчтәлеге якынча менә мондый иде:

«Мөхтәрәм Михаил әфәнде!

Җәйгә безнең Нәсибаш авылына кайтсагыз иде. Без сезгә әниегезнең каберен тәртипкә китерергә булышыр идек».

Озак та узмады, җавап хаты да килеп төште:

«Дорогой Махмут Рахимович!

Ваше письмо глубоко взволновало меня. Спасибо за большое человеческое сердце. У меня нет слов, чтобы передать те чувства, которые я испытал прочтя Ваше письмо. Спова хлынули в душу ощущение своей трагической судьбы, боль сиротства... Современность закружила, закрутила меня. Я созвонюсь и спишусь с Рашитом, и мы летом сделаем все, что в наших силах, для могилы, для памяти матери. Стыдно и горько, но большая часть жизни у меня была посвящена ничтожнейшей борьбе за существование... Разрешите послать Вам одно из своих стихотворений о матери и книгу, в которой тоже есть стихотворение о матери. Я собираюсь в конце декабря прилететь в Казань, тогда поговорим по душам.

С сердечным приветом ваш М.Львов. 25/XI-1964 г.».

Ошбу хат белән Рифкать абый әнисенә багышланган бер шигырен дә юллаган иде.

Ул сүзендә торды. Рифкать һәм Рәшит абыйлар, авыл картлары һәм мин Гөлҗиһан апаның каберен эзләп киттек. Әмма кырык ел эчендә бик күп сулар аккан, бик күп җилләр искән, күпме генә азаплансак та, каберне эзләп таба алмадык. Ә аны белгән кешеләрнең күбесе фронтта һәлак булган, икенчеләре исә инде күптән вафат. Дәүләтша абый үзе исән булса, ярдәм итәр иде дә, тик ул да берничә ел элек кенә фани дөньядан китеп барды. Шуннан соң без өчәүләп Тугызлы авылына (Кыйгы районы) юл тоттык. Андагы зиратка җирләнгән Дәүләтша абыйның кабере матур гына чардуган белән әйләндереп алынган. Кабер ташындагы фарфор плитәгә төшерелгән фоторәсем астында шундый сүзләр бар: «Бу кабердә Башкортстанның атказанган укытучысы Дәүләтша Габитов ята».

Әйе, Дәүләтша абый гомере буе татар балаларына урыс теле һәм әдәбиятыннан гыйлем биргән кеше. Ул көнне бер өйдә Дәүләтша абыйны искә алу мәҗлесе булып узды. Анда Рифкать абый һәркемгә унар сум акча өләшеп чыкты. Тугызлыдан соң без заманында Дәүләтша абый эшләгән берничә авылда — Лаклыда, Еланлыда, Чобаркыяда булдык. Һәр тарафта мәҗлес оештырылды, әмма өстәлгә шайтан суы — аракы кунакламады. Чөнки без өчебез дә хәмерне өнәмәүче кешеләр идек.

Берничә сүз белән генә Рәшит абый хакында да әйтеп узарга кирәктер. Ул да нәкъ Рифкать абый кебек үк ачык йөзле, тыныч, сабыр холыклы кеше иде. Ятимнәр йортыннан соң Чиләбедә югары уку йортын тәгәлләп, гомере буе заводта эшләгән. Хатыны — татар кызы, табибә. Ике кыз үстергәннәр. Рәшит абыйның вафатына ике генә ел булды әле.

● Михаил Львов һәм Мәхмүт Әхмәтҗанов. 1965 ел.

Рифкать абый исә югары уку йортында укыганда ук журналистика белән шөгыльләнгән, шигырьләр язган. Берничә әсәрен гәзит-журналларда бастырган. Чиләбе — металлурглар шәһәре. Сугыш елларында Чиләбе трактор заводы «Т-34» танкларын эшләп чыгарды. Бу шәһәрдә тарихка «Добровольческий Уральский танковый корпус» дигән исем белән кереп калган танк дивизияләре дә оештырыла. Рифкать абый, завод биргән броньнан баш тартып, үз теләге белән фронтка китә, политработник була, фронт гәзитләре белән хезмәттәшлек итә. Анда Михаил Львов исеме белән аның очерклары, шигырьләре дөнья күрә. Рифкать абый сугыш турында, сугышта алган яралары турында сөйләргә яратмый иде. Мәскәүдә гомер итсә дә, гел Казанны, Татарстанны сагынып яшәде. Форсаты килеп чыккан саен ул әтисенең туган ягына кайтып килде. 1957 елда Мәскәүдә татар декадасы оештырылыр алдыннан Казанга Михаил Львов җитәкчелегендә бер төркем урыс язучылары килгән булган. Ул елны авылдашыбыз бер айга якын «Казан» кунакханәсендә яшәгән. Шунда көн дә диярлек бик күп әдәбият һәм сәнгать әһелләре белән очрашкан. Фатих Хөсни, Сибгат Хәким, Мөхәммәт Садри, Мәхмүт Хөсәен кебек әдипләребез белән шунда дуслашкан ул. Аның Мөхәммәт Садрига багышлап язган бер шигыре дә бар.

Рифкать абый татар зыялылары арасында дуслык, бердәмлек булмауга бик борчыла иде. Язучылар бердәм булмагач, халык нишләргә тиеш инде, дип әйткәне әле дә хәтердә саклана. «Дуслык, бердәмлек ягына килгәндә, яһүдләрдән үрнәк алырга кирәк, — диде ул. — Бервакыт Илья Эренбург минем Казанга китәргә җыенганымны белгәч, анда яшәүче Ян Винецкий исемле язучының әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итүемне үтенгән иде. Урта кул әдипкә бөтен дөньяга танылган язучы һәм ялкынлы публицист И.Эренбург ярдәм кулы суза! Менә бит ул бердәмлек хисе нинди аларда»

Өстәп шуны әйтәсем килә, Рифкать абый Я.Винецкийга чыннан да ярдәм иткән.

Шунысы аянычлы, безнең арабызда гомере буе татарлар арасында яшәп тә үз ана телен яратмаучы кешеләр бар. Гадәттә, без андыйларны манкорт дип атыйбыз инде. Сүгә башласаң, акланырга тотыналар. Янәсе, аларны урыс мохите шундый иткән. Бәлки, шулайдыр да, әмма гомере буе урыслар арасында яшәгән Михаил Львов нигә манкортка әверелмәгән соң? Ул бит татар телен бик яхшы белә иде. Моның сәбәпләре шактый күп. Ул, үз мәдәниятен кире каккан манкортлардан аермалы буларак, моның нинди гаҗәеп зур әхлаксызлык булуын аңлау өстенә, үлеп-үлеп Казанны ярата иде. Башкалабызда булып кайту аның өчен үзенә күрә бер олы бәйрәм була иде. Шагыйрь Мәскәүдә дә үзенең татар булуы белән горурланып яшәде, үз халкына багышлап гүзәл әсәрләр иҗат итте. Күзебез шуңа кысык, чөнки җәядән ук атканда күзне кысарга туры килгән, аягыбыз гөз түгел икән, моның да сәбәбе бар: татар ат өстеннән төшмәгән, дип язды ул. Я.Смеляков кебек Мәскәү шовинистлары Рифкать абыйны кан дошманнары итеп күрделәр. Урыс тегерменә килмешәк татар телен он итте, дип мактандылар. Андыйларга җавап итеп шагыйрьнең иң якын дусларының берсе – татар милләтеннән булган башкорт шагыйре Нажар Нәҗми Мәскәүдә чыга торган «Учительская газета»да кискен шигырь бастырды. Бу шовинистлар өчен үтезгә кызыл чүпрәк күрсәтү белән бер иде. Алар «Крокодил» журналында Рифкать абыйның иҗатын пычратып ямьсез пасквиль язып чыктылар. Янәсе, Михаил Львов иҗаты мич артында сайраган чикерткәне хәтерләтә. Күңелсез булса да, сүз уңаеннан шуны әйтеп узам: бу әшәкелекне эшләгән каләм иясе гиздән аракы эчеп үлде. Әйе, кайбер тар күңелле язучылар, шагыйрьләр Рифкать абыйның югары зәвык белән иҗат ителгән тирән эчтәлекле әсәрләреннән үлеп көнләштеләр. Шул түзә алмаслык шартларда да ул иҗат утында янудан туктамады, яңадан-яңа китаплар чыгарды. Җәмгысе –, утыз ике җыентык. Мөхәммәт Садри тәрҗемәсендә аның татар телендә дә шигырьләр җыентыгы дөнья күрде.

Рифкать абыйның иҗатын халык яратты. Шуңа күрә дә СССР Язучылар берлеге идарәсе аны Ленин премиясенә тәкъдим итте. Әмма шовинистлар бу юлы да шагыйрьгә каршы дәррәү күтәрелделәр. Һәм теләкләренә ирештеләр дә.

Бервакыт журналистлар генерал Якуб Чанышевка: «Ни өчен сез генерал-лейтенант дәрәҗәсеннән уза алмадыгыз?» — дигән сорау биргәннәр иде. Аның җавабын мин үз колагым белән ишеттем. «Татар милләтеннән булмасам, мина инде күптән маршал йолдызы тагарлар иде»; — диде ул. Рифкать абыйның язмышы да шуңа охшаш, дисәм, хакыйкатьтән тайпылу булмас. Ятим балачак, фронт яралары, иҗатына карата гаделсезлекләр аның сәламәтлеген нык какшатты һәм ул житмеш яшендә Мәскәүдә йөрәк авыруыннан үлеп китте.

Һәм соңгысы. Рифкать Дәүләтша улы Габитов ничек һәм ни өчен Михаил Давыдович Львовка әйләнгән соң? Мондый сорауны мин Рәшит абыйга да, Рифкать абыйның үзенә дә биреп карадым. Әмма аларның берсе дә әлеге сорауга анык кына җавап бирмәде. Рифкать абый яһүд гаиләсендә тәрбияләнгән. Бу аның искиткеч тәрбияле, итагатьле, нечкә һәм киң күңелле кеше булуында да бик ачык күренә. Минем уйлавымча, ул тәрбия кылучының исем-фамилиясен рәхмәт йөзеннән алгандыр. Давыт, Львов — яһүдләргә бик хас исемнәр. Икенче фаразым да бар. Аны бу исем алыштыруда шовинистларның татарга карата тискәре мөнәсәбәттә булулары этәргәндер. Рәсәйдә татарга бик юл куярга теләмиләр бит. Яһүд милләтеннән булган күп кенә зыялылар әле дә булса, милләтләрен яшермәсәләр дә, кусн кесәләрендә урыс паспортын йөртәләр. Моны чыгышы белән яһүд булган урыс шагыйре К.Симонов та яхшы аңлаган. Заманында ул татар егете Рөстәм Сутеевка: «Китабыңа кереш сүз язам, әмма сиңа Роман Солнцев булып китәргә туры килер», — дигән булган. Бәлки, Рифкать абыйның юлында да шундый «киңәшчеләр» очрагандыр. Ни генә булмасын, мәкаләм ахырында шуны өзеп әйтәсем килә: Рифкать абый һәрбер күзәнәге, дөньяга булган карашлары белән чын ТАТАР кешесе иде.

## Көлсәң — көл, көлмәсәң — ела!

Гадел

# Фасон

Кәҗә Тәкәсе (Козел) бо-
рылыштан соң пост барлы-
гын белә иде. Тизлекне ал-
дан ук баса гөште. Андагы
старшина хатынның аяусы-
злыгын бөтенесе дә белә
иде.

Чыгарып күрсәтегез,
— диде сөйкемле старши-
на, кәҗә мөгезенә таяк
аскан кулын куеп алгач.

— Минем бер генә тише-
белән генә шартлатып ти-
шеп ала иде ул.

Әллә нинди кәҗәләрне
күргәне бар иде Тәкәнең:
берсе белән дә килешми ка-
лмый торган иде әле моңа-
рчы. Шуңа күрә шәһадәт-
намәсе дә бер генә тишекле
иде.

Матурым, бозмыйк
инде нием... фасоның,
— диде Тәкә, намәсен яшь-
келе, — диде Тәкә.

— Булмаганны, — диде
Тегесе, — күпме эшләп, ан-
дыйны бер генә тапкыр да
кулыма тотып караганым
юк әле. Чыгарып күрсәте-
гез!

Тәкә (Козел) як-ягына
карап алды. Кеше-мазар
юк иде.

— Ни бит... нитмик ин-
де... — дип, күперебрәк го-
рган янчыгын Тегенә күрсә-
тебрәк капшап куйды.

— Күрсәт, күрсәт!

— Бәлкем, ни, мату-
рым... болай гына нитәр-
без, — дип, Тәкә янчыгын-
нан (акчаның) башын бераз
күрсәтебрәк куйды.

— Үзеп, үзен чыгар!
— Җитмәсә, тешен дә ша-
кылдатып алды Тегесе:
права кәгазен казык теше
келт акча белән каплап Те-
геңә суздьı. — Калсын инде
шул бер тишекле килеш ке-
нә...

— Фасон сакламакчы та-
гын... Син кайдан киләсең?
— дип күзләрен акайтты
Тегесе.

— Монда... Бакчадан гы-
на кайтып килеш.

— Кайсы заманнан килә-
сең, дим мин сиңа, карт тә-
ре! — Күзләреннән чыккан
ялт-йолт нур көлтәсе нәф-
рәт белән яшькелт акчаны
айкый иде.

Шунда гына Тәкә үзенең
нинди хата эшләп ташлага-
нын аңлап алды. Намәсен
каплаган акча торгынлык
заманында ук гел шуның
өчен генә тыгып йөрткән
мескен бер яшькелт өчлек
иде.

— Аһ, бигрәк сукыр тәкә
инде үзем, — дип, кабала-
нып, тагын янчыгын тотты
Тәкә.

Коз-зел, — дип, ты-
ныч кына төзәтте аны Тего-
се, Тәкә янчыгын кашыган
арада. — Моңысы нәрсә
тагын?! Һаман яшькелт...
Кызармый да үзе! — дип,
Тәкәнең алыштырып өлге-
ргән шытырдап торган яш-
келт акчасы белән бергә на-
мәсен дә теш арасына кы-
стырып алырга әзер иде ин-
де ул.

— Талир ые ул... доллар,
ягъни, — диде коелып төш-
кән, ак сакаллылар төрке-
менә керә торган кәҗә теле
белгече Тәкә әфәнде.

Тегесенең авызы ачылды
да калды. Аның куышлы-
гыннан көдрә-көдрә
«ә-ә-ә...» дип сузган кәҗә
тавышы гына чыкты.
— «Мә-ә-ә», — дип ялгап
китте аннары.

— Мә! — дип намәсен
Тәкәгә тоттырды, долларны
ипле генә ирен арасына
кыстырды да, җайлап кы-
на, Тәкәгә арты белән әй-
ләнде.

Шул чаклы да рәхәтлә-
неп басканы юк иде әле газ-
ны Тәкәнең. Аның бу баты-
рлыгын доллар битеннән
елмаебрак кына Джорж Ва-
шингтон үзе карап торадыр
кебек тоелды. «Менә, ичма-
сам, президент! Буе гына да
183 сымы булган шул
аның, — дип басканнан ба-
са барды газны Тәкә.
— Мымы түгел бит ул си-
ңа, сымы! Менә президент
дисәң дә, президент, ичма-
сам! Әмрикә — Әмрикә
шул инде ул. Фасонны тота
беләләр анда!..



Егет гошенә сөйгән яры керә,
тавык төшенә тары керә.

Кирам САТИЕВ

# Өч хәрефле сүзләр

Бөтен яхшы сүзләр өч хәрефтән гора. Әти, Әни, Мин. Соңгы вакытта рус белән кабат дуслаштык. Баксаң, рус һәм дус сүзләре (өчесе дә!) өч хәрефтән тора икән! Ә менә «тора» сүзенең соңгы хәрефен алып ташласаң, ул «тор» булып, ягъни өч хәрефле сүз булып кала. Ләкин мин мондый сүзләрне яратмыйм. Беренчедән, алардан диктатура исе аңкый. Икенчедән — боерык фигыльнең буйсындырудан, мәҗбүр итүдән гайреләре дә бихисап, лабаса! Мәсәлән, бир. Йә, ходай, исәнлек бир, сабырлык бир һ.б.лар.

Өч хәрефле «бир» сүзен мин аеруча яратам. Чөнки сирәк-мирәк кепә булса да, бирүчеләр дә булгалый.

Бир, дигәннән, бер көнне кибеткә кереп, ярты кило акыл сорадым. Кибетче аптырап: «Бездә юк бит ул нәрсә», — диде һәм... бераздан кычкырып көлеп җибәрде. Ә акыл сатучылар тормышта адым саен очрап тора. Гадәттә, надан кешеләр акыл сатарга ярата.

Өч хәрефле исемнәр әдәбият-сәнгать әһелләрендә еш очрый. Бу шәхесләрнең фамилияләрен язмасам да, сез аларны яхшы беләсез: Аяз, Нур, Нил, Ким, Хәй, Рим, Риф, Фән, Дан...

Дан, дигәннән, аның әтисенең исеме 24 хәрефле иде. 8 тапкыр кыскартып, улына өч хәрефле исем кушты. Кәгазь-каләмгә күпме экономия! Галимнәр исәпләвенчә, гомер буена нәкъ бер машина алырлык акча янга кала икән! Ә менә ул кешенең даны еракларга таралырмы-юкмы — аныcын бер Алла гына белә.

Баштарак мин «рус белән дус» дигән идем. Бу җөмләдә дә өч хәрефле өч сүз бар: мин, рус, дус.

Урыс дигәннән, алар телендә өч хәрефле сүзләр буа буарлык. Шуларның кайберләрен бигрәк тә хатын-кызлар ярата. Хәзер сезгә шул сүзнең берсен атап узам: ул — мир. Миңа әбием бала чакта. «Ипи белән бәрәңгегә риза, сугыш кына булмасын», — дип әйтә иде.

Урысларның Алла дигән сүзләре дә өч хәрефтән гора — бог Машиналар ЗИЛ, ГАЗ, Ока, барыбызга да яхшы таныш булган КГБ, МВД һәм БАМ сүзләре; хәтта иң моңлы җырларыбызның берсе — «Уел» — барысы да өч хәрефле сүзләр.

Элегрәк Вил исемле кешеләр хәйран күп иде. Бу инде Владимир Ильич Ленинны кыскартып ясалган сүз.

Америка экс-президентының да фамилиясе өч хәрефтән тора. Аның атасы Буш булды микән, әллә бабасымы — монысы әле ачыклыйсы бар.

Элек тә, хәзер дә зыялы кешеләрне ипи-тоз белән каршылаганнар. Һәм дә өч хәрефле сүз белән озатып калалар: «Хуш!» — диләр.

«Уй»га тәмамланган татар сүзләре дә еш очрый. Мәсәлән, суй, гуй, туй, куй. Үзем яраткан өч хәрефле берничә сүзне атап узам: кал, сал, чиш, күз, сүз, гүз, кул, тот, наз, имә, нык, чык, тык...

Иң зур хайваннарның исемнәре дә өч хәрефле — фил, кит Иң кечкенә җанварлар — бет Ул да өч хәрефле.

«Х» авазына башланган өч хәрефле сүзләр дә байтак Мәсәлән, хат, хан, хак, хуш, хуп һ б лар.

Урыс телендә «Х» га башланган өч хәрефтән торган сүзләр шактый. Сезгә шуларның берсен генә, иң ямьсезен, иң әшәкесен әйтәм — хам.

Тагын бер сүз Ул сүзнең ике хәрефе билгеле. Берсе «Х», берсе «У», өченчесен үзегез әйтегез. Ә, белмисезмени? Ул вакытта үзем әйтеп бирәм уха..

ПАР(О!)ДӨЯ

Нияз АКМАЛ

*Кургашланды елгаларда сулар,*
*Шәрәләнде оялчан*
*Аулак җирләр.*
*Кичерелмәс гөнаһ эшләгәндәй,*
*Сулык-сулык елый көзге җилләр...*
*Марс ШАБАЕВ.*
*«Көзге җилдә».*

**Аулак җирләр оялмыйча тора,**
**Елга гына һаман оялчан.**

**Елга буе шигырь язу нигә**
**Гөнаһ эшләүдән дә оялсаң?!**

**Җилләр елар сулык-сулык килеп,**
**Гөнаһларга әгәр буялсаң.**
**Аулак урын — әгәр оялмасаң,**
**Күмәк урын — әгәр оялсаң...**



# Кылдан нечкә,

## Сүз башы

— «Тукай» дигән фән булырга тиеш! — дигән иде мәрхүм Альберт Фәтхи. — Тукайның һәр сүзенә, һәр шөгыленә тарихи-гыйльми аңлатма, шәрех булырга тиеш киләчәктә...

Татар галимнәренең вә чит илләрдәге фән эшлекләләренең өзлексез эзләнүләренә карамастан, Тукайның иҗаты һәм аның шәхси хәяте турында әле соңгы сүз әйтелмәгән, һәм әйтелмәячәк тә, чөнки фән ул чиксез нәрсә.

Пушкинның иҗатына калын-калын гыйльми хезмәтләр багышланган, аерым сүзлекләр төзелгән; аның дуэль көне сәгате-минутына хәтле өйрәнелгән, тәфсилләп язылган. Урыс матбагасы Пушкин турында инде кабат яңалык әйтә алмас кебек, ләкин яңадан-яңа табышлар була тора, яңа фаразлар туа тора.

Галимнәребез, язучыларыбызның мактауга лаек хезмәтләре булса да, кызганыч ки, күп кенә шәхесләребезнең иҗаты, тормышы тәфсилләп өйрәнелмәгән. Тукаебызның да әле әллә никадәр серләре ачылмыйча ята булыр. Әйтик, Тукайның кайсы күзенә ак төшкән булган, дигән сорауга хәзергә төгәл җавап юк. Кемдер, сул күзенә, ди. Галиәсгар Камал исә, уң күзенә, дип яза. Кайсысы дөрес? Бер фоторәсемдә Тукай янында мөлаем, озын егет басып тора. Берәүләр аны, төрек шагыйре Габделвәли Әмрулла, ди. Икенче бер галимнәр, бу — Габдулла Кари, дип Тукай музеена куйган. Кайсысы дөрес? Тагын бер рәсемдә Камил Мотыйгый белән янәшә гәбәнәк кенә бер шәкерт басып тора. Китаптан китапка күчә барган бу рәсемне без К.Мотыйгый белән Г.Тукай сурәте дип беләбез. Хәзер бәхәс купты: юк, бу Тукай түгел, янәсе. Тукай булмаса, ул кем? Кәттә кыяфәтле, мәгърур Камил бәй очраклы вә гади шәкерт белән кулга-кул тотышып фотога төшәр микән?

Әлбәттә, бер карагаңда, боларның барысы да бик вак мәсьәлә кебек күренер. Барыбер түгелмени сон: сул күзенә ак төшкәнме, уң күзенәме! Моның ни әһәмияте бар?

Тукай фәне бар икән, аның иҗаты вә шәхесенә кагылышлы һәр «вак» нәрсәгә җавап табылырга тиеш. Тукайның үзе өчен дә күзен каплаган «печать проклятия» («каргыш мөһере») бер дә вак нәрсә булмаган. Бу зәгыйфьлек аның рухына нык тәэсир иткән; рухына тәэсир иткән икән, димәк, иҗатына да көчле йогынты ясаган, дигән сүз. Һич шик юк ки, күзенә төшкән бу ак Тукайның кимсенүен арттырган.

Язучы буларак, мине, мәсәлән, Тукайның күз агы гына түгел, аның тәмәке тартканы-тартмаганы да, бала-чага белән бишташлы, кузналы уйнаганы да һәм кайбер «нәзик эшләре» — барысы да кызыксындыра. Гади кызыксыну, имеш-мимеш теләгемне канәгатьләндерү өчен генә түгел, ә бәлки, иҗатым өчен, Тукай кебек даһиның рухын өйрәнү өчен кирәк.

Тукай — ул чагыштырмача бик якын тарих. Исәннәр арасында Тукайны күргән-белгәннәр дә бар. Шагыйрьнең кыяфәтен сурәтләгәндә, эчке халәтен тасвирлаганда язучылар бары тик тарихи мәгълүмат вә хатирәләргә таянып, дөреслеккә хилафлык китермичә иҗат итәргә дучар. Узар замананар, Тукай ерак тарих вәкиле булыр; әдәбият-сәнгать-фән Тукайны өйрәнүдән, ачышларга омтылудан, шәрех вә фаразлардан туктамаячак. Рәссамнар, әдипләр, композиторлар Тукайны үз мәсләкләреннән чыгып сурәтләр. Аны күзенә ак төшкән, зәгыйфь бәдәнле, кимсенү чире йоккан, ярты үпкәле, үпкәчел кеше итеп түгел, ә бәлки, мәһабәт гәүдәле каһарман итеп күрсәтер. Сәхнәдә, кинода аны баһадир гәүдәле актер уйнар. Без Тукайдан ерагая барган саен, Тукайның боеклеге арта барыр. Ул киләчәк буыннар өчен Алып батырдай биек-калку булып күренер, чөнки Тукай — үз иҗаты белән Алып, үз шигъре белән каһарман.

Татар шагыйрьләре (сәнгатьчеләр) үз иҗаты, үз хәяте белән, миңа калса, биш сыйфатка ияләр.

Илаһи куә, ягъни кабилият, олуг сәләт, бүгенгечә әйтсәк, табигать (Аллаһы) биргән талант.

Фәлсәфә. Фәйләсуфләрчә, бөек суфиларча фикерләү; моңа кадәр без күрмәгәннәрне иҗатта күрсәтә белү; безнең башыбызга да килмәгән төшенчәләрне ачып салу; моңарчы канун-кагыйдә дип йөргәннәребезнең хата икәнен исбатлау куәсе.

Әүлиялык. Шәхес иҗаты белән үз кавеменнән сизгеррәк, акыллырак булып, алда халыкны ни көтәсен юрый алса, әсәрләрендә шуңарга ишарәләр ясый, һич югында, болай барсагыз, сезне алда һәлакәт көтә, дип кисәтә алса, ул әүлияләр рәтендә булыр.

Фиданлек. Бар фидакарь җаннар, ягъни тырышып эшләүчеләр, хезмәт батырлары, алар — күпчелек. Ә фиданлек — ул каһарманлык, ватанпәрвәрлек, ил-халык өчен үзеңне корбан итәргә әзер булу, үзеңне корбан итү.

Фаҗигале гомер. Алда саналган сыйфатлары булган кешенең шәхси хәяте гаять катлаулы, кыен һәм, гадәттә, фаҗига белән тәмамлана; аны җәберлиләр, кыерсыталар, үтерәләр, үтертәләр; ул ялгызлыкта, хәерчелектә үләргә мәҗбүр ителә.

Кол Гали (сугышта үтерелә), С.Сараи (горбәттә вафат), Колшәриф (сугышта үтерелә), Акмулла (үтерелә), Ш.Бабич (үтерелә), Һ.Такташ (агулана), М.Җәлил (үтерелә), Ф.Кәрим (сугышта үтерелә) һ.б. бик күп татар шагыйрьләре һәм сәнгатьчеләренең фаҗигаләре моңа ачык дәлил. Үз үлеме белән дөньядан киткән Сәйдәш тә чынлыкта үтерелде, аның иҗатын, рухын сындырдылар. Ул шәхес буларак яшәүдән туктарга мәҗбүр ителде.

Мин дә шәхесләребез турында әсәрләр язам. Тарихтагы мәшһүр шәхес турында әдәби әсәр язу — ул гаять четерекле мәсьәлә. Тарихчылар синнән төгәллек таләп итәчәк, бер-ике елга гына түгел, бер-ике сәгатькә генә ялгышсаң да, сине тарихны бозуда гаепләячәкләр кебек; әдәбиятчылар синнән әдәби образ, сгылып укырлык маҗара-хикмәтләр көтә. Документлар, шаһитлар булмаганда, рәссам, әдип ни кылырга тиеш? Әлбәттә, иң беренче документ, иң мөһим шаһит — ул шәхеснең иҗаты, риваятьләр.

Мәшһүр шәхескә куелган һәйкәлне күреп, рәсемгә карап, без еш кына скульпторларны, рәссамнарны тәнкыйтьләргә тотынабыз. Янәсе, бу әсәр шәхеснең үзенә охшамаган. Охшаса — әйбәт, охшамаса — начар. Сынның, рәсемнең шәхескә охшаган булуы шарт, әлбәттә. Ләкин рәссамның үз күзаллавы да бар бит әле! Иҗатыннан чыгып, рәссам Лотфи Насыйр Такташны ясады. Аның бу «Такташ»ы Такташның үзенә охшаган иде, ләкин Лотфи Такташны ут янган күзле, чәчләре кысага сыймый торган итеп, сынык сызыклар белән иҗат итте. Бу рәсем Такташның символы буларак тарихта калачак, дип уйлыйм мин. Такташның тарихи фотолары түгел, рәссам Л.Насыйрның «Такташ»ы алдан йөриячәк, чөнки бу рәсемдә Такташның гыйсъянчылыгы да, калыпка сыя алмаганлыгы да ачык күренә. Бу — рәссамның иҗади батырлыгы, ачышы.

Шуннан соң Лотфи Насыйр Тукайны ясап карады. Уңышсыз әсәр килеп чыкты. Рәсса[м] тарихи дөрес сурәт ясамаган. Тукайның иҗатын, рухын белмәве аркасында ялган, буржуй Тукай образы барлыкка килгән. Рәссам Тукайның бердәнбер тук-симез кыяфәтле рәсемен алган да шуны турыдан-туры күчергән генә. Китаптан китапка, альбомнан альбомга Тукайның әнә шул очраклы рәсеме, Тукайга хас булмаган сурәте күчеп йөри. Бу рәсем Тукайның типик сурәте түгел. Тукайның фоторәсемнәре бер-берсенә һич тә охшамаган. Һәр фотода аерым кеше сурәтләнгән кебек. Тукай шулай әледән-әле үзгәрә торганмы, фотографлар шулай төрлечә төшергәнме? Шуңа күрә бәхәс тә купты бит: Камил Мотыйгый янындагы таушалган бишмәт, борешеп беткән чалбар кигән, янбашын остеннән кинрәк, кәкре аяклы бу шәкерт Тукаймы, юкмы? Төгәл җавап юк, Мотыйгый кебек һавалы кеше гади шәкерт белән мәшәкатьле эш — фотога төшү белән әш-мәш килер идеме икән? Шик юк кебек, бу — Тукай.

Мин үзем рәссамнарга Тукайның рәсем символын «Аң» журналында басылган, кырыс карашлы рәсеменнән һәм хастаханәдә меңдәргә яткан сурәтеннән, үлеменә бер тәүлек элек алынган, тезен кочаклап төшкән рәсемнәреннән эзләргә киңәш итәр идем.

Тавил Хаҗиәхмәт нәкъ менә мин бая әйткән — ул иң өсте аша кырыс карап төшкән рәсемен нигез итеп алып, шагыйрьнең портретын ясаган. Шуңа күрә рәссамнар тарафыннан иҗат ителгән «Тукай»ларның иң уңышлысы әлегә шушы эштер, дим. Ләкин монда да ризасызлык уята торган бик мөһим бер чатаклык күренеп тора. Тукайның күз карашы борчулы түгел — сабыр, хәтта битараф. Тукайның бөтен иҗаты борчылу, халкы өчен җан ату, кыйналудан гыйбарәт, ә шул хәвефләнү, халык кайгысы шагыйрь күзләре аша безгә карамый.

Тарихи шәхесләрнең рәссамнарыбыз тарафыннан ясалган рәсемнәрендә «күз, күз карашы» мәсьәләсе аерым бер бәхәс мәүзуы була алыр иде. Күз — күңел көзгесе. Күз дөрес ясалмаса, шәхеснең рухын ачып бирә алмаса — рәсем юкка чыгар. Казаковның «Бәләкәй Тукай» исемле рәсемендәге сабый Апушның күзләре акыл иясенеке кебек мәгънәле багалар. Башка «Тукай»ларның күбесенең күзләре буш, сукыр...

Тавил Хаҗиәхмәтнең «Кол Гали» портретына карагач та, күңелле рәссам өчен, олуг шагыйребез өчен бер сызлану тырнап уза. Кол Галинең җанлы күзе юк. Мәгънәле караш юк. Гасырларны кичеп, безне күреп торя торга[н] багыш юк. «Йосыф-Зөләйха»дагы зиһният, хиссият, әүлиялык күренми бу күзләрдә. Рәсемдәге Кол Гали сукыр. Һәм бу рәсем бөек Кол Галинең символы була алмый. Тарих барыбе[р] башка бер Кол Гали рәсемен таләп итәчәк.

Мин үзем шәхсән Кол Гали символы ите[п] Бакый Урманченың агач тамырыннан иҗат ите[л]гән «Сагыш» сынын яки «Кол Галя» исемл[е] мәрмәр әсәрен алыр идем. Бу ике акыл иясе куәт иясе халык кайгысы, ил язмышы турынд[а] уйлаучылар түгелме? Алар, миңа калса, Роде[н]ның «Акыл иясе» дигән мәшһүр сынынан бе[р] дә ким түгел.

Мәшһүр шәхесләребезнең кабер ташындагы сурәтләре турында да аерым сөйләшергә кир[ә]ктер, мөгаен. Мөселман зиратында сурәт, сы[н] рәсем куелырга тиеш түгел дип беләм. Ярый без инде Ислам кануннары буенча яшәмибе[з] икән, хет, ичмасам, сәнгать кануннарын то[] тыйк. Уңышлы сурәтләр белән бер рәттә[н] адәм әйтеп, адәм ышанмаслык гарип чырайл[]

# ...кылычтан үткер

...сына килеп керәбез ләбаса. Кабер өсте... һәйкәл, барельефлар гүр иясенә бе... охшаган булырга тиештер бит инде? ...хилтураны, мәрхүмнең рухын рән... каберге куймаска гына кирәктер дә.

...Насыйрның рәсемен рәссам Байназар ...иҗат итте. Каюм абзыйның авылдаш... рәсемне күргәч, менә, бу безнең Каюм, ...шулай кылый күзле иде, дигәннәр. ...бүе мин Байназар аганың бу эше бе... «Каюм Насыйри» рәсеме белән ризя... идем. Байназар аганың үзенә дә ...әйткәләдем. Ул рәсемнең оригиналы ...охшашлыгын иң алгы планга сөрә иде. ...замандашларының сүзе рәссамга иң ...булып калды. Сукырлыктамыни ...? Замандашлары аны «сукыр Каюм», ...Каюм» дип йөрткәннәр. «Сукыр» дигәне ...күзе зәгыйфь булганы, «урыс» дигәне ...яхшы белгәне, урыс галимнәре белән ...ы, татарларны урысча өйрәтергә те... арасында бирелгән. Дөньяның киләчә... теләннән бәнкә баралмаячагын йөз ...алдан күргән кеше сукыр була аламыни ...Мин аны кылый күзле итеп ясамас идем. ...ны да күзенә ак төшереп ясаучы габы... Дөрес, Тукайның күзендә зур гына ак тап булган, диләр, шуңа күрә, аны солдатка да алмаганнар булса кирәк. Әмма Тукайның күңел күзе сукыр булмаган. Ике күзе дә сәламәт Тукайның рәсеме тарихи дөреслеккә күбрәк туры килә. Күптәнкән инде без Тукайның символик рәсемен Байназар Әлмиев ясаган рәсемнән күрә килдек. Буй-буй якалы ак күлмәк, нохтә галстук; тәти Тукай безгә һични сөйләми торган күзләре белән карап тора. Бу рәсемдә дә Тукайның катлаулы рухы чагылыш тапмаган. Димәк, тарихи шәхеснең рәсемен ясаганда, рәссамнарыбыз шул шәхеснең вөҗүден, максатын аңламыйча эш итәләр. Яки коры тышкы охшашлыкка гына басым ясыйлар кебек. Еш кына ул охшашлык та барып чыкмый кала.

Тукайның бик матур бер рәсеме бар. Тукай үзе исән чакта ук аны «Гасыр» нәшрияты бастырып тараткан. Дикъкать белән карасак, бу рәсемдә дә Тукайның уң күзе сулыннан зуррак. Ак төшкәнгә күрә уң күз, караңгыда ыштрак ачылган бәбәк кеби, яктылык күрергә омтылып ачылганмы, әллә сулына ак төшкәнгә, уң күз икесе өчен дә күрергә теләп зураймы? Дөнья күргәннәрнең әйтүенчә дә, күз табибларының фикеренчә дә, сукыр күз ыштрак ачылырга мәҗбүр була икән.

Шулай озын гына сүз куерткаңнан соң, мин дә Тукайның рәсемен, әдәби сурәтен ясарга җөрьәт иттем. Тарихи әсәрме бу? Тарихи әсәр. Әдәби әсәрме бу? Әйе, әдәби әсәр. Тукай Зәйтүнә тутаң белән очрашканмы? Очрашкан! Нәрсә турында сөйләшкәннәр алар? Һичкем белми. Бәс, аларны җанландыру язучының иркендә, әдипнең хокукында лабаса. Иҗат максатларыннан чыгып, автор хәтта тарихи чынбарлыктан күрәләтә читкә дә китә ала. Дөнья әдәбиятында моңа мисаллар җитәрлек.

Әйтик, тортмә холыклы, әче телле Тукай, жандармериянең «авырткан сөяге» булган Тукай, күпме мәшһүрләрне «чәнчегән» Тукай үз үлеме белән үлә аламы? Юк! Тукайны йә үтерергә, үтертергә, йә үз-үзенә кул салырга мәҗбүр итәргә тиешләр иде. Һәм, әлбәттә, бу шулай булгандыр да. Тукайның үз-үзенә кул салырга уйлаган вакытлары да булган. Киләчәк буын язган әсәрләрдә Тукай нәкъ бөек каһарман — баһадир буларак, карагруһчыларга, шовинистларга каршы сугышта һәлак булачак! Бу — Тукайның иҗат символы.

Тукайның соңгы көннәрен мин үземчә күзалладым, үземчә гомавладым һәм үземчә күргәннәремне сезгә сөйләргә булдым. «Кылдан нечкә, кылычтан үткер» исемле бу кыйсса тулысы белән «Казан утлары» журналына тәкъдим ителде.

**Рабит БАТУЛЛА**

Ул җиңелчә генә йөткереп алды, почмактагы кисмәктән алып су эч... ...тагын килде. Тукай шак... ...ерлек итеп ютәлли баш... Нihaять, ютәл китте, ул эш... ...ы, ләкин каләм аңа буй... ...ы. Шулчак ишек шакыды... ...сат ишеткәнче үк ишек ...бүлмәгә чадра бөркәнгән ...керде.

...әт итсәгезче, Тукай әфән...

...ыгыз! — диде Тукай. ...Мәфруза түти асравымы?

...! Мин Мәфруза тутагыз ...түгел. Мин бөтенләй баш... Сез көткән кеше түгелмен. ...ыйм сезне, туташ!

...! — дип тәзәтте аны ...— Ханым, дип дәшегез ...иде.

...ыйм сезне, ханым-әфән... Тукай үз урынына ба...ды.

...хатын ишек катында... бирде.

...маскарадым өчен гафу ...кай әфәнде. Мин шулай ...ышып килергә мәҗбүр...

...йса, сез йә бик чибәр, йә ...минем икенче күзем... ...райтмасын, дип чадра ...р? Яки сез дөнья ямь... ...ны күреп, кешенең ко... ...; дип шулай яшерен...

...ярымшаяруы, кырыс ...га нык тәэсир итте,

...сез усал Тукай! — диде. ...өченче сәбәп яшеренергә ...

...хатын бүлмәдә башка ..., дигәндәй як-якка ка...лды.

...магыз, — диде Тукай. ...ыз.

...ургә узмаенча, шулай ...ла бирде һәм сүзгә күч...

...әфәнде, — дип баш... ...зинһар, кызмагыз, ачу... ...бичара бер хатынны. ...сезнең китапларыгызны ...ым. Шигырьләрегезне укып егълыйм. Сезне күреп белергә иң гомер хыялландым. Әмма мин иркле түгел. Никахтагы хатын мин. Сезне күрү хыял була килде. Ниһаять, мин шушы ысул белән сезне күрү бәхетенә ирештем. Зинһар, шушы китапларга истәлек имзагызны салыгыз...

Тукай иркен сулап куйды. Йомыш ул үтәмәслек түгел иде. Каләм тотып, ханым пәрдә астыннан чыгарып өстәлгә куйган китапларны алып:

— Кемгә дип языйм соң, ханым? — диде.

— Алтаң туташка, дип языгыз.
— Алтаң туташка.

Тукай яза-яза:

— Алтаң туташка, Алтаң — матур исем, әгәр дә...

— Борчылмагыз, Тукай әфәнде, — диде кунак хатын. — Алтаң – минем сеңлем.

Имзалар салынып беткәч, хатын рәхмәт әйтте, ләкин китәргә җыенмады. Тукай соңгы имзаны куюга ук:

— Хушыгыз, ханым! — диде.

Чадралы хатын өстәл янынан кузгалмыйча:

— Килүемнең төп сәбәбе бу түгел иде... — дип сүз башлады. — Имза алу сылтау гына. Зинһар, мине тыңлап багыгыз, әфәндем. Мин сезнең иҗатыгызны читтән генә күзәтүче түгел, мин сезнең химаячыгыз булырга телим, Тукай.

Тукай урынында кала бирде, ләкин аның карашы да, тавышы да сагаюлы иде:

— Мин әле бернәрсә дә төшенмәдем, ханым...

Хатын Тукайдан бераз читкәрәк китеп, озын-озак сүз сөйләргә җыенган кеше кебек:

— Сез зур талант! — дип куйды. — Күп гасырларга бер генә туа торган даһи сез! Ләкин сезнең кадерне белүчеләр юк. Булганнары үзләре кемнеңдер ярдәменә мохтаҗ. Сезнең талантыгыз үзегезнеке генә түгел. Сез — бөтен халыкныкы. Шуңа күрә сезне аеруча сакларга, иркәләргә, үстерергә кирәк. Сез Руставелилар, Фирдәүсиләрдән бер дә ким түгел, әфәндем. Нигә сезгә дә мәйдан тотмаска!

Тукай тамак кырып куйды. Ханым моны үзенчә шәрехләде: мин болай да мәйдан тотам бит инде, димәкче иде Тукай. Ханым аннан алда өлгерде:

— Дөрес, сез мәшһүр! Ләкин татар халкы эчендә генә! Сез һичнинди мохтаҗлык күрмәенчә, ипи-тоз, торак-фатир турында уйламыйча, бары тик иҗат белән генә, бары тик әдәбият белән генә, бары тик халык язмышы белән генә яшәргә тиеш. Ташлагыз газет-журналларда ми черетеп утыруыгызны. Ташлагыз пароход-сабын рекламаларыгызны. Сезгә заказчы хуҗа кирәкми. Сез үзегез хуҗа. Тукайның көчен юкка-барга сарыф итәргә кемнең дә хакы юк. Вак эшләрегезне йөртер өчен сезнең үз адвокатыгыз, йорт эшләрегезне карарга үз хезмәтчеләрегез булыр. Сез — даһи шагыйрь, иҗат итегез! Калганы минем эш...

Үзенең каршысында шактый мәгълүматлы, заманча тәрбия алган татар хатыны торганын Тукай, ниһаять, аңлады, аның зиһен түрендәгеләрнең барысын да әйтеп салды бу серле ханым.

— Менә хәзер аңлый башладым инде, сез — Фон-Мек! — диде Тукай.

Хатын җанланып китте:

— Котлыйм! Афәрин! Браво, Тукай! Мин ялгышмаганмын. Сез хәбәрдар шагыйрь. Дөрестән дә, мин, Фон-Мек кебек, сезнең химаячыгыз булырга телим... Шикләнмәгез, Тукай. Менә, алайса мин сезгә кемлегемне ачарга мәҗбүрмен, — дип ул чадра астыннан Тукайга балдагын сузды. Тукай, балдакны алып, андагы язуларны укыды:

— Могҗиза! Сез тайный советник Әхтәмов кызымыни?

— Тсс! — Бу балдак сезгә булган хөрмәтем һәм мәхәббәтем билгесе! Алыгыз!

Тукай балдакны тиз генә иясенә сузды:

— Кичерегез, ханым, мин бүләкләр алырга күнекмәгән! — диде.

Хатын балдакны теләр-теләмәс кенә шагыйрь кулыннан алды да:

— Сезнең тәкәббер икәнегезне мин яхшы беләм, — диде. — Балдакны кулыгыз белән алмасагыз, өстәлегезгә куям. Икенче балдак миндә кала. Балдакта тагын язу бар, укыгыз!

Тукай өстәлдәге балдакны әйләндереп бакты:

— Мөгайдине ишетеп белүгә караганда...

— ... күреп белү яхшырак, — дип өстәде ханым. — Икенче өлеше бу балдакта, миндә калачак.

Тукай балдакны тоткан килеш аптырап утыра бирде, ханым бу сөйләшүнең хуҗасы иде:

— Беләм, «Тәсмәгы бин Мөгайди хәйрен мин өн тәраһе». (Мөгайдине күреп белүгә караганда, ишетеп белү яхшырак) сезнең яраткан сүзегез. Ә мин үземчә: «Мөгайдине ишетеп белүгә караганда, күреп белүең яхшырак», — дип яздырдым. Дөрестән дә, сезне күрү — минем өчен зур бәхет. Берсе сездә, берсе миндә калыр балдакларның. Мин чыгып киткәч, теләсәгез тәрәзәдән атыгыз. Хәерчеләргә бүләк итегез, әмма минем алдарга кире какмагыз, зинһар. Бу — минем олы үтенечем. Мин — сезнең дустыгыз...

(Дәвамы киләсе санда).

# ИЛ ЯШӘВЕ — ҖЫР БЕЛӘ

Алар автобус килүен озак көттеләр. Әйе, сөйләшенгән, вәгъдә кылынган. Тик дөнья дигәнең иртәгесен — кичкә, кичкесен бүгенгә кабул итми. Ара ерак, төрле хәлләр булуы мөмкин. Артистлар да, җитәкче дә борчуларын башкаларга белдерми генә сабыр иттеләр, карашлар юлда иде. Вакыт шактый алга тәгәрәсә дә, өметләрен өзмәделәр, төшенкелеккә бирелмәделәр. Ниһаять, автобус килде. Аннан беренче булып тәбәнәк буйлы, ачык йөзле, кара кашлы ир сикереп төште, исәнләште һәм гафу үтенгәндәй:

— Сезгә кереп булмый, Казан тирәли әйләндек, сәгатьтән артык вакыт әрәм иттек, — диде һәм артистларны автобуска чакырды, ә үзе кунакларның кием-салымнарын, музыка аппаратларын, уен коралларын ташырга кереште. Ул — Кама Тамагы районының мәдәният бүлеге мөдире Әлһап Хәйруллин икән. Артистларны алырга үзе килгән.

Юл кешесенең юлда булуы хәерле. Автобус кузгалып та китте. Ул Кама Тамагы районына юл алды. Борыла-сырыла бара торгач, асфальт юллар да бетте. И, Ходаем, юл михнәтен күп йөрүче белә инде. Ә автобуста нәкъ шундыйлар. Тик юл сикәлтәләрен, авыл арасындагы чокыр-чакырларны алар җыр, музыка белән тигезләделәр һәм Көрәлегә килеп җиттеләр. Юлда Роза Габидуллинаның кулыннан гармуны төшмәде. Баянчы, җырчы Розаның чишмәдәй саф тавышына, автобустагы җыр әһелләре кушылды, уртак җыр яңгырады. Ә фольклор ансамбле җитәкчесе Рәис Сафиуллин сәфәрчеләргә аңлатмалар бирә барды, авыллар белән таныштырды, аларның тарихи үзенчәлекләрен ирештерде, җиләк-җимеш мул үсә торган төбәкләр хакында сөйләде.

Автобустан коелган артистлар тиз генә үз рольләренә керә алырмы, юл буенча җырлап килгән кешеләр сәхнәгә чыккач, тавышсыз калмасмы, дигән шөбһә артистлар сәхнәгә күтәрелгәнче күңелне бимазалап торды. Сөбханалла! Ансамбльнең җырчылары, музыкантлары матур киемнәрдән чыгып, беренче аккордларны алгач, сәхнәдәге юлдашларымны таныймый тордым. Ару-талу билгесе югалган, йөзләре көләч, үзләре бәхетле. Баянчы, композитор Рәис Сафиуллин гармунын кулларында биетә-биетә дә, җырчыларга ым кага. Күңел кылларына чиртә-чиртә җыр, музыка агыла. Дөнья мәшәкатьләрен оныткан тамашачы да шул күңелле моң дулкынында тибрәлә, йөзә. Наталья Ярхамова, Нил Исламов, Нәҗия Мусина, Әлфирә Афанасьева, Роза Габидуллина, Дания Дәминова, Разия һәм Нәкыйп Ибәтуллиннар, Альфред Ситдыйков, Рәис Сафиуллин бу мизгелдә тамашачы-халык өчен яшиләр. Алар җырлап үзләренең дә, башкаларның да күңелләрен ачалар. Озакка сузылган алкышлардан соң сәхнәдән кабат җыр яңгырый. Алар өчен халык үтенече изге икән — ялындырмыйлар. Көрәлеләргә якташлары Рәис Сафиуллинны, Альфред Ситдыйковны, Дания Дәминованы үзләренең сәхнәләрендә күрү кадерле дә, горурлык та иде.

Артистларга килгәндә, алар — үзешчәннәр. Һәм һәвәскәрләрнең дә ниндие әле! Халык ансамбле исемен йөртә, төрле фестивальләр лауреатлары, анда катнашучыларның җырлап, күңел ачып йөрүенә 10-40 ел. Әнә дистәдән артык җыр авторы, курайчы, баянчы, җырчы Нил Исламов 1957 елдан бирле үзешчән сәнгатьтә катнаша һәм музыкага, сәхнәгә багышланган гомере өчен аз гына да үкенми.

— Җомга көнне Башкортстаннан кодаларым кунакка килергә тиеш иде, ә мин монда йөрим, — ди Нил ага. — Туганнарым, кодаларым аңлыйлар, чөнки сәхнәгә күтәрелә торган ансамбльгә мин хыянәт итә алмыйм. Аягымда тромбофлебит, баксаң, өйдәге аксак картка сәхнәдә канатлар үсеп китә, авыртуларымны онытам, яшәрәм. Музыка, баян, курай моңы минне сихри дөньясында яшәтте һәм яшәтә. Аның курайда, баянда, гармунда татар халык көйләрен уйнап, буыннан-буынга күчеп килгән музыкаль мирасны кабат тамашачыга зур осталык белән ирештерүе батырлыкка тиң. Әйе, Нил ага кебек һәвәскәрләр җырга, музыкага тугрылык саклый. Әлеге сүзләрне ансамбльнең һәр артистына карата әйтергә мөмкин. Мәсәлән, җырчы Нәҗия Мусинаны тамашачылар икенче Зифа Басыйрова дип кабул итәләр. Разия Ибәтуллинаны, Наталья Ярхамованы алар төпе буе да тыңларга әзер. Бу — һәвәскәр башкаручыларның югары осталыгы, профессиональлеге хакында сөйли. Җитәкчеләре Рәис Сафиуллин аларны шул биеклеккә күтәргән.

Татарстанда һәм элеккеге СССРда чыгышлары белән дан тоткан, лауреат исеменә лаек булган ансамбльнең җитәкчесе Рәис Сафиуллин җиденче дистәне тутырып килгәндә дә үзенең артистлык, оештыру, башкару осталыгын югары кимәлдә саклап калган. Күпләгән үзешчән артистларның остазы алдында олы ихтирам белән баш иясе һәм барлык тамашачылар исеменнән рәхмәт сүзләре белдерәсе килә. Хәзерге вакытта барлык артист халкы тамашачыга акчага хезмәт иткәндә, Казандагы Сәетгалиев исемендәге мәдәният йорты каршындагы халык фольклор ансамбленең бушлай зур концерт күрсәтүен дә истә тоту кирәктер.

Гәрчә, һәвәскәр артистларның махсус автобуслары да һәм хәзерге юл бәяләрен күтәрерлек сәмәннәре дә юк, заводтагылар эш хакы күрми, ә пенсионерның акчасы санаулы. Шулай итеп, транспортны барасы районнан гына сорыйсы кала. Әнә Кама Тамагының район мәдәният бүлеге мөдире Әлһап Хәйруллин ансамбль җитәкчесе Рәис Сафиуллинның үтенечен аңлаган да, Карл Маркс исемендәге хуҗалыктан автобус алып, башкалабызга үзе килгән. Ә хуҗалык җитәкчесе Дамир Сабиров клуб бинасына концерт белдерүен элдереп кенә калмаган, кунак килгәч, ит пешә, ит пешмәсә, бит пешә, дигән әйтемне истә тотып, ике сарык чалдырган Рәис авылдашлары белән бер залда утырып, рәхәтләнеп концерт та карады һәм соңыннан сәхнәгә менеп, артистларга рәхмәт сүзләрен дә җиткерде. Югыйсә, авылда кызу эш өсте: урак, сука, печән, төзелеш һ.б. Рәхмәт аңа, чын ирләрчә сәнгать кешеләре хезмәтен бәяли һәм авылдашларын ял иттерә белә икән.

Кала кадәр каладан атлап-данлап чыгып киткәч, бер концерт белән чикләнү килешми. Алдан сөйләшенгәнчә, Д.Сабиров әйдәгән хуҗалык автобусы артистларны Балтач авылына китереп куйды. Клуб мөдире Фәрит Гайфуллин кунакларны озата килде. Артистлар Балтач җиренә аяк басканда Әлһап Хәйруллин да Кама Тамагыннан килеп җиткән, аларны көтә иде.

Сөбханалла! Мәдәният йортында гөлләр үсеп утыра, сәхнә йолдызларына стенд эшләнгән, якташлары драматург Туфан Миңнуллинның 60 еллыгына багышлап күргәзмә оештырылган. Мәдәният йорты мөдире Раушания Гатауллинаның тынгысыз җан икәнлеге күренеп тора.

Балтачлылар концерттан төнге сәгать бердә генә таралды. Алар артистларга рәхмәтле иде. Тик «Балтач» хуҗалыгы җит... Әхмәт Зыятдинов кы... мәшәчылар арасында... нмәде, сәхнәгә күтә... де, үзешчәннәргә р... әйтмәде. Авылдашла... хәлне:

— Бүген безнең а... яшьләр туй итә, рәис... да, — диделәр. — ... — эшлекле кеше, ху... төзекләнә бара, халы... печтән йортлар ... — дип тә өстәделәр... лайдыр, авылның, ху... биналарының төзекл... згә ташлана. Әмма ... да: «Өе биек, өйрәсе ... — дигән әйтем дә ба... лтач» хуҗалыгы аш... ндә кунакларга чәй ... ргә бер кап чәй та... лар бугай. Көрәлә... кайнар, баллы чәйд... тәмсез ак су аларның... гыннан үтмәде. Ә ху... кның өч умарталыг... алардан бик мул ба... нуын балтачлылар ... сөйләде.

Сәхнәдә кырыкта... тык әсәр уйнап, ку... баянын төшермәгә... самбль җитәкчесенә... сыз төннән соң иртән... кны да кичерергә тур... де. Хуҗалык рәисе: ... сезгә транспорт вәгъ... мәдем», — ди, ә к... куйган автобус күр... вашиягә юл тотка... медән артык кешен... кенә аппаратураны... алып кайтасы да ба... әле. Рәис Сафиулли... таннан район үзә... байтак кешене аякка... рды. Һәм артистлар... заннан алып кайткан... мәдәният бүлеге мө... озату да насыйп ик... автобус табып, безн... тачтан алып китте һ... ма Тамагы пристане... шлашты.

«Ракета»да утыры... раз мәшәкатьләрен ... кан җитәкче арти... белән киләсе җомга... кабат концерт бирү ... да сүз башлады...

**Сәрмәдия СӨЛӘЙ...**

● Скрипка моңы. Эрот ЗАРИПОВ рәсеме.

## ГАЗЕТА ҺӘМ УКУЧЫ

### Безнең теләк!

Ниһаять, бездә дә мәдәният яңалыкларын ашыгыч рәвештә яктыртырдай яңа басма — «Мәдәни җомга» пәйда булды.

Без XXI гасыр — мәдәният гасыры булыр дип, Татарстан үрнәге сәясәт өлкәсендә генә түгел, мәдәният өлкәсендә дә формалашыр дип өметләнәбез. Бу басма шушы модельне формалаштыруга булышлык итсә иде дигән теләктә калабыз.

**Фәридә ЗӘБИРОВА,**
Татарстан Республикасы Архитекторлар берлеге рәисе,
иҗат берлекләренең һәм җәмгыятьләренең координация шурасы рәисе.

### «Балкыш»ка — алкыш

Татарстан радиосы тапшырулары көннән-көн матурая, байый бара. Әлеге тапшыруларны оештыручы журналистларның күбесе мактауга лаек дип уйлыйм мин. Кем ничектер, ә менә мин үзем Гадилә Нургали әзерләгән тапшыруларны аеруча яратып тыңлыйм. Ул һәр җомга көнне оештыра торган «Балкыш» тапшыруын тыңлау үзе бер зур бәйрәм. Өстәвенә, тавышы да бик назлы, ягымлы яңгырый аның. Тагын шунысы сөенечле, ул үзенең һәрбер тапшыруын Коръән сүзләре белән башлап җибәрә. Аңа «Мәдәни җомга» гәзите аркылы изге эшендә зурдан-зур уңышлар, нык сәламәтлек һәм бәхет теләп калам.

**Нәҗия САБИРОВА,**
хезмәт ветераны.
Казан шәһәре.

МАТБУГАТ АКСАКАЛЫ

# Сәях Тәхау

Җөмһүриятебез журналистларының Х.Ямашев исемендәге бүләге ... Татарстанның атказанган ...нияг хезмәткәре, матбугат ак... Касыйм Тәхауның исеме ...-журналларда 50 нче еллар ... күренә башлады. Ка... Тәхау язган мәкаләләр тема... яналыгы, кузгаткан про... әһәмияте белән ...ларының дикъкатен тиз җәлеп ...

Касыйм Тәхау журналистикага ... тормыш тәҗрибәсе туплап ки... үз йөзен тапты. Ул 1925 ... 10 сентябрендә республика... Шөгер (хәзер Лениногорс... районындагы Тукмак авылын... крестиян гаиләсендә туа. 1943 ... гыйнварында, Шөгер урта ...тәбенең 9 нчы сыйныфында ... армиягә алына һәм анда ... хезмәт итеп, 1956 елның фев... авиация техник-капитаны ... демобилизацияләнә. ...дән кайткач, башта Казан ...ларының берсендә эшче, ан... сон Казан университетының ...лек ияләре һәм кеше физио... кафедрасында өлкән пре... булып эшли, шул ук ва... читтән торып университет... тарих-филология факультеты... да укый.

...62 елның июлендә Касыйм ... «Социалистик Татарстан» ...ендә әдәби хезмәткәр булып ... башлый. Гәзиттә нинди генә ... алынса да, хезмәтенә зур җа...лык белән карый: Аны, ба... да бигрәк, милләтебезнең, ...ниятебезнең хәле, телебезнең ...-ел ярлылана, чүпләнә, мил... традицияләребезнең, гореф-га...ләребезнең онытыла баруы бо...

Касыйм Тәхау дүрт дистә ел ма...гатта эшләү дәверендә үзенең ... шөгыленә тугрылыклы кала ... Моннан берничә ел элек ул ... Мордовиядә үткәрде һәм ... татарлар яшәгән авылларда ... Өлкән журналистның кү...ездәге Мордовиягә баруы та..., чөнки ул республикада ...үзе 950 мең чамасы халыкның ... татарлар бит. Мордовия ...лятыбызга Шәриф Камал, Һа... Такташ, Габдрахман Әпсәлә... тебек әдипләрне биргән төбәк ... Ул республикада 67 татар авы... бар. (Касыйм Тәхау ул авыл... кайларда урнашуларын ...кән карта ясап, аны матбу... бастырып та чыгарды). Тын... журналистны андагы мил...ташләребезнең тормыш-көнкү...ләре, телебезнең, гадәт-йоларыбызның милли үзенчәлекләребезнең торышы кызыксындыра. Әмма Мордовиядә ул үтә аяныч хәлгә — милләттәшләребездә татарлыкның отыры тәкәнә баруына юлыга. Әйтик, Казанда чыга торган татар телендәге гәзит-журналларны анда бары тик берничә кешенең генә алдыруы, татар авылларындагы мәктәпләрдә татар балаларының урысча гына укулары ачыклана. Татар поэзиясенең классик шагыйре Һади Такташ туган элек 615 йортлы, дүрт мәчетле Сыркыдыс авылының бүген эзе дә калмавын, аның Парча елгасы аръягындагы калкулыклардан болын ягына — тигез җиргә күчеп утырганын, Такташ Сыркыдысының беткәнен, юкка чыкканын, тик зираты гына үз урынында калганын күрә. «Бөек Ватан сугышыннан соң күпләр Сыркыдыдан Мәскәүгә һәм якындагы шәһәрләргә күчеп киткәннәр. Авыл хәзер Сыркыды дип түгел, ә Соргудь (мукшыларның «сура куд» — «сөрелгән» сүзеннән) дип йөртелә икән. Соргудьта 100 хуҗалык (шуларның 70 ендә татарлар яши) бар. Һади Такташ исемендәге күмәк хуҗалыкның үзәк утары да шунда. Ләкин шагыйрьне анда бик начар беләләр. Яшьләр мәшһүр авылдашларының үлемсез әсәрләрен ана телендә укый алмыйлар, чөнки татарча бөтенләй диярлек белмиләр, алар үзара да вата-сындыра урысча гына аңлашалар», — дип ачына өлкән журналист Сыркыдыга багышлаган мәкаләсендә.

Касыйм Тәхау күләмле романнары белән дан яулаган Габдрахман Әпсәләмовның туган авылы Иске Аллаголга да кагыла. Ләкин анда да ул күренекле әдипнең туган һәм балалык елларын үткәргән йортны тапмый. Аңа колхозның терлекчелек фермасы каралтылары яңашәсендәге бер буш урында, Әпсәләмовларның өйләре шушы төштә иде, диюдән узмыйлар.

Габдрахман Әпсәләмовның әтисе Сафа агай хәлләләрдән саналган. Ул 30 нчы еллар башында гаиләсе белән Мәскәүгә күчеп киткән һәм туган авылына бүтән әйләнеп кайтмаган. Булачак әдип бала чактан ук әдәбият белән кызыксынган, гаиләре Мәскәүгә күчкәч, Муса Җәлил оештырган әдәбият түгәрәгенә йөргән. Аның беренче шигыре дә М.Җәлил мөхәррирлек иткән «Октябрь баласы» журналында басылган.

Сыркыдыдагы кебек үк, Иске Аллаголда да хәзерге авылдашлары бөтен татар дөньясының горурлыгына әверелгән атаклы якташларының истәлеген мәңгеләштерүгә битараф карауларына, Г.Әпсәләмовның да, Һ.Такташныкы кебек үк, туган авылында ни бюсты, ни музее булмауга борчыла Касыйм Тәхау һәм, Иске Аллагол авылындагы колхоз Габдрахман Әпсәләмов исемен йөртә бит, ничек алар үзләренең мәнсезлекләренә республикаларындагы башка милләт вәкилләре алдында кызара белмиләр икән, ди.

Касыйм Тәхау тынгысыз журналист булу өстенә әдәби иҗат эше белән дә шөгыльләнә. Ул — илледән артык җыр текстлары авторы. Аның шигырьләренә Нәҗип Җиһанов, Рөстәм Яхин, Александр Ключарев, Заһид Хәбибуллин, Сара Садыйкова, Әнвәр Бакиров кебек композиторларыбыз язган җырлар радио-телевидениедән, эстрададан даими яңгырап тора. Ул кече яшьтәге һәм мәктәп яшендәге балаларны да онытмый. Аның балалар өчен язган җырлары, шигырьләре, хикәяләре, парчалары «Салават күпере», «Ялкын» журналларында һәм «Сабантуй» гәзитендә еш басылалар. Татарстан китап нәшриятында өлкән журналист урта яшьтәге мәктәп балалары өчен туган ягыбыз табигатенең матурлыгы, республикабызның төрле төбәкләрендә очрый торган җәнлекләр, кошлар, бөҗәкләр, бакча һәм болыннарыбызны бизәүче талымсыз нәфис чәчәкләр, урман-кырларны соклангыч сайраулары белән җанландыручы җырчы кошлар һәм ел фасыллары турында «Табигать мизгелләре», «Ай артыннан ай туа» исемле китапларын да бастырып чыгарды.

К.Тәхауның мәкаләләре, зарисовкалары, очерклары, шигырьләре генә түгел, чәчмә әсәрләре дә шактый. Аларның күбесендә, мәсәлән, «Авылым парчалары», «Чаллы этюдлары» язмаларында намус, әхлак мәсьәләләре күтәрелә. Аның каһарманнары яшәү мәгънәсен ил гамен кайгыртуда, башкаларның бәхетле, имин яшәвендә күрәләр.

Мин бу көннәрдә өлкән журналистның дачасындагы шәхси архивында казындым. Нилләр генә юлыкмадым анда! Дәфтәр-дәфтәр тәкмаклар, «Әйтмәс җирдән әйтерсең» һәм «Башка нинди гыйбарәләр килмәс» дигән баш астында йөзләгән хикмәтле җөмләләр (аларның дистәләгән вариантлары бар), нәсерләр, истәлекләр, шигырьләр, төрле җәнлекләр, кошлар, дару үләннәре, гөмбәләр, җимеш агачлары, үләннәр, чәчәкләр, гөлләр турында тәфсилле язмалар, мәктәпләр өчен төрле тармакларга караган кызыклы сүзлекләр, хатлар, схемалар, карталар, фотографияләр...

Касыйм Тәхау инде лаеклы ялда булса да, өендә кул кушырып утырмый. Үзе якыннан белгән мәрхүм язучылар, композиторлар, артистлар, сәнгать әһелләре турында истәлекләр яза. Җитмеш яше тулган көннәрдә без аңа иҗат эшендә һәм тормышында уңышлар, ныклы сәламәтлек, озын гомер телик.

**Гурий ТАВЛИН.**

---

КАРАШ

## «Шүрәле»не үзебезчә карый алырбызмы?

...ел мин М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт ... опера һәм балет театрында уздырылган ...ф Нуриев исемендәге халыкара классик балет ...лендә булдым. Максатым — «Шүрәле» ба... карау һәм Фәрит Яруллин музыкасын тыңлау ...

...ренең куелу тарихы шактый гыйбрәтле. 1941 ... татар тамашачылары әлеге балетны түземсез... көтеп ала. Җәй аенда Мәскәүдән һәм Ленин... чакырылган балет белгечләре Федор Лопу... Петр Гусев һәм Леонид Якобсон «Шүрәле» ...ның каралама вариантын сәхнәләштерүгә ...р. Ләкин Бөек Ватан сугышы бөтен матур ... чәлпәрәмә китерә. Фәрит Яруллин ... китә һәм 1943 елның көзендә һәлак була. ... итеп, «Шүрәле» әсәре премьера булып фә... 1945 елның 12 мартында гына дөньяга чыга. ... премьера 1952 елны Я.Бурнак тарафыннан ... инде 1957 һәм 1970 елларда Фәрит Ярул... бу әсәре Леонид Якобсон хореографиясендә дүртенче тапкыр сәхнәгә менә. Соңгы тапкыр ул 1986 елны РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе К.Рассадин тарафыннан куела. Әлеге премьераны мин дә караган идем.

Шундый мәшһүр әсәрнең сәхнә бизәлеше өчен жаваплы булган Русиянең сәнгать эшлеклесе А.Кноблокка зур рәхмәт: аның эшендә милли үзенчәлек, татар моңы ярылып ята. Ләкин әсәрнең хореографиясенә карата бу сүзләрне әйтеп булмый. Ник дигәндә, спектакльнең башыннан алып ахырына кадәр милли костюмнар кигән егетләр-кызлар йә башкортча, йә марича, йә үзбәкчә бармак шартлатып (Сабантуй сәхнәсендә) биеделәр. Бию дип гомумиләштереп әйтәсем килми, чөнки бу өлкәдә мин белгеч түгел. Ләкин әлеге кимчелекләр хәтта иң дилетант тамашачының да күзенә чалынадыр. Алар татар аһәңенә хас булмаган ниндидер бер винегрет хасил итәләр, дисәм дә һич арттыру булмас. Күрәсең, мөхтәрәм балетмейстерыбыз, татарны үзбәктән аера алмыйча, аннан-моннан гына йолкып, бәйнәлмиләл әсәр ясамакчы булгандыр.

Ярар, күпне күргән «Шүрәле» бит инде. Бу юлы да чыдады бичара. Ләкин заман үзгәрә, быел булып узган тамашада да шактый җитди җитешсезлекләр бар, дип уйлыйм мин. Искиткеч бай һәм дәртле музыка, дәртле ритмнар. Тик артистлар шул музыкага бер-ике сикереш ясыйлар да тыналар. Психологик драмалар һәм комедияләр кую өчен Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры да бар лабаса. Ә бу — балет. Музыка һәм бию бергә кабатланмас вә үзенчәлекле аһәң тудырырга тиеш кебек. Монда исә музыка белән бию икесе ике телдә сөйләшә.

Композитор Фәрит Яруллинның әсәре төрле буяуларга, психологик киеренкелеккә шундый бай ки, тыңлап утырганда хыялыңда әллә нинди матур дөньяларда очып йөри башлыйсың. Ә сәхнәдә тәрт-тәрт итеп йөгереп йөргән артистларга карауга, милли музыканы һәм сәнгатьне аңламаган кеше эше бу, дип уйлап куясың.

Артист кеше әсәрне йөрәге аша үткәргәндә генә тамашачының мәхәббәтен җәлеп итә ала. Бу җәһәттән Былтыр ролен башкарган Айдар Әхмәтов белән Шүрәлене уйнаган Вадим Яруллин гына әсәргә җан өрә алдылар, дип әйтәсе килә.

Кыскасы, кем әйтмешли, тәре күтәреп, елның елында Аурупага чыгып йөргәнче, милләтебезнең йөзек кашы булган «Шүрәле» балетын бар яктан да камил итеп сәхнәгә менгерсәләр, бу хезмәт ошбу труппаны дөньяга ныграк танытыр иде. Күрәсең, «Шүрәле»гә акча калмагандыр. Ни өчен татар әсәрләрен куймыйсыз, дигән сорауга, андый спектакльләргә халык йөрми, дип җавап биреп котылу җиңелрәк булса кирәк.

**Фәнис ҖИҺАНША,**
Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясе студенты

КҮЗГӘ-КҮЗ КАРАП

## Равил ГАЙНЕТДИН:



# ИСЛАМ —

***М**әскәүнең Казан вокзалына килеп төшкәннән соң, метро поездына утырып бер генә тукталыш барасы. Шунда төшеп, җир асты юлын узгач, бераз гына өскә күтәрелүең. Бер якта — чиркәү, икенче якта — Олимпия корылмалары. Гадәттә, без шушы юлдан Мәскәүнең тыйнак, әкке мәчетенә килеп чыга идек. Бу баруымда һич тә алай булмады. Ерактан ук балкып торган зәп-зәңгәр гөмбәзле, өр-яңа, ап-якты ай каршы алды. Ул үзенә чакырып тора, тирә-якны нурландыра. Русиянең уртасында син үзең дә, синең динең дә берәүдән дә ким түгел, дигәндәй. бабайлардан мирас булып калган горурлык хисенә кагыла да, күзгә яшь китерә.*

*Сөбханаллаһы, дими нәрсә әйтәсең инде.*

***Мәскәү Җәмигъ мәчетенең имам-хатыйбы, Русиянең Үзәк Аурупа өлеше мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе, мөфти Равил хәзрәт Гайнетдин һәрвакыттагыча ачык йөзле, күркәм, кунакчыл. Үземне, халкыбызны кызыксындырган сорауларны аңа җиткердем, яңа чыга башлаган «Мәдәни җомга» гәзите өчен әңгәмәне махсус язып алып кайттым.***

Мәскәүдә һәм аның тирәсендә бер миллионнан артык мөселман яши. Мәскәү башкала булганнан соң биредә 8 миллион кеше яшәгән Бу гавәм арасында мөселман халкы югалып киткән шикелле иде. — ди хәзрәт - Ләкин мәчет-мәдрәсә тирәсенә якынрак килсәң, мөселманнарның җанлы яшәве күзгә ачык күренә Мәчет тирәсендә яшьләрнең булуы, олыларның килүе, хәтта җәйге ял вакытында да ыгы-зыгының тукталмавы, мәдрәсәдә укырга дип язылырга килеп торучыларның кимемәве шатландыра, Сентябрь аеннан тормыш тагын җанлана, ата-аналар балалары белән мәдрәсәдә, курсларда укырга агылып киләләр Шулай итеп, һәр елны бездә укырга 600-650 кеше йөри. Ислам нигезләрен үзләштерә Бу без әле бер мәчеткә генә кагыла Мәскәүдә икенче мәчетебез дә бар ич әле безнең! Татарская урамында. Анда да дини хәятне җанландырабыз Мәскәү ул — мөселманнарның үзенә күрә бер дини үзәге Мөселманнарның кыйбласы Мәккә булса, Казан — татар халкының кыйбласы Ул мәдәни яктан һәрберебезне бер үзәккә берләштерә Шуңа да Татарстан безнең туган җиребез Шунысы бик мөһим дингә ирек бирелгәч, тормышыбызда байтак үзгәрешләр барлыкка килде, яшәешебез рухи яктан нык җанланды Моны Мәскәүдәге тормышта да күрәбез Мөселман дәүләтләренең 40тан артык илчелеге, чит илләрнең 25тән артык иҗтимагый-мәгърифәт оешмасы барлыкка килүе моңа иң зур дәлил Элек Мәскәү Җәмигъ мәчете бөтен Аурупа өлешендә иң эре дини үзәк булып торган һәм якын-тирәдәге өлкәләрдә мәчетләр булмаган вакытта ул барлык мөселманнарны берләштергән, аларга юл күрсәткән. Әлбәттә, дини-мәдәни хәятне җанландырган Шуңа күрә ул мөселманнарның Ислам мәркәзенә әйләнгән дә Бу мәркәз хәзер Мәскәү һәм аңа күрше өлкәләрдәге мөселманнарны гына берләштереп калмады Бирегә ерактагы төбәкләрдән дә киләләр. Ислам үзәге белән бергә эш итәргә теләк белдерәләр Шуның нәтиҗәсендә Мәскәү һәм аңа якын төбәкләрдә яшәүче мөселманнарның Диния нәзарәте оешты Һәм ул Русия мөселманнары арасында гына түгел, бөтендөнья Ислам җиһанында, шулай ук Көнбатыш илләрдә дә дәрәҗәле дини үзәккә әйләнде.

Тормыш икътисадый яктан авыр булуга карамастан, әлхәмдүллиләһи, безнең Диния нәзарәтебез дистәләгән авылларда мәчет төзүгә матди ярдәм күрсәтеп тора. Русиядәге зур шәһәрләрдә мәчет төзү өчен җир алуга булыша Төзелеш өчен проектларны Диния нәзарәтебез карамагындагы архитектура бюросы эшләп бирә Яңа мәдрәсәләр ачу, Ислам җәмгыятьләренең яңа оешмаларын төзү, элекке мәчетләребезне кайтарып алу, яңарту-реставрацияләү болар барысы да Мәскәүдәге Диния нәзарәте башкарган эшләр Мәчетебезгә дөньяның бик күп төбәкләреннән, төрле илләреннән безнең белән эш итәргә, тыгыз элемтә урнаштырырга теләк белдереп киләләр Икътисадый кыенлыкларга карамастан, Диния нәзарәтенең яңа бинасын төзү тәгәлләнде, иншаллаһ. Хәзер аның тирә-ягын төзекләндерү, матурлау, тәртипкә китерү эшләре бара Югары белем бирү министрлыгыннан юридик рөхсәт алган Русиядәге бердәнбер югары Ислам уку йорты инде бер ел эшләп килә. Быел да укулар бүгенге көн таләпләренә җавап бирерлек классларда, аудиторияләрдә дәвам итә Кавказ якларыннан, Идел-Урал төбәкләреннән бик күп гаризалар килә Урта мәктәпне яхшы тәмамлаган егетләребез безнең югары Ислам уку йортында белем алырга теләк белдерәләр Бу да безнең дини хәятебезнең җанлануына бер мисал Нәзарәтебезгә караган Түбән Новгород мәхәлләсе җәмигъ мәчетенең 80 еллыгын билгеләп үттек Мәскәүдә. ЮНЕСКО белән берлектә, дини-милли мөнәсәбәтләрне туганнарча, дусларча хәл итү мәсьәләсенә багышлап конференция үткәрдек Аны уздыруда Русия Фәннәр академиясе һәм Кувайттә эшләп килгән Азия мөселманнары комитеты зур булышлык итте Шундый ук конференция Түбән Новгород шәһәрендә дә булды Түбән Новгородта да бер ел инде дини урта белем бирә торган һәм авыл мәчетләренә имамнар әзерләүче мәдрәсә эшли

Мәскәү, ничек кенә әйтсәк тә, барлык юлларны тоташтыручы шәһәрләрнең берсе инде Гарәп, мөселман дәүләтләренең юллары аның аша уза Кавказ якларына, Татарстан, Башкортстан җөмһүриятләренә, башка төбәкләргә китә торган зур кунакларыбыз да, гадәттә, иң элек Мәскәүгә килеп төшә Эшне Диния нәзарәтеннән башлап җибәрәләр Шулай ук Татарстандагы дини оешмаларга ярдәм күрсәтү өчен килә торган мөгаллим-укытучыларны, дәгъватчыларны эшкә чакыру, аларга визалар юллау безнең Диния нәзарәте аркылы башкарыла Әле генә Волгоград шәһәрен имам-хатиблы иттек Төрек-гарәп телләрен өйрәтү буенча гына түгел, ә мөселманнарга Ислам тәрбиясе, Ислам әхлагы иңдерүдә, Коръән-Кәримне аңлатуда, кыскасы, Ислам дине буенча ан-белем бирүдә имамнарыбыз халкыбызга зур булышлык итә Болар барысы да Мәскәүдәге Диния нәзарәте юлламалары буенча эшләнә.

Билгеле, Диния нәзарәте башка илләр белән дә зур һәм күпьяклы эш алып бара Әйтик, без дөньякүләм конференцияләрдә катнашып, чыгышлар ясыйбыз. Әле быел гына безнең делегация Австралиядә, Төркия, Америка, Мисырда һәм тагын да башка илләрдә булган җыеннарда бөтен Русия мөселманнары, аларның бүгенге көндәге хәяте һәм хәл итәсе мәсьәләләре турында сөйләдек Шулай ук гарәп илләре һәм Русия мөселманнарының ихтыяҗларын, үтенечләрен Русия җитәкчеләренә җиткерәбез. Чөнки аларның үтенечләре бик урынлы Гарәп дусларыбыз әйтүенчә, элеккеге Советлар Союзы гарәп илләре белән тыгыз элемтәдә торып, аларның яклаучысы да булган. Дөрес, бу мөнәсәбәтләр идеологик яктан төзелгән булса да, гарәпләрнең ышанычы-таянычын аклаган Ул чакта бөтен дөньяда ике зур көч яшәп килде — Америка Кушма Штатлары һәм Советлар Союзы Безнең ил исә үсеш юлына баскан өченче дөнья илләренең яклаучысы буларак чыгыш ясады Шулай ук аларның икътисадын үстерү өчен дә зур тырышлык куйды. Гарәпләр советлар дәверен онытмыйлар Алар бүгенге көндә дә Русия Федерациясенең гарәп илләре белән дус булуын телиләр Төркия, Гыйрак, Пакистан һәм башка илләр мөселманнары да шул фикердә Алар белән дус булып яшәүнең әһәмияте зур. Русия Аурупа һәм Азия кыйтгаларында урнашкан. Русиядә иң киң таралган диннәр - Православие һәм Ислам Без менә шуны онытмыйча сәясәт алып баруны бурыч итеп куябыз Дөрестән дә, илебездә Христиан һәм Ислам диннәре бер-берсенә хөрмәт күрсәтеп яшәсә, бер-берсен кимсетмәсә генә, Русиянең тынычлыгы тәэмин ителер Шул күзлектән карагандa, әлбәттә, без мөселманнарны һәм Ислам динe, аның тәгълиматы белән яшәүче халыкларны икенче сортлы итеп куюга каршы һәм бу хакта үзебезнең каттый фикеребезне әйтәбез

**— Равил хәзрәт, Мәскәү барлык мөселманнарның дини үзәге була аламы?**

Моңа кадәр Мәскәүне кырык чиркәүле шәһәр дип йөриләр иде Әмма биредә яшәүче милләттәшләребез башка дингә күчерерләр дип куркып тормаганнар, XҮ гасырда килеп утырып, үзләренең бистәләрен, гыйбадәтханәләрен төзегәннәр Ә бүгенгә Мәскәүдә ике мәчеттән гайре бер нәрсәбез калмаган иде Хәзер менә шул мәчетләребезгә карап Исламның Русиядәге торышына дөньякүләм бәя бирәләр.

Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәламнең бер хәдисендә «Мәчет ул — мөселманның да, Исламның да көзгесе», - диелгән Дөньяның төрле якларыннан килгән кунаклар безнең мәчетебезне тәртипсез, җимерек хәлдә күрәләр икән, димәк, монда Ислам хәяте дә шул хәлдә икән, дип бәя бирәчәкләр Әгәр дә мәчетебез пакьлеге, үзенең мәһабәт, затлы бинасы белән җәлеп итә икән, димәк, Исламның көче-куәте бар, ул халыкны үзенә чакырып, иман нуры таратып тора дигән сүз Менә шуны истә тотып, без Диния нәзарәтенең яңа бинасын төзедек тә Безгә бит мөселманнар гына түгел, ә яһүде дә, христианы да килә, күрсеннәр мөселманнарның да бинасын.

Зур дәрәҗәдә сөйләшүләр үткәрә торган конференция залыбыз да, кунаклар кабул итәрлек бүлмәләребез дә, залы китапханәбез дә, уку залларыбыз, классларыбыз да заманча җиһазландырылган Без моңа Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән ирештек Бинаның мөселманча, татар орнаментлары белән бизәлеше дә, шулай ук итеп эшләнгән гүшәмнәре, баганалары, «Аятел корси» белән нәкышләнгән имән ишекләре дә бездә горурлык хисе уята Без Русиядә, аның мәркәзе Мәскәүдә урысныкы дип саналган шәһәрдә мөселманнарның бер затлы, зәвыклы дини үзәге булуын теләдек Кайберәүләр Мәскәүдә мондый бина төзүгә җаны-тәне, теше-тырнагы белән каршы төште Башта безгә аны ике генә катлы итеп төзергә рөхсәт биргәннәр иде Аннан соң, төзи башлагач, җаен таптык тагын өченче катны күтәрергә дә рөхсәт алдык Гөмбәзләрен зурайту өчен дә рөхсәт кирәк булды Йөри-йөри. Аллаһыга шөкер. Мәскәү Җәмигъ мәчете янында өч айлы өч гөмбәз барлыкка килде Моның, әлхәмдүлилләһи, минем дәвергә, мин эшләгән вакытка туры килүенә бик горурланам

**— Равил хәзрәт, Татарстанның да үз Диния нәзарәте, үз мөфтие булды, Аллаһыга шөкер! Ләкин, миңа калса, баш нәзарәтне таркату ваклануга, бүлгәләнүгә, дини күтәрелештә артка чигенүгә китерде кебек...**

Уфадагы Диния нәзарәтен бүлгәләү бит Татарстан җөмһүриятендә Диния нәзарәте оешкач башланды Аннан соң Башкортстан җөмһүриятендә шундый нәзарәт барлыкка килде. Мәскәүдәге Диния нәзарәте иң соңыннан гына оешты.

**— Уфадагы Диния нәзарәтен таркату максаты 1912 елда ук туган. Шул ният 80 елдан соң тормышка ашты. Әллә инде барыбызның да мөфти буласы килдеме, әллә башка сәбәпләр бармы? Сезгә ничектер, миңа калса, бүген берләшү, бары тик берләшү генә максатка ярашлы.**

— Хәзерге вакытта Исламның куәтләнүе, аның көчле булуы Русия дәүләтенә кирәк түгел. Җитмәсә, без бүген тегендә бер, монда икенче диния нәзарәте төзеп, таркалабыз, бүлгәләнәбез Без үз кулыбыз белән үзебезне, төгәлрәк әйтсәк, Русиянең Аурупа өлеше һәм Себер мөселманнарының Диния нәзарәтен таркатабыз Болар Русия файдасына Шуңа аның җитәкчеләре сөенәләр генә, мөселманнарның бу эшенә безнең катнашуыбыз да кирәкми. бүлгәләп тә торасы юк, баш ватып уйлыйсы да, программалар төзисе дә юк, диләр Мөфтиләр үзләре үк бер-берсен пычрата, бер-берсенә каршы килеп, «сугышып» ята Кыскасы, таркалуга без үзебез сәбәпче Моны тирәннән аңлап, 1994 елда ук мәсьәләне көн тәртибенә куеп сөйләшергә, киңәшергә һәм таркалуны туктатып, берләшергә кирәк иде Соңгы вакытта миңа ике мәртәбә Татарстан Президенты Миңтимер Шәймиев белән очрашырга туры килде Бу очрашуларда мин аның Ислам дине, аның бүгенгесе, киләчәге турындагы фикерләрен белеп сөендем. Әлбәттә, бүген берләшү безгә аеруча мөһим Әмма барыбыз да бик яхшы аңлыйбыз: бер үзәктән генә торып Русиянең Ерак Көнчыгышы белән дә, Калининград өлкәсе белән дә идарә итеп булмый Хәзерге вакытта Уфада утырган мөфти, нинди генә булса да шәехисламмы ул, диния нәзарәтенең рәисеме мәхәлләләрдә, ерак төбәкләрдә эшнең ничек баруын һәм анда нинди мохтаҗлык, ихтыяҗ барлыгын белеп бетерми Диния нәзарәтләре, мөфтиләр кирәктер ул Моңа Төркия мисалы дәлил Анда да берничә мөфтият бар. Ләкин аларның бер үзәге, бер мәркәзе бар. Әнә шундый дини-мәркәзнең бездә дә булуы бик зарур

Шушы үзәккә барлык мөфтиләр җыелып, ургак тактиканы, идеологияне формалаштырырга, ә Үзәк шул фикерне үткәрүче булырга тиеш Шушы фикерне алга сөргән оешма дәүләт алдында да, тышкы эшләрне хәл иткән вакытта да абруйлы Бүген нәкъ менә без үз сүзебезне Русия мөселманнары исеменнән әйтәбез һәм бу карарны дәүләт җитәкчеләренә җиткерәбез дә Ә соңгы вакытта барлыкка килгән ИКЦ, ВИКЦ дигән мәдәни-дини үзәкләр Русия мөселманнарының ихтыяҗларын хөкүмәткә җиткерерлек дәрәҗәдә түгел Хәзер әнә шундый берничә үзәк бар. Алар һәрберсе үз сүзен аерым-аерым әйтә Шуна тавышыбыз көчсез, безне ишетмиләр Сүзебезне ишетсеннәр, фикеребезгә колак салсыннар өчен, безнең берләшүебез, бердәмлегебез бик зарури

Дөрес, Русия мөселманнарын таркатырга, көчсезләндерергә күптән, гасыр башыннан бирле тырышалар Кызганыч, бүлгәләү хәзер тормышка ашты Безнең таркалуыбызга чит илләрдән килгән дин кардәшләребез дә булышты Моңа алар да сәбәпче Тегеякбу дини оешмага аерым-аерым ярдәм итеп, һәркайсын мактап үсендерәләр Шулай итеп, алар безне бүлгәләп бетерүгә ирештеләр Бу хәлләргә тирәнтен һәм төрле яклап анализ ясап, артыбызга борылып

# дөньяга зур алгарыш, бөек ачышлар биргән дин

караганнан соң, аек фикерле кешеләр моны бик яхшы аңларга тиеш. Безнең ата-бабаларыбыз Ислам динен мең ел буена саклаган, тәрәккый иткән, бидгать мәсхәбләренә кермичә, безгә китереп җиткергән. Бүген исә ярым-йорты гыйлем алган имамнарыбыз Ислам белгечләре булып, зур мөфтиләргә әйләнгәч, алар инде бездә баһауллалыкны да китереп чыгардылар. Алар хәзер безгә әхмәдилек кебек әллә нинди «яңа» агымнарны китереп кертәләр, шулай итеп, халкыбызны хак, туры, традицион мәсхәбеннән адаштырып, буташтырып бетерүгә сәбәпче булалар. Инде акыллы, аек фикер белән аңлашырга, бу хәлләрнең кемгә файдалы булуына төшенергә вакыт җитте. Әйе, безгә берләшергә кирәк.

Үзебез бу хакта, көчебездән килгәнчә, Татарстан мөфтиенә дә әйтә киләбез, берләшергә вакыт җитте, амбицияләрне читкә куеп, үзеңнең бер позицияңне булдырырга, туры юлдан тайпылмаска, принципларны бозмаска кирәк, дибез. Көчебездән килгәнчә шушы юнәлештә эшләргә тырышачакбыз да. Аллаһы Тәгалә, иншаллаһ, ярдәменнән ташламас, дип өмет итәм. Күп кенә мөфтиләр белән фикерләребез туры килә. Аллаһы Тәгалә насыйп әйләсә, берләшү буенча якын арада мөфтиләребез белән очрашу үткәрергә исәп.

**— Равил хәзрәт, Ислам диненең Русиядәге хәле ничек? Сезне нәрсәләр борчый, нәрсәләр шатландыра?**

— Җәмгыятьне демократик юлга салу безнең файдага булды, чөнки динебезне хәзер үзебез теләгәнчә тота алабыз. Мәчет, мәдрәсәләрне төзүдә бернинди каршылык юк. Акчаң, ярдәмчеләрең генә булсын. Яшьләрне укырга җибәрү, балаларны үзебезнең төбәкләрдә укыту мөмкинлекләре бар. Көчеңнән килсә, матбугат, радио-телевидение аша Исламны пропагандаларга мөмкин. Моны эшләве бигрәк тә төбәкләрдә, Татарстан, Башкортстан җөмһүриятләрендә җиңелрәк. Мөселманнар өчен газит чыгарырга, тапшырулар эшләргә дә була.

Соңгы вакытларда хаҗ кылулар, мәгърифәтчелек эше, дини җәмгыятьләр төзү, мәдрәсәләр ачу — болар безне шатландыра, сөендерә. Әмма безне көендерә торган нәрсә дә бар. Урыс православие чиркәве үз динен дәүләтнең рәсми дине итү буенча закон проектлары әзерли. Бу проектларны мөселман диния нәзарәтләренә җибәрәләр. «Сез моны тикшереп, үзегезнең фикерләрегезне әйтегез», — диләр. Бу исә безне сак, уяу булырга кирәклеген искәртә. Чөнки православие динен Русиянең бердәнбер рәсми дине итәргә йөрүчеләр Русия Президенты аппаратында да, Дәүләт Думасында да, Федераль Җыенда да бар. Бу турыда зур сөйләшүләр үткәрелә. Әмма Русиядә моны эшләү мөмкин хәл түгел, дибез. Чөнки бу илдә 20 миллион мөселман яшәгән вакытта, Русиянең Аурупа һәм Азия дәүләте икәнен күз алдында тотканда, андый эшне эшләү язык гамәл.

Икенче яктан, Русиянең дин эшләре буенча кабул иткән законы бар. Шуның нигезендә дин өлкәсендә демократия түгел, бәлки, анархия урнаштырырга мөмкиннәр. Шушы канунга таянып, безгә килгән һәрбер «килмешәк» үзе хуҗа була башлады. Шундый сүзне әйткәнгә гафу итегез, чөнки үзләрендә бер нәрсә эшли алмаган, бер нәрсәгә ирешмәгән кеше монда килеп фәрештәгә әйләнә. Ул дини оешма төзи дә, бездәге мөселманнар белән идарә итәргә, үзенең амбицияләрен күрсәтергә тотына. Ул дин юлындагы безнең имамнар белән элемтәгә кереп, мөфтигә үз фикерләрен үткәрә. Аның кулы белән үз идеологиясен булдыра. Менә шул хәл безне бик көендерә. Өченче зур көенечебез — кадрлар хәзерләү мәсьәләсе. Без, иншаллаһ, ата-бабаларыбыз кабул итеп алган, безгә килеп җиткән хак, пакь, саф динне дәвам иттерәбез. Соңгы вакытларда чит илләрдәге төрле уку йортларына әле аңы утырмаган, фикере ныгымаган яшьләрне алып китәләр. 14-15 яшьлек балаларны монда да төрле курсларда, лагерьларда укыталар. Шундый юллар белән үзләренең идеологиясен үткәрәләр. Без 4-5 елдан үзебездә яңа буынны, «яңа» фикерле, «яңа» дигәндә алдынгы карашлы, яхшы фикерле түгел, ә, киресенчә, искергән карашлы кешеләрне каршы алачакбыз. Алар монда кайтып низаг куптаручы, мәчетләребезне бүлгәләүчеләр, ата-бабаларыбыз фикеренә ревизия ясап, динне таркатучылар булачак. Кыскасы, фетнәчеләр кайтачак. Безне иң борчыган нәрсә бу. Чөнки безнең халык ышанучан, самими, садә һәм гарәп илләреннән килгән ак киемле, кара сакаллы һәр кешене фәрештәгә тиңли. Әгәр дә инде Коръән укып, гарәпчә дә сөйләшсә, бөтенләй дә пәйгамбәр дип кабул итә. Әмма гарәпчә сөйләгән һәрбер кеше фәрештә була алмый. Шуңа күрә иң әүвәле үз галимнәребез — Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдин, Муса Биги Ярулла, Галимҗан Баруди шикелле хәзрәтләребез, Каюм Насыйри, Әхмәдһади Максуди кебек мәгърифәт нуры таратучыларыбыз язып калдырган китапларны туплыйсыбыз, җыеп өйрәнәсебез, халкыбызга җиткерәсебез бар.

Бездә үткән гасыр ахырында, бу гасыр башында булган исламча яңа караш, тәрәккый фикерләү гарәпләрдә әле бик соң — бу дәвернең 60-70 нче елларында гына формалаша башлаган. Аларның әле бик күп төбәкләрендә бездәге XIX гасыр ахыры, XX гасыр башы фикере белән яшиләр. Ә шунда укып кайта торган кадрларыбызны исә узган гасырдагы кебек фикерле итеп әзерлиләр. Алар безне шуңа кайтарырга тиеш була. Шуның өчен дә Русиядәге Ислам оешмаларында эшләүче җитәкчеләрнең беренче бурычы — илебездә яшәүче мөселманнарга хезмәт итүчеләрне үзебезнең җирлектә әзерләү. Моның өчен безнең дин, фән галимнәребез, тарихчыларыбыз бар. Ә инде дин, икътисад мәсьәләсенә килгән вакытта, без гарәп илләреннән, мөселман дәүләтләреннән укытучыларны үзебез сайлап алып, үзебез чакырырга тиеш. Монда килгәннең соңында аларның безнең күзәтү астында укытуы зарур. Алар бүгенге көндә Русиянең үзенчәлекле ил икәнен, хәзерләнә торган кадрларның кемгә хезмәт итәчәкләрен белеп торырга тиеш. Читтә укып кайтучы балаларыбыз үз халкыбызга, мөселманнарга хезмәт итәчәкләр бит. Мөселманнарыбыз гарәп, ислам илләрендә яшәмиләр, ә марилар, удмуртлар, чувашлар, шул ук урыслар, башка диндәгеләр белән бергә гомер кичерәләр. Алар шул җирлектә яши дә, үз-үзләрен тота да, ихтирамлы да, тигез хокуклы да була белергә тиеш.

Сез кулыгызга корал алырга, мөселман дәүләте төземәгән җитәкчеләрегез белән көрәшергә тиеш, дигән өндәүләргә колак салсак, без бүгенгә кадәр ирешкәннәребезне, башка диндәге халыкны юк итәргә тиеш булабыз. Безгә исә кан, сугыш кирәкми. Тирән фикерле, һәрнәрсәне яхшы аңлап, җайлап, уйлап, киңәшеп яши торган булган безнең бабаларыбыз. Шул традицияне дәвам итеп кенә без уңышка, тыныч тормышка ирешеп, чын мөселман булып яши алырбыз.

**— Равил хәзрәт, көенечләребезнең берсе әйтелми калды шикелле. Бабаларыбыз, аталарыбыз рухына, сөякләренә үзләре үлгәннән соң да тынгы юк. Туганнар каберлекләрендә, изге урыннарда төтен чыгарып, пумала селкеп, су сибеп йөриләр. Әй, күңел рәнҗи дә шуңа, мәрхүм Мөхәммәт абый Мәһдиев тә бик борчылып язган иде ул хакта...**

— Минем бабам теге заманнарда сөргенгә озатылган, әнием 9 яшькә кадәр ана телен белмәгән. Чөнки бабам алтын юуда эшләгән. Әни Красноярск якларында тайгада урыслар арасында үскән. 9 яшендә генә туган ягына кайткан. 1-2 елдан сугыш башланган. Бабам — әниемнең әтисе Исмәгыйль Сталинградны саклаганда һәлак була. Туганнар каберлегендә ята. Ул каберлекләр барыбызга да — урыска да, татарга да бик якын. Ләкин монда яткан мөселманнарны христиан йоласы буенча чукындырып, су сибеп, төтен җибәреп йөрүләр һич тә дөрес түгел. Безнең моңа ризалыгыбыз юк. Шулай ук Русия хөкүмәте бирә торган орден-медальләрдәге сурәтләр, Җиңүнең 50 еллыгы уңаеннан ветеран-мөселманнарның күкрәкләренә тәре ясалган медальләрне тагу да һич килешми. Алар, билгеле, символика. Шулай булса да, пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам Ислам динен куәтләндергән чагында үзләре ясап куйган сыннарга, потларга, тәреләргә табынуны катгый тыйган. Бүген инде шул ширек сыйфатларны күрмәмешкә салышсак, пәйгамбәребез өйрәткәннәргә хилафлык китерү булыр. Бу турыда Русия мөселманнары үзләренең катгый сүзләрен әйтергә тиеш. Шовинистик идеология алып барган Русия империясе элек тә тәреләрен таратган, таккан, ләкин хәзер чоры башка. Үз хокукларыбызны бары тик үзебез генә яклый алабыз.

**— Сезнең бу турыда Алексей II белән сөйләшкәнегез юкмы?**

Урыс православие чиркәвенең безгә карашы бик сәер. Алар үзләренчә, сезнең хис-тойгы, кичерешләрегезне, динегезне, вөҗдан иреггезне кимсетәсебез килми, сез үзегезнекен эшләгез, без үзебезнекен эшлибез, диләр. Урыс православие диненең хәле дә шәптән түгел. Рухи аталары, язучы Алексей Солженицин: «XXI гасыр — мөселманнарныкы», дип әйтте әйтүен. Дөрес, бу сүзләр аларны куркыта да, кисәтә дә..

**— Равил хәзрәт, без бер гирә кешеләре идек, ләкин сез алдан күрүчән, акыллырак булып чыктыгыз. Казанда, телевидениедәге дипломыгызга лаек эшегезне калдырдыгыз да, бик күпләрне гаҗәпләндереп, Бохарага дини уку йортына китеп бардыгыз. Ислам Сезнең өчен нәрсә ул?**

— Ислам динен бары тик көнкүреш дине, гореф-гадәт дине дип кенә кабул итәргә кирәкми. Безнең бик күпләребез, бигрәк тә мәчеткә йөрүчеләребез, Ислам дине ул — тәһарәт алып, намаз укып, сәдака биреп, ураза тотып, Коръән мәҗлесләре уздырып, бәлеш ашап йөри торган дин, дип кенә уйлыйлар. Ислам дине — тирән мәгънәле дин һәм аның фикере XIII-XIY гасырларда бөтен дөньяның алга китешенә этәргеч булган. Шуңа ул тәрәккый дин буларак кабул ителгән. Юкка гына бөтендөнья күләмендә «Исламның дөнья мәдәниятенә керткән өлеше» дигән конференцияләр үткәрелми. Ислам дине ул — бөтен дөньяга цивилизация биргән дин. Ул төгәл фәннәрне — математика, геометрия, астрономия, астрология, медицина һәм башка бик күп, дәрәҗәге, барлык фәннәрне дә үстерә-күтәрә, үз эченә ала. Димәк, Ислам дине фәннәрне үстерү, ачышлар ясау өчен дә кирәк. Ул әдәп-әхлакның сафлыгына, мәдәниятнең үсешенә, җәмгыятьнең гаделлек белән яшәвенә, тормышның нигезе дөрес булуга ярдәм итә. Ә инде адәм баласының гыйбадәтне, тәртипне саклавы, сафлыкны, намуслылыкны үзендә булдыруы, Аллаһы Тәгалә каршында үзен тәкъва итеп күрсәтүе, җәннәткә керергә омтылышы — аның шәхси эше. Әмма Ислам диненең җәмгыять өчен мөһим ягы бар. Аның иҗтимагый әһәмияте искиткеч зур. Ул — дөньяви дин, дөньяга бик зур ачышлар, үсеш биргән дин. Менә шуның өчен дә ул безгә кадерле, газиз, изге. Ислам дине белән без бүгенге көндә дөньяны, үз-үзебезне, милләтебезне, телебезне саклап калырга тиеш.

**— Татарстанда ике теллелек турында закон кабул ителде. Моңа кадәр безнең бабайлар вәгазьләрне татарча гына сөйләгәннәр. Ә хәзер урысча да вәгазьләр ишетәсең. Шулай сөйләүчеләр, мәчеткә урыслар да, яһүдләр дә килә, дип аңлатып маташалар. Әмма Татарстанда, Казанда Ислам дине белән кызыксынып мәчеткә килгән башка милләт кешесе ник татарча белмәскә тиеш? Бездә бит җитәкче булып эшләүче урыслар да татарча өйрәнә башлады. Ә безнең мәчеттәге муллаларыбыз урысча вәгазь сөйләргә тотынмакчы.**

— Әлбәттә, тел һәм дин тыгыз бәйләнгән, аларны аерып карарга мөмкин түгел. Әгәр дә без үзебезнең телне саклап кала алмасак, ул вакытта динебез дә, милли мәдәниятебез дә бетәчәк. Татар теле һәм Ислам дине бер-берсеннән аерылгысыз булган вакытта гына тел, тарих, гореф-гадәтләребез саклапырга мөмкин. Русиянең мәркәзе урыс шәһәре булгач, безнең мәчеткә урыс телле халык, шулай ук Кавказ якларыннан килгәннәр дә гыйбадәтләребездә катнаша. Вәгазьләребезне тыңлый. Алар тарафыннан да, вәгазьләрне безгә дә аңлатыгыз инде, дигән тәкъдимнәр күп була. Әлбәттә, мәчетләребез бабаларыбызның төрки телле халыкларның гыйбадәт кыла торган урыны гына булмаган. Аларның тарихи, мәдәни, милли, дини үзәге ул. Мәскәү шәһәрендә безнең мәчетләребезгә милләттәшләребез татарча сөйләгәнне тыңлар өчен дә киләләр. Татар телен өйрәтә торган мәктәпләр Мәскәүдә юк. Шуңа күрә мәчеттәге дин курсларында булдыра алганча татарча да өйрәтергә тырышабыз. Тарих, әдәбият, милләт турында сөйлибез. Шулай булгач, Русиянең башкаласы Мәскәү мәчетләрендә вәгазьләребезне урысча сөйләргә җыенмыйбыз. Һич югында мәчеттә татар халкы икенче сортлы булмасын. Әгәр дә мәчетләребездә урысча вәгазь сөйли башласак, телне белмәгән кешеләребез, муллаларыбыз да урысча сөйли, нәрсәгә безгә татар теле, диячәк. Бүгенге көндә без авыз тутырып, рәхәтләнеп: «Йә, Раббым, әй, Ходаем, бер Аллам, кичер», дип Аллаһыга ялварабыз. Бу сүзләрне урысча: «О, боже, господи, помилуй», дип әйтергә минем телем әйләнми. Бер Ходай үзе сакласын.

**Әңгәмәне Фәния ХУҖАХМӘТ оештырды.**

Заһид Мәхмүди

# Яңа орлык

(хыялый хикәя)

Һәр тарафта йолдызлар, йолдызлар, йолдызлар. Ниндиләре генә юк арада! Сарысы, кызылы, зәңгәре... Барысы да, барысы да кемнендер затлы сандыгыннан коелып калган асылташлар кеби нур уйната, жемелди Адәм баласына җан өргән Бөек Зат анын да менә шушы йолдызлардай нурлы, матур һәм пакь булуын теләде. Әмма анын ышанычы акланмады: кешелек дөньясы көннән-көн бозылды, явызланды, ямьсезләнде һәм көннәрдән бер көнне Бөек Затнын түземлеге бетте Ул Айнын янгырлар дингезендә урнашкан Сират күпере тәҗрибәханәсе башлыгына соңгы фәрманын җибәрде

— Җирдәге чүп өемен чистартырга, яңа орлык чәчәргә!

Бу фәрманнан йолдызлар да калтырап куйды Әмма ул тормышка ашырыла башлаганчы, Җирдә әле тагын берничә ел узып китте. Сәясәтчеләр гадәттәгечә яңа ачышлар ясау, хәрбиләр бер-берсен үтерү, эшлекле даирәләр нефть һәм мазут белән диңгез-океаннарны пычрату, ирләр — хатын-кызлар турында, хатын-кызлар ирләр турында гайбәт сату, яшьләр исә гаилә кору һәм таркату белән шөгыльләнделәр.

Ахыр заман 2016 елның 14 июлендә килде Шул көннән адәм затлары шәһәрләре һәм авыллары белән кырыла башлады. Ике сәгать эчендә эчке әгъзаларны тарката торган коточкыч вирусның табигатен ачыклау һәм аңа каршы көрәш чараларын уйлап табу өчен бихисап акча түгелсә дә, галимнәр сизелерлек уңышка ирешә алмадылар. Әйе, бу чын кыямәт көне иде. Күктә изге китапларда сурәтләнгән тимер кошлар очмаса да, каберләреннән мәетләр тормаса да, тереләр үлгәннәрдән көнләшә торган хәтәр заман килде Җиргә. Бөтен дөнья мәетләр белән тулды. Аларны күмеп бетерергә һичбер мөмкинлек булмаганлыктан, һәр тарафта чыдап булгысыз начар ис таралды. Адәм затлары кешелек дөньясын алып китәргә дип килгән серле вирустан гына түгел, чума, холера, тиф кебек авырулардан да кырыла башлады.

Чүп өемен чистарту җиде Көн һәм җиде Төн дәвам итте. Сират күпере кабул иткән рухларның кайсылары таркату, кайсылары камилләштерү бүлегенә агылды. Таркату бүлегендәге җаннар хасил иткән кара болыт куерганнан-куера барып Орион йолдызлыгындагы Кара Куышка өрелде, камилләштерелергә тиешлеләре исә җиденче үлчәнештәге тәҗрибәханәләргә озатылды.

Сигезенче көнне өлкән оператор Таң Җирдән кабул ителгән рухлар турында мәгълүмат бирер өчен йөзенче катка очты. Тәҗрибәханә башлыгы Кан аны инде күптән түземсезлек белән көтә иде. Әллә дулкынланудан, әллә инде берничә тәүлек юньләп ял итмәүдән, өлкән операторның сары болыт рәвешендәге энергетик күлмәге җиңелчә генә калтырап ала иде.

Кан — әфлисун төсендәге һәм Таң кебек үк үтә күренмәле түрә — бик кәефсез иде Кәефе булмаганда анын энергетик күлмәге тоныклана, шәлперәеп төшә.

— Бик озак көттерәсең, — диде ул, канәгатьсезлек белдереп, — сөйлә, ничек анда хәлләр?

Әлеге фикри тавыш дулкыны Таңның аңына көч-хәл белән генә барып иреште. «Шеф кәефсез, — дип уйлады Таң. — Димәк, нидер булган» — Анын уе ялгыш кына фикри дулкында уйнап алды. Тагын шул тасабилану галәмәте инде Хәер, зыян юк, начар нәрсә уйламады ич

— Син бик дөрес уйлыйсың, — Канның фикри элемтә дулкыны операторның миенә хәнҗәр кебек килеп кадалды.

— Баш, — дип ыңгырашты Таң, чайкалып. Ләкин егылмады. Чөнки түрә, шундук исенә килеп, ультра фикри дулкыннан чыгып өлгерде. Азга гына соңга калган булса да, Таңның энергетик күлмәге ертылачак һәм таркалачак иде. Күрәсең, бик тә күңелсез бер хәл булган. Ул да дулкынлана. Юкса, гадәти фикри дулкын белән ультра фикри дулкынны бутамас иде.

— Гафу ит, — диде түрә, гаепле тавыш белән.

— Ярый, зыян юк, — Таң, һичбер нәрсә булмагандай, Җирдән кабул ителгән җаннар турында мәгълүмат бирә башлады. — Бүген җәмгысе җиде миллион йөз дә сиксән ике рух таркатылды.

— Ә йөз дә сиксән өченчесе кайда? — дип бүлдерде аны түрә.

— Без бөтен Җирне капшап чыктык. Анда башка бер генә орлык та калмады. Бәлки компьютер ялгышкандыр.

— Сез үзегез ялгышасыз, дустым. Эзләгез. Җирдә сиксән өченче җан да булырга тиеш.

Таң янә Сират күперенең рухларны кабул итү бүлегенә төшеп китте. «Кайда булырга мөмкин бу соңгы орлык? — дип уйлады ул. — Башлык дөрес әйтә, сиксән өченчесе дә булырга тиеш. Ә мин, юләр, хәтергә ышанып...»

Ул килеп кергәндә, шәмәхә болыт рәвешендәге Моң нидер бытырдый-бытырдый кабул итү көпшәсен күзәтә иде.

— Җирдә тагын бер рух бар, — диде Таң.

Бу хәбәр Моңны тамчы да гаҗәпләндермәде.

— Беләм. Әнә ул, капка янындарак күренә.

Таңның сары энергетик күлмәге яктырып китте.

— Кая, кая?

Моң капкага көчле яктылык җибәреп, Таңга үз урынын бирде.

— Кызыл нокталы күрәсеңме?

— Күрәм.

— Бу син әйткән адәм рухы инде.

— Җирдә мондый төстәге лептон дулкын юк ич. Өстәвенә, ул хәрәкәтләнми дә бугай

— Бугай гына шул Гади генә орлык түгел ул Капкага кадәр очып килде Хәзер менә шуышып килә

Син хаклы, Моң Ул инде капканың бу ягында, — диде Таң, һаман да капканы күзәтеп. — Без адәм рухларын таркаткан, камилләштергән арада берәү Бөек Сергә ачкыч тапкан.

— А, бу лептодулкын кыры бик зур галим булса кирәк, — Моңның фикри тавышы чак кына дерелдәп куйды. Аннары ул тенту бүлеге компьютеры экранында пәйда булган мәгълүматларны укый башлады. — У-у, атаклы парапсихолог, 2003 елда парапсихология өлкәсендәге хезмәтләре өчен Нобель премиясе белән бүләкләнгән. Әхлак дәрәҗәсе нульдә тора. Интеллект дәрәҗәсе ике йөз дә унҗиде процент. Башлы орлык, каһәр. Бездән чак кына аңгырарак.

Гыйсъянчы орлык, амеба кебек сузыла-жыерыла, максатына табан шуышуын дәвам итте. Ул әле туктый, әле, шымчы кебек, тирә-юньгә карана-карана, бик сак кына кыланып шуыша.

Җирдәге вакыт исәбе буенча дүрт-биш сәгать вакыт узып китте. Шактый киеренке һәм газаплы булды ул.

Ниһаять, кызыл орлык һавага күтәрелде дә, зур тизлек белән алга ыргылды.

Таң шундук терсәге белән Моңнын янтыгына төртте:

— Саклык чылбырын кабыз!

Ике үтә күренмәле затның энергетик күлмәкләре бер-берсенә орынуга, ярым караңгы лаборатория эчендә салават күпередәй җиде төрле төс балкып алды.

Көчле магнит кыры хасил иткән саклык чылбыры гыйсъянчы орлыкны суырып алып таркату бүлегенә төкерергә тиеш иде. Ләкин бу барып чыкмады. Шулай да, көчле каршылык тудырып, орлыкның шактый хәлен алды. Тизлеген дә бик күпкә киметергә мәҗбүр итте.

— Анын энергетик күлмәге гадәти рухларныкына караганда ун тапкыр тыгызрак, — дип мыгырдады Таң. — Әгәр ул баштагы тизлеген саклап кала алган булса, инерция көче белән таркату блогы аша да уза алыр иде. Күңелем сизә, бу югары интеллектлы матдә безгә әле бик күңелсез сюрпризлар ясаячак.

Моң, анын сүзләренә куәт өстәп, башын чайкап куйды.

— Кичекмәстән шеф белән элемтәгә керергә кирәк, Таң.

— Нәрсә булды тагын? Мин сезне тыңлыйм! — тәҗрибәханә башлыгының фикри тавышы икән Әллә тыңлап торган, әллә...

Таңны тыңлап бетергәч, шеф гасабилы тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Бу мөмкин түгел! Сезнең баш шәрифләрегез какшаган!

— Бәлки какшагандыр да, әмма бу орлыкның энергетик күлмәге башкаларныкына караганда ун тапкырга тыгызрак.

— Ун тапкырга? Ярый, мин Үзәк белән элемтәгә керәм Карагыз аны, әгәр ялгышкан булсагыз...

Фикри элемтә әнә шул сүздә тәгәлләнде Ә гыйсъянчы орлык инде таркату бүлеге янына төшеп утырган

— Әгәр бу кызыл хәшәрәт таркату бүлеге аша узса, безне гафу итмәячәкләр, - диде Моң, еларга җитешеп. — Ул Альфа йолдызлыгында житештерелгән саф орлыклар блогына үтеп кереп, аларны да бозарга мөмкин.

Таң ачу белән ысылдап куйды:

— Анын төп максаты да шул инде.

Искиткеч киеренке һәм хәвефле минутлар иде бу. Орлык, аларның түземлеген сынарга теләгәндәй, кеткелдәп көләргә, төрле мыскыллы ишарәләр ясарга керешге. Ямьсез һәм нәфрәтле иде анын көлүе.

Менә ул, корбанына ташланырга әзерләнгән җанвар кебек, жыерылып куйды. Сикерергә жыена мы? Әллә һавалануы гынамы? Юк, ул шаярырга жыенмый... Сикерде... Һәм бик шәп сикерде Ул инде таркату бүлегенен икенче ягында. Саф орлыклар янына юл ачык. Тик нигә ул анда элгерга ашыкмый? Һәй, Җиргә җибәрелә торган яңа орлыкларны бозарга дип килмәгән ул Алайса, нигә килгән? Бәлки аны бу имансызлыкка гап-гади кызыксыну хисе этәргәндер? Утыра, үз өендә кебек утыра, кабих... Тагын күңел ача таркату бүлегенен әле бер, әле икенче ягына сикерә. Чикерткә кебек сикерә. Кайчан туяр?

— Ул бездән көлә, — диде Таң, башын иеп.

Бизгәк тоткан җан ияседәй калтырый башлаган Моң, кара коелып, читкәрәк барып басты. Ул үзенен энергетик күлмәген ертырга әзерләнә иде. Чыдавы авыр иде шул мондый хурлыкка. Әгәр Таң ялгыш кына артына борылып карамаган булса, Моң басып торган урында соры төтен болыты гына калачак иде.

— Бүтән мондый юләрлекне эшләмә! — диде Таң. — Бу орлыкның энергетик күлмәге калын булганга без гаепле түгел.

Өлкән операторның сүзләре дөрескә чыкты. Орлык тагын бер сюрприз ясады: таркату бүлеге аша сикереп туйгач, искәрмәстән Җиргә юл тотты.

Ул капкадан чыгып китүгә, Таң җиде тотка сурәте төшерелгән төймәгә басты. Хәзер инде гыйсъянчы орлык капкадан керә алмаячак.

— Котылдык, — диде Моң, авызын ерып.

Таң әлеге четерекле хәлдән шулай җиңел котылуларына бик нык сөенсә дә, шефка хәбәр салырга ашыкмады. Чөнки саф орлыклар блогындагы ак болыт акрын гына карала кебек тоелды аңа. «Әллә күзгә күренәме? — дип уйлады ул. — Юк, күзгә генә күренми, Моң да сизгән бу хәлне».

— Бусы нәрсә тагын? — диде ул, күзләрен түгәрәкләндереп. — Алар арасында кара орлыклар юк иде ич. Каралалар, валлаһидыр, каралалар!

Таң, кабалана-кабалана, Интеллект экранын кабызды.

— Саф орлыклар блогындагы болыт карала, — диде ул. — Сәбәбе нидә?

Экранда иң элек катлаулы математик формулалар, аннары гарәп хәрефләре белән язылган сәтырлар пәйда булды:

«Төннең нинди булуын белер өчен көн кирәк. Саф орлыклар арасында гыйбрәт өчен бозык орлыклар булмау сәбәпле, алар барысы да берьюлы бозылалар».

— Алай икән, — диде Таң. — Безнең бу хәлне булдырмас өчен күпме вакытыбыз бар?

Компьютерның жавабы бик кыска булды:

«Вакыт инде бетеп бара».

— Нишлибез? — диде Моң.

Таң кычкырып көлеп җибәрде. Кече операторга бу ошамады:

— Таптың көләрлек вакыт.

— Безне Җиргә кайтып киткән орлык коткарачак. Җибәр орлыкларны иреккә. Сип барысын да Җиргә!

— Шәп фикер Мин сиңа сокланам, Таң Димәк, бозыклык та кирәк, ә?

— Аз гына, бик-ик аз гына, дустым.

# Атналык манзара TV

## Дүшәмбе

### 11 СЕНТЯБРЬ

#### «ТАТАРСТАН»

7.00 8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.35 Мультфильмнар 18.45 Балалар өчен «Тамчы» 19.00 «Татарстан» 19.30 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 19.40 «Түгәрәк өстәл» Реформалар программасы ул ниндн булырга тиеш? 20.20 «Әлли-бәлли-бәү» 20.30 Яшьләр өчен музыкаль күңел ачу программасы. «Гашыйклар телеканалы» 21.00 «Яшел камин янында» Татарстан Республикасы дәүләт музее директоры Геннадий Муханов. 22.00 «Моңнар кайта ерактан» «Сорнай» ансамбле чыгышы 22.20 «Болл клубы». 22.50 Тапшырулар программасы.

#### «ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Ушастик и его друзья» 7.30 «Кино-Мено». 8.00, 10.55 — «Юл патруле» Атналык йомгак. 8.10, 11.35 — «Даруханә» 8.20 «Сул аяктан!» (MTV). 9.20, 13.35 — «90х60х90». 9.35 Мультсериал: «Еноты» 10.00 Балалар өчен сериал. «Неоновый всадник». 11.10 Спорт атнасы. 11.50 «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 12.10 Нәфис фильм: «Быть влюбленным». 13.50 «Валюта бәясе» 14.00 CNN. Бизнес яңалыклары. 14.30 Атна һалакәтләре. 15.05 Сериал: «Из глубины веков» «Знаки и символы». 16.05 Документаль фильм: «Москва, Кремль — XX век» 17.05 «Джексонвиллда джаз». 18.05 «Кәмитчеләр планетасы» 18.55 «21 нче параграф». 19.20 «Эфирда — музыка». 19.30 «Видеомода». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.20, 23.05 — «Шәһәр» информацион программасы. 20.45 «Бөтенләй башкалар». 21.15 Телеэкспресс. 21.35. «Спутник-Казан» акционерлык җәмгыяте тәкъдим итә:«Кайда йөрәгең — шунда хәзинәң». 22.45. Нәфис фильм премьерасы: «Прах и кровь». 2 нче серия. (Франция-Италия-Германия) 22.40 «Криминаль хроника тележурналы». 23.30 Нәфис фильм: «Тайна вагона № 13».

#### 1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 1.05 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Могҗизалар кыры». 11.00 «Кеше һәм закон». 11.25 Мультфильм: «Корабль пустыни». 11.35 «Ел буе — яшелчә бакчасы». 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Н.Еременко һәм Н.Бондарчук «Красное и черное» телесериалында. 14.10 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның жиде көне». 16.00 Мультсериал: «Отверженные». 16.25 «Йолдызлар сәгате». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 Яшьләр сериалы: «Элен и ребята». 17.30 «Тет-а-тет». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.15 Хоккей. МХЛ чемпионаты. ЦСКА — «Крылья Советов». Тәнәфестә — «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 Телесериал: «Двенадцать стульев». 23.20 «Юрамалар». 23.40 «Футбол күзәтүе» 0.10 «Матбугат клубы».

#### «РОССИЯ»

7.30 Эшлекле кешеләр вакыты. 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 Нәфис фильм: «Опиум». 10.05 «Сәяси олимпта». 11.05 Милиция хроникасы. 11.15 «Телегазета». 11.20 Мульти-пульти. 11.50 Сергей Есенин. «Соңгы шагыйрь». 12.05 Музыкаль экспромт 12.15, 17.20 «Яңа гармак». 12.30, 14.20 - «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 Мульти-пульти. 17.50 «Алыргамы — алмаскамы». 18.00 «Лад» галереясы. С.Цыганова. 18.30 «Котчкару-911». 19.25 «Сабый авызыннан». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 «Наркович В.ның сере». 21.40 Репортер. 22.00 «Бизәүсез» 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел». 23.40 Киношок-95. 0.00 Нәфис фильм «Берлин. Александр Платц»

#### «САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә» 8.15 «Киңәшче» 8.45 Балалар өчен 9.20 «Гүзәллек». 10.15 «Төш юрау» 10.40 «Такмаклар» 11.15 «Коллекционерлар». 11.45 «Тәҗрибә». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00, 15.30 «ТВ мәгълүматлары» 13.20 «Антре. Цирк программасы». 13.30, 15.40 Музыка мизгеле. 14.00 «Ашыгыч ярдәм» 14.30 Телефильм. «Мануэла» 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр» 15.45 Телефильм: «Евфроний» 16.15 Музыкаль фильм: «Портрет мадемуазель Таржи». 17.25 «Алтын софит» фестивале 18.10 Мультфильм.
22.55 «Спорт, спорт, спорт ..» 23.10 Парадлар парады Музыкаль шоу

## Сишәмбе

### 12 СЕНТЯБРЬ

#### «ТАТАРСТАН»

7.00 8.00 «Чулпан» информацион программасы 18.10 «Йолдыз-йолдызчык» Эльвира Зарипова 18.30 «Автосалон-95» «КАМАЗ» акционерлык җәмгыяте базарга чыгу юлында» 19.00 «Татарстан» 19.30 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 19.35 «Хосусыйлаштыру сораулар һәм җаваплар» 20.05 «Әлли-бәлли-бәү» 20.15 «Пульс» Медицина программасы 20.30 Күп серияле нәфис фильм премьерасы «Гарзан» 11 нче һәм 12 нче серияләр (Мексика - Канада Франция) 21.00 «Сәхнә» Чаллы театры Казанда. 22.05 Тапшырулар программасы.

#### «ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Синичкин календарь» 1 нче һәм 2 нче кисәкләр 7.30, 20.20, 23.35 — «Шәһәр» информацион программасы 7.55 Телеэкспресс (11 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.20 «Сул аяктан!» (MTV). 9.15, 13.35 — «90х60х90» 9.30 Мультсериал: «Еноты» 9.55 Балалар сериалы «Неоновый всадник» 11.00 «Юл патруле» 11.15 Атналык фаразлар 11.40 «Даруханә». 11.55, 18.15 — «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 12.15 Нәфис фильм: «И это все о нем...» 1 нче серия 13.50 «Валюта бәясе» 14.00 CNN Бизнес яңалыклары 14.30 «Минем кино» Александр Лазарев 15.00 «Музыка һәм матбугат» «Каләм осталары» «Ва-банк», «Текиладжаз», «Вежливый отказ» төркемнәре. 15.55 «Алтын ачкыч — 94» премиясе белән бүләкләү тантанасы 18.40 Телесериал: «Против течения» 19.30 Хокук каналы 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.45 «Коммерция әйләнмәсе» 21.05 Спорт-ревю 21.15 Телеэкспресс. 21.35 «Ялта» Ялтада. 21.55 Русия киносы көне. Нәфис фильм: «Паук» 0.00 «TAP RECORDS» коллекциясеннән. «Пинк Флойд» төркеме

#### 1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә» 9.00, 12.00, 15.00, 1.00 — «Яңалыклар» 9.20 Телесериал. «Тропиканка» 10.10 Хоккей. МХЛ чемпионаты. ЦСКА — «Крылья Советов». 10.50 Хайваннар дөньясында. 11.25 Мультфильм: «Песня о летучих мышах». 11.35 Телеуен: «Мине аңла» 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телесериал: «Красное и черное» 14.10 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Футбол күзәтүе» 16.00 «Кара, тыңла» 16.20 «Кактус һәм К» 16.30 «Кварьете — күңелле квампания». 16.40 «Тылсымлы дөнья яки Синема» 17.00 Кыска яңалыклар. 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.30 «Джем» 18.00, 21.00 — «Вакыт» 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны» 20.00 «Тема». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 «Беренче куллардан» 22.05 Футбол. УЕФА кубогына. 1/32 финал. «Спартак-Алания» (Владикавказ) — «Ливерпуль» (Англия). 23.55 «Юрамалар». 0.15 Волейбол. Европа чемпионаты. Ир-атлар. Болгария һәм Русия җыелма командалары. 1.20 Телесериал: «Улицы Сан-Франциско» 2.10 «Кумирлар, кумирлар...» Л.Долина.

#### «РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика» 8.50 «Кирәк... кирәк...» 10.55 «Телегазета». 11.05 «Милиция хроникасы» 11.15 «Сәнгать мәйданы Дирижер В.Ашкенази. 11.45 Клип-антракт 11.50, 17.40 Мультсериал: «Камень сновидений» 12.15, 16.20 «Яңа гармак» 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия» 16.05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.50 «Ай тотучы» 17.20 «Көн дә бәйрәм» 17.30 Мульти-пульти. 18.05 «Беркем дә онытылмаган» 18.10 «Сәүдә йорты» 18.25 Әдәби-публицистик цикл премьерасы: «Россия. Мәхәббәттә аңлашу». 18.55 Шахмат буенча дөнья беренчелегендә Г.Каспаров — А.Ананд 19.10 «L» клубы. 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 Нәфис фильм «Последние дни Ше Ну» 22.25 «Мәхәббәт астрологиясе» И.Понаровская 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел» 23.40 Нәфис фильм «Пой песню, поэт...»

#### «САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә» 8.15 «Әдәплелек» 8.45 «Оборона» 10.00 «Төш юрау» 10.45 «Кумирлар» 11.15 «Аукцион» 11.45 Тәҗрибә 12.10 «Джаз» 12.40 «Кунак» 13.00, 15.30, 22.40 «ТВ мәгълүматлары» 13.20 Мультфильмнар. 13.50, 15.40, 17.40 «Музыка мизгеле» 14.00 «Ашыгыч ярдәм» 14.30 Телефильм: «Мануэла» 15.15 «Бакчачыларга киңәшләр» 15.45 Нәфис фильм. «Наш американский Боря» 17.10 Мультфильмнар 17.50 «Бөтен Россия буйлап» 22.55 «Спорт, спорт, спорт ..» 23.10 А.Невскийның тууына 775 ел тулуга карата

## Чәршәмбе

### 13 СЕНТЯБРЬ

#### «ТАТАРСТАН»

7.00 8.00 «Чулпан» информацион программасы 18.10 Балаларга фильм: «Өченче планетаның сере» (татар телендә) 19.00 «Татарстан» 19.30 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 18.35 Документаль фильм: «Суверенитет: год пятый» 20.20 «Әлли-бәлли-бәү» 20.40 «Язучы фикере» Рабит Батулла 21.20 «Болл клубы» 21.50 Зөһрә Шәрифуллина җырлый 22.00 Тапшырулар программасы.

#### «ЭФИР»

6.50 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Синичкин календарь» 3 нче һәм 4 нче кисәкләр 7.30, 20.20, 0.05 — «Шәһәр» информацион программасы 7.55 Телеэкспресс (12 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.20 «Сул аяктан!» (MTV) 9.20, 13.35 — «90х60х90» 9.40 Мульсериал: «Еноты» 10.05 Балалар сериалы: «Неоновый всадник» 11.00, 19.00 — «Юл патруле» 11.15, 15.00 «Атна пизаглары» 11.40 «Даруханә» 11.55, 18.40 — «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 12.15 Нәфис фильм: «И это все о нем...» 2 нче серия. 13.50 «Валюта бәясе» 14.00 CNN Бизнес яңалыклары. 14.30 «Минем йолдыз» Светлана Немоляева 15.30 Е.Кавалерович фильмы премьерасы: «Узник Европы» (Польша). 17.40 Детектив сериал: «Филипп Марлоу — частный детектив» 19.10 Эфирда — музыка. 19.25 «Поза» 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.45 «Enter club» 21.15 Телеэкспресс. 21.35 Хатын-кызлар өчен яңа контрацептив препаратлар. 21.45 Стефани Пауэрс «Дочь Мистраля» кинобестселлерында. 1 нче серия. 0.25 «Пинк Флойд» төркеме концерты.

#### 1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә» 9.00, 12.00, 15.00, 2.10 — «Яңалыклар» 9.20 Телесериал: «Тропиканка» 10.10 «Тема» 10.55 Футбол. УЕФА кубогына. 11.35 Телеуен: «Мине аңла» 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телесериал: «Красное и черное» 14.10 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның жиде көне» 16.00 «Күңелле ноталар» 16.20 «Ник һәм нигә?» 16.50 «Фен-клуб». 17.00 «Шпаргалка» 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.30 «Тин-тоник» 18.00, 21.00 — «Вакыт» 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны» 20.00 «Без» В.Познерның авторлык программасы. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21.55 «Мәскәү-Кремль» 22.20 Футбол. Чемпионнар лигасы. «Блэкберн» (Англия) — «Спартак» (Мәскәү). 0.20 «Юрамалар». 0.40 Футбол. Чемпионнар лигасы. 8 матчка күзәтү 2.30 «Телемемуарлар»

#### «РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр» 8.30 «Йолдызлар сөйли» 8.35 «Ритмика» 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 «Төп мизгел» 9.05 «Пилигрим» 9.50 Телесериал: «Санта-Барбара» 10.40 «Крестьян мәсьәләсе» 11.05 «Милиция хроникасы» 11.15 «Телегазета». 11.20 Грета Гарбо турында. В.Вульфның авторлык программасы. 11.50, 17.20 Мультсериал: «Камень сновидений» 12.15, 16.30 «Яңа гармак» 12.20, 14.20 - «Эшлекле Россия» 16.05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.20 «Көн дә бәйрәм» 17.45 «Популяр булмаган тема» 18.00 Драма артистлары җырлый. 18.30 «Мин — әйдәп баручы» 18.55 Шахмат буенча дөнья беренчелегендә. 19.10 «Экспо-видео» 19.25 «Үз уены» 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара» 21.30 Күңел ачу программасы. «Шәһәрчек» 22.05 «Губернаторлар клубы» 22.45 «Криминаль хәбәрләр экраны» 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40 Киношок-95 0.00 Нәфис фильм «Берлин Александр Платц»

#### «САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә» 8.15 «Киңәшче» 8.45 Балалар өчен 9.20 «Гүзәллек» 10.15 «Төш юрау» 10.40 «Такмаклар» 11.15 «Аукцион». 11.45 «Тәҗрибә» 12.10 «Джаз» 12.40 «Кунак» 13.00, 15.30, 22.40 «ТВ мәгълүматлары» 13.20 Мультфильмнар 13.50, 15.40 «Музыка мизгеле» 14.00 «Ашыгыч ярдәм» 14.30 Телефильм «Мануэла» 15.15 Бакчачыларга киңәшләр 15.45 Нәфис фильм: «Я, бабушка, Илико и Илларион» 17.10 Музыкаль телефильм. «Гласом моим...»
22.05 Театраль бинокль 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 Россиянең халык артисты К.Лавровның тууына 70 ел тулуга карата

## Пәнҗешәмбе

### 14 СЕНТЯБРЬ

#### «ТАТАРСТАН»

7.00- 8.00 «Чулпан» информацион программасы 18.00 Мультфильмнар 18.30 «Ачыктан-ачык сөйләшү» Венерик авыруларга профилактика турында 18.50 «ГАИ мәгълүматлары» 19.00 «Татарстан» 19.30 «Хөкүмәт сәгате» 20.00 «Әлли-бәлли-бәү» 20.10 «Тынлыйм йөрәк гавышынны» Илгиз Сәхаутдинов җырлый 20.20 Экранда кинокомедия. Нәфис фильм: «Главарь мафии» 22.00 Тапшырулар программасы.

#### «ЭФИР»

6.55 «Зарядкага басыгыз!» 7.05 Мультфильм: «Спорт» 7.30, 20.20, 23.05 — «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (13 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.20 «Сул аяктан!» (MTV) 9.20, 13.35 «90х60х90» 9.40 Мультсериал: «Еноты» 10.05 Балалар өчен сериал: «Неоновый всадник» 11.00, 19.05 «Юл патруле» 11.15, 15.00 CNN «Стиль» 11.40 «Даруханә» 11.55, 18.45 «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 12.15 Нәфис фильм: «И это все о нем...» 3 нче серия 13.50 «Валюта бәясе» 14.00 CNN Бизнес яңалыклары. 14.30 «Чәй-клуб» Владимир Лукин һәм Юлий Ким Зиновий Гердта кунакта. 15.30 Ток-шоу «Мин үзем» «Яшь ханым эш эзли» 16.30 Нәфис фильм: «Первая девушка» 17.45 Мажаралы сериал: «Филипп Марлоу — частный детектив» 19.15 Эфирда — музыка 19.20 Видеогид. 19.40 «Заречье» банкы мәгълүмат бирә 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.45 «Коммерция әйләнмәсе» 21.05 «Казанские ведомости» нәрсә турында сөйләде» 21.15 «Телеэкспресс» 21.35 Нәфис фильм: «Дочь Мистраля» 2 нче серия. 23.30 Атна фильмы. Мишель Морган «Максим» комедиясендә. 1 нче серия.

#### 1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә» 9.00, 12.00, 15.00, 0.55 «Яңалыклар» 9.20 Телесериал: «Тропиканка» 10.10 Футбол. Чемпионнар лигасы. 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 12.20 Телесериал: «Красное и черное» 14.10 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның жиде көне» 16.00 Мультитроллия. 16.20 «Золушкада балда» 16.40 «Компьютер-холл» 17.00 Кыска яңалыклар. 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» 17.30 «16 яшькә кадәр һәм өлкәнрәкләр...» 18.00, 21.00 — «Вакыт» 18.20 Телесериал: «Тропиканка» 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать» 19.35 «Лотто-миллион» 20.00 Футбол. Чемпионнар лигасы. «Динамо» (Киев) — «Панатинаикос» (Греция). 20.50 «Тыныч йокы, нәниләр» 22.00 Нәфис фильм: «Подсматривающий» 23.50 «Юрамалар» 0.10 Волейбол. Европа чемпионаты. Ир-атлар. Россия һәм Италия җыелма командалары. 1.15 Телесериал: «Улицы Сан-Франциско» 2.05 Бенуа призы. Балет йолдызларының гала-концерты.

#### «РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр» 8.30 «Йолдызлар сөйли» 8.35 «Ритмика» 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 «Төп мизгел» 9.05 Документаль фильм: «Человек, который сломал радугу» 9.45 «Телегазета» 9.50 Телесериал: «Санта-Барбара» 10.40 «Крестьян мәсьәләсе» 11.05 «Милиция хроникасы» 11.15 «Халява партиясе» 11.35 «Музыкаль экспромт» 11.45, 17.20 Мультсериал. «Камень сновидений» (Бөекбритания). 12.10 «Беркем дә онытылмаган» 12.15 «Яңа гармак» 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия» 16.05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.20 «Көн дә бәйрәм» 16.30 «Төрле гөстәге призма» 17.45 «Бөтенрусия яшь язучыларының киңәшмәсен каршылап» «Исәнме, яшь буын...» 17.55 Футбол. Кубоклар иясе кубогына 1/16 финал. «Динамо» (Мәскәү) — «Арарат» (Ереван). 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 Телесериал «Санта-Барбара» 21.30 «Хроно» 22.05 «Армия-95» 22.00 «Клип-антракт» 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.45 «Криминаль хәбәрләр экраны» 23.55 Рок риваяте «Питер Хэммил Мәскәүдә»

#### «САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә» 8.15 «Әдәплелек» 8.45 «Оборона» 10.15 «Төш юрау» 11.15 «Аукцион» 11.45 «Тәҗрибә» 12.15 «Спартак» 12.40 «Кунак» 13.00, 15.30, 22.40 «ТВ мәгълүматлары» 13.20 «Театраль бинокль» 13.50, 15.40; 17.40 «Музыка мизгеле» 14.00 «Ашыгыч ярдәм» 14.30 Телесериал. «Мануэла» 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр» 15.45 Нәфис фильм: «Остров Серафимы» 17.00 Мультфильм. 17.10 «Балаларга җәнлекләр турында» 17.50 «Бөтен Россия буйлап»
22.00 «Санкт-Петербург телевидениесе» 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.20 Нәфис фильм «Веселенькая повестка» 23.55 «Наобум» И.Костолевский

# ҖОМГА

## 15 СЕНТЯБРЬ

### «ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.50 «Ералаш» киножурналы. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Видеоспорт». 19.45 Татарстан Дәүләт Советында. 20.15 «Әлли-балли-бәү». 20.45 «Ислам чакыруы». 20.35 «Җомга көн кич белән». Альманах. 21.35 Әнвәр Бакиров җырлары. 22.00 Тапшырулар программасы.

### «ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Спорт-2». 7.30, 20.20, 0.45 «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 «Телеэкспресс» (14 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.20 «Сул аяктан!». 9.20, 13.35 «90х60х60». 9.40 Мультсериал: «Еноты». 10.05 Балалар өчен сериал: «Неоновый всадник». 11.00 Юл патруле. 11.15 «Атнага бер тапкыр» юмористик программасы. 11.40 «Даруханә». 11.55, 18.15 «ПОСТ — музыка яңалыклары». 12.15 Нәфис фильм: «И это все о нем...» 4 нче серия. 13.50 «Валюта бәясе». 14.00 CNN. Бизнес яңалыклары. 14.30 «Нью-Йорк, Нью-Йорк». 15.00 Нәфис фильм: «3:15» (АКШ). 16.35 Рей Бредбери. «Склянка». 17.05 Сериал: «Филипп Марлоу — частный детектив». 18.35 Эфирда — музыка. 18.40 «Суперспорт». 19.00 Сериал премьерасы: «Корабль любви». 2 нче серия. 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 21.15 Телеэкспресс. 21.35 Сериал: «Сирены» (АКШ). 22.30 Нәфис фильм: «Дочь Мистраля». 3 нче серия. 1.05 Куркыныч фильм: «Реаниматор».

### 1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 2.10 Яңалыклар. 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Без». В.Познерның авторлык программасы. 10.50 «Сәяхәтчеләр клубы». 11.35 Телеуен: «Мине аңла». 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телесериал: «Красное и черное». 14.00 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 16.00 Балалар өчен телесериал: «Белый клык». 16.25 «Орфей йолдызлыгы». 16.40 «Яңа чынбарлык». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 «Рок-дәрес». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Кыргый кыр». 19.25 «Кеше һәм закон». 19.55 «Могҗизалар кыры». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 Телесериал: «Рейли — король шпионов» (Бөекбритания). 23.25 «Юрамалар». 23.45 «Караш». 0.40 Волейбол. Европа чемпионаты. Ир-атлар. Ярымфинал. 2.30 Телесериал: «Улицы Сан-Франциско». 3.20 «Кабаре — барлык йолдызлар».

### «РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...». 8.55 «Үтә яшерен». 9.45 Клип-антракт. 9.50 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 «Милиция хроникасы». 11.15 «Телегазета». 11.20 Документаль фильм: «Ахалтекинец». 11.30 «Сәүдә йорты». 11.45 «Шәп авыл». «Рус туе». 12.15 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Контерә». 16.50 «Ай тотучы». 17.20 Лена Радищевскаяның ачышлары. 17.35 Шахмат буенча дөнья чемпионатында. Г.Каспаров — В.Ананд. 17.50 Нәфис фильм: «Зорро». 18.45 «Оста». Кирилл Лавров. 19.25 Вертикаль. «Хөкүмәтнең эш көннәре». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 21.30 «Үз-үзенә режиссер». 22.05 «К-2» тәкъдим итә: «Александр Володин «Халык фрагы» программасында. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.45 Киношок-95.

### «САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 «Балалар өчен». 9.20 «Гүзәллек». 10.15 «Төш юрау». 10.40 «Кумирлар». 10.45 «Такмаклар». 11.15 «Коллекционерлар». 11.15 «Тәҗрибә». 12.10 Джаз. 12.40 «Кунак». 13.00, 15.30, 22.40 «ТВ мәгълүматлары». 13.20 Мультфильм. 13.50, 22.25 «Музыка мизгеле». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телесериал: «Мануэла». 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.45 Нәфис фильм: «Веселенькая поездка». 17.05 Документаль фильм: «Религия в ЮАР». 17.20 «ТВ мәгълүматлары. Европа калейдоскобы». 17.50 «Бәллүр ачкыч». Музыкаль клиплар фестивале. 18.10 «Антре». Цирк программасы. 18.30 «Буй-буй музыка». 22.05 Санкт-Петербург телевидениесе. 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 Нәфис фильм: «Джошуа».

# ШИМБӘ

## 16 СЕНТЯБРЬ

### «ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Мизгел». 20.00 «Әлли-бәлли-бәү». 20.10 К.Тимбикова. «Тын бакчада». Телевизион спектакль. 22.00 Композитор Ренат Еникеев әсәрләреннән концерт. 22.50 Тапшырулар программасы.

### «ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Межа». 7.30 «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (15 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.10 «Коммерция әйләнмәсе» (12 сентябрь көнендәге тапшыруны кабатлау). 8.30 «Спорт-ревю». 8.40 «Видеомода». 9.00 «Поза». 9.25 «Хокук каналы». 9.45 «700 нче клуб». «Җаваплар». 10.15 «Палитра» сериясеннән: «Лорен». 10.40 Мультфильм: «Двенадцать месяцев». 11.35 «Чаплиниада». «Чемпион». 12.00 Хәрби телевидение. 12.30 «Спорт атнасы». 13.00 Мультфильм: «Следствие ведут знатоки». 14.45 Нәфис фильм: «Кларенс» (АКШ). 16.20 Эфирда — музыка. 16.25 Телесериал: «Тропическая жара». 17.20 Телесериал: «Детективы на полставки». 18.15 «Яшерен йомыш». 18.40 «Йозак тишеге». 19.00 «Исәнмесез!». 21.00 «Мавыгулар дөньясы». 21.30 Сериал: «Сирены» (АКШ). 22.30 Мультфильмнар. 23.00 «Музыкага чикләр юк». 0.00 Куркыныч фильм: «Реаниматор-2». 1.35 В.Боровчик фильмы: «Искусство любить».

### 1 НЧЕ КАНАЛ

7.30 «Иртә». 8.45 «Пастырь сүзе». Митрополит Кирилл. 9.00, 15.00, 1.40 Яңалыклар. 9.20 «Лего-го». 9.50 Балаларга фильм: «Секреты моего лета». 10.15 Мультфильм. 10.25 «Иртәнге почта». 11.00 «Татлы». 11.20 «Сәламәтлек». 11.50 «Бөтен Россия». 12.20 «Бомонд». 12.40 Тарихи фильм: «Кутузов». 14.25 «Көзге». 15.20 «Зур узышлар». 15.50 В.Леонтьев. «Голливуд юллары буйлап». 16.10 Фильм-әкият: «Там, на неведомых дорожках». 17.20 «Хайваннар дөньясында». 18.00, 21.00 «Вакыт». 18.20 «Көлкеле манзара». Е.Петросян алып бара. 19.10 Маҗаралы фильм: «Следопыт». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 Телесериал: «Рейли — король шпионов». 22.55 «Брейн-ринг». 23.40 «Һәркемнең телендә». Н.Дарьялова алып бара. 0.10 Волейбол. Европа чемпионаты. Ир-атлар. Финал. 2.00 Телесериал: «Улицы Сан-Франциско». 2.50 Эстрада концерты: «Кара, нинди җәй!»

### «РОССИЯ»

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 — Хәбәрләр. 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30, 13.55 «Клип-антракт». 8.35 «Шөрептән башлап». 8.50 «Озынайтылган көн». 9.05 М.И.Кутузовның тууына 250 ел тулуга карата тапшыру. 9.35 «Пилигрим». 10.20 «Алтын шпор». 10.50 А.Гурнов. «Саф инглизчә репортаж». 11.00 «Ватандашлар». 11.45 Нәфис фильм: «Вечерняя школа». 14.20 «Де факто». 14.35 Нәфис фильм: «Умершая, которая убила». 15.20 Киноафиша. 15.35 «Набоков янына сәяхәт». И.Золотусскийның авторлык программасы. 16.25 «Синең мөмкинлекләрең, кеше». 16.55 Футбол. Россия чемпионаты. 18.55 Шахмат буенча дөнья беренчелегендә — Г.Каспаров — В.Ананд. 19.05 «Аншлаг һәм Кº». 20.25 Нәфис фильм: «Софи Лорен. История ее жизни» (АКШ). 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «А» программасы.

### «САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.30 «Христос — бөтен дөньяда». 8.00 «Хәерле иртә». 9.00 «Турыдан-туры элемтә». 10.00 Нәфис фильм: «Камми». 11.20 Музыкаль телефильм: «Кармен, страницы партитуры». 12.25 Минем музыка. 12.55 «Теледоктор». 13.15 Нәфис фильм: «Николай Николаевич». 13.45 Тест. 14.00 «Тарихи альманах». 14.35 Нәфис фильм: «Не болит голова у дятла». 15.45 Спектакль: «Волшебник изумрудного города». 16.35 «Музыка мизгеле». 16.45 «Әкият арты әкият». Хатларга җаваплар. 17.30 Нәфис фильм: «Приходите завтра». 23.00 Нәфис фильм: «Повелитель Демона». 0.15 «Алкышлап». Юрий Охочинский.

# ЯКШӘМБЕ

## 17 СЕНТЯБРЬ

### «ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 «Чулпан» информацион программасы. 19.00 «ТОН» (атналык телекүзәтү). 19.35 «Автокалейдоскоп». 20.00 «Әлли-бәлли-бәү». 20.10 «Күңел чишмәләре». Гариф Ахунов турында документаль фильм. 20.35 «Сандугач» җыр фестивале. 2 нче бүлек. 21.55 Тапшырулар программасы.

### «ЭФИР»

7.00 Телеэкспресс (атналык тапшыруларны кабатлау). 8.30 «Коммерция әйләнмәсе» (14 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.50 «Enter club». 9.20 «Видеогид». 9.40 «Суперспорт». 10.00 «Йозак тишеге». 10.20 «Мавыгулар дөньясы». 10.50 Мультфильм: «Конек Горбунок». 12.00 «Минем яңалыклар». А.Олейников белән. 12.20 «Чаплиниада». «Искатель приключений». 12.45 Нәфис фильм: «Солдат Иван Бровкин». 14.20 «Нью-Йорк, Нью-Йорк». 14.55 Телесериал: «Подводная «Одиссея» команды Кусто»: «Осьминог, малютка осьминог». 15.50 «Атна һәлакәтләре». 16.20 Э.Сагалаев программасы: «Кешеләр дөньясында». 17.10 «Фитиль». 17.20 Документаль фильм: «Луи Пастер» (Франция). 17.50 Телесериал: «Тропическая жара». 18.45 Телесериал: «Детективы на полставки». 19.45 «КиноМеню». 20.15 «Җирле вакыт». Информацион программа. 20.45 Питер Фалк, Джилл Клэйбург «Гриффин и Феникс: история любви» фильмында. 22.30 «Исәнмесез!» (16 сентябрь тапшыруын кабатлау).

### 1 НЧЕ КАНАЛ

7.30 «Иртә». 9.00, 0.35 Яңалыклар. 9.20 «Иртә таннан». 9.50 Мультфильм: «Найда». 10.10 «Бар да өйдә чакта». 10.45 «Иртәнге йолдыз». 11.30 «Россиягә хезмәт итәм». Полигон. 12.00 Телесериал: «Лики Земли». 12.35 Мультфильм. 12.55 Хоккей. МХЛ чемпионаты. 12.30 «Зур театр. Көннәр һәм кичләр». 16.20 «Сәяхәтчеләр клубы». 17.05 «Европага тәрәзә». Д.Киселев алып бара. 17.35 Мультсериал: «Приключения капитана Врунгеля». 18.00 Вакыт. 18.20 «Көмеш шар». Т.Доронина. 19.05 «Күзгә-күз». А.Любимов алып бара. 19.30 «Кумирлар, кумирлар...» И.Понаровская. 20.05 «КВН-95». Чемпионнар кубогы. 22.00 «Якшәмбе». 22.50 «Спорт яңалыклары». 23.05 Телесериал: «Рейли — король шпионов». 0.00 «Бер күрүдә ярату». 0.55 Телефильм: «Стакан воды».

### «РОССИЯ»

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 Хәбәрләр. 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 Документаль фильм: «Дело жизни Ивана Цветаева». 9.50 «Беренче дубль». 9.05 «Алтын ачкыч». 9.20 «Футболга чикләр юк». 10.05 «Хәерле иртә, Европа». 10.35 «Аты, баты...» 11.05 «Консолидация». 11.10 «Рус лотосы». 11.55 Шахмат буенча дөнья беренчелегендә. Г.Каспаров — В.Ананд. 12.15 Фильмнарны кабат күрсәтү кинотеатры. «Две стрелы». 17.45 К.Мажейка. «Параллельләр». 14.20 «Кисеп бетерә алмаслык...» 14.35 Нәфис фильм: «Умершая, которая убила». 15.25 «Беренче нөсхә». 15.35 «Тайны животных» телесериалыннан документаль фильм: «Гигантская выдра» (Бөекбритания). 16.30 «Кайнар уңлык». 17.25 «Веди». 18.00 Мультфильмнар: «Чокнутый», «Новые приключения Винни Пуха». 18.55 Шарман-шоу. 20.25 Нәфис фильм: «Джамиля». 22.00 «Кеюшада кунакта». 22.30 «Тапшырулар тартмасы». 22.45 Өлкәннәр өчен мультфильм: «Контакты... конфликты». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «Тулы ай».

### «САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Бу сезнең көнегез». 7.30 «Шифалы сүз». 8.00 «Хәерле иртә». 9.00 «Турыдан-туры элемтә». 10.00 Мультфильм. 10.20 Нәфис фильм: «Черная кобра». 11.50 Музыка мизгеле. 12.00 «Якшәмбе лабиринты». 13.10 Нәфис фильм: «Групповой портрет с Кижами». 14.00 «Страсти-мордасти». 14.30 «Классика-5». «Осталыкка ирешү». 15.30 Депутатларга сүз бирәбез. 16.00 Спектакль: «Волшебник изумрудного города». 17.00 «Алтын ачкыч». 17.15 «Ыргыт, әйдә». 17.55 Футбол буенча Италия чемпионаты. 22,15 «Адәм алмасы». 23.15 ТВ мәгълүматлары. 23.35 «Рок риваятьләре: Даяна Росс. Леди җырлый».

## ДҮШӘМБЕ, 11 СЕНТЯБРЬ

6.00, 19.15 Соңгы хәбәрләр. 6.15 Иртәнге дулкында. 6.53, 7.58 Һава торышы. 6.55, 7.50 Белдерүләр. 7.00 Информацион-музыкаль программа. 7.45, 20.38 Тапшырулар программасы. 8.00, 18.30, 20,45 Радио-1. 17.45 «Уйныйбыз да, җырлыйбыз да...» 18.15 «Дүшәмбедән — дүшәмбегә». Мәдәният яңалыклары. 19.45 «Алабугам — ак җырым». Шәһәр Техника йортының «Рәйхан» халык ансамбле.

## СИШӘМБЕ, 12 СЕНТЯБРЬ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 Һава торышы. 6.55, 7.50 Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25 Тапшырулар программасы. 8.00, 14.30, 18.30 20.45 Радио-1. 12.25—14.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 Башкортстан артистлары концерты. 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 13.30 «Юллар чатында» информацион программасы. 13.45 «Турыдан-туры элемтә». 17.45 «Яшьлек» студиясе. 18.15 «Көн темаларына». Әңгәмәләр, аңлатмалар. 19.45 Б.Мулюков җырлары һәм инструменталь пьесалары.

## ЧӘРШӘМБЕ, 13 СЕНТЯБРЬ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Татарстан дулкынында». 6.53, 7.58, 13.25, 20.53 Һава торышы. 6.55, 7.50 Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.53 Тапшырулар программасы. 8.00, 13.30, 18.30, 21.00 Радио-1. 12.30 Концерт. «Без Татарстан җирендә яшибез». 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 18.00 «Кеше һәм закон». 19.45 Сораулар буенча концерт.

## ПӘНҖЕШӘМБЕ, 14 СЕНТЯБРЬ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.53, 7.58, 13.25 Һава торышы. 6.55, 7.50 Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25 Тапшырулар программасы. 8.00, 14.30, 21.45 Радио-1. 12.25—14.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 «Балалар җырлый». 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 13.30 «Туры эфирда диалог». 17.45 «Казан һәм казанлылар». 19.40 Җ.Фәйзи. «Башмагым» музыкаль комедиясе (трансляция буенча язып алынган).

## ҖОМГА, 15 СЕНТЯБРЬ

6.00 «Балкыш». 6.43, 20.30 — Татарча өйрәнәбез. 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 Һава торышы. 6.55, 7.50 Белдерүләр. 7.00, 13.05, 19.15 «Соңгы хәбәрләр». 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.38 Тапшырулар программасы. 8.00, 13.30, 18.30, 20.45 Радио-1. 12.25—13.30 «Көн үзәге» информацион нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 Ә.Шәрәфиев әсәрләре. 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 18.00 «Чишмәләр» (чуваш телендә). 19.45 Т.Гыйззәт шигырьләренә язылган арияләр һәм җырлар.

## ШИМБӘ, 16 СЕНТЯБРЬ

6.00, 7.00 Соңгы хәбәрләр. 6.15 Авыл эшчәннәре өчен концерт. 6.58, 7.58, 14.30 Һава торышы. 7.15 Иртәнге концерт. 7.45, 14.30 Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 8.00, 11.00, 14.35 Радио-1. 8.15 «Сезнең хатларыгыз». 8.40 «Көмеш кыңгырау». 9.00 «Хәзинәләр эзләгәндә». Язучы Гариф Ахуновның 70 еллыгына карата. 9.30 «Еллар һәм юллар». Язучы А.Расихка 80 яшь. «Каһәр суккан тел». А.Расих хикәясе буенча радиокомпозиция. 10.30 «Танышу». 11.45 «Кардәшлеккә чикләр юк». 12.15 Татар халык көйләре. 13.10 Яңалыклар эстафетасы. 13.30 «Яшьлек» студиясе. 14.00 «Әбугалисина» клубы.

## ЯКШӘМБЕ, 17 СЕНТЯБРЬ

7.00, 7.58, 13.40 Һава торышы. 7.04 «Хәерле иртә!» 7.45, 13.40 Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 8.00 «Идел белән Урал арасында». Алты республиканың берләштерелгән радиожурналы. 9.00 «Табигать дуслары». 9.30 «Гасырларны бәйләүче җеп». 11.45 «Изгелек һәм яктылыкны каршылап». Өлкәннәр һәм балалар өчен программа. 12.15 «Тел күрке — сүз». 12.45 Саба урман хуҗалыгы эшчәннәренә багышланган информацион-музыкаль программа. 13.45 «Татарстан дулкынында». 14.25 А.Расих. «Юллар аерылганда». Роман буенча радиоспектакль. 16.00 Радио-1.

# Вахиттә — академиклар җыены

**_Кукмара районының Вахит авылында Татарстанда Халыкара информатизация академиясенең оешуына 2 ел, Берләшкән Милләтләр Оешмасының 50 еллыгына багышлап, академиянең күчмә утырышы уздырылды. Анда катнашу өчен илебезнең төрле төбәкләреннән, чит илләрдән уннан артык академик килгән иде. Халыкара «Планетаны яңарту» ассоциациясе вице-президенты Рәфикъ Миңнекәевләр өендә башланып киткән бу утырыш Сабан туе булып дәвам итте._**

Һәр бәйрәм кунаклар каршылаудан башлана. Традицион булмаган медицина үзәге урнашкан Вахит авылындагы Рәфикъ Миңнекәевләр өендә дә мыгы-зыгы иртән үк башланып китте. Татар халкының күркәм гадәтенчә, капкалар, ишекләр киң итеп ачып куелды, мичкә бәлешләр тыгылды, өстәл янында кызлар-ханымнар кайнашты.

Югославиядән килгән «Белмос» концерны президенты Милан Зец әфәнде, Халыкара информатизация академиясе академигы, Советлар Союзы Каһарманы, Русия Кораллы Көчләрсен Генераль штабы кинәшчесе, өч сугыш зилзиләсе аша узган Федор Чураков, Татарстан информатизация академиясе президенты, профессор Альберт Бикмуллин һәм башка академикларны, Мәскәүдән, Пермьнән, Уфадан килгән кунакларны күпереп пешкән күмәч, тоз белән каршы алганнан соң, Миңлебай абыйлар (Рәфикъ Миңнекәевнең әтисе) өендә академиянең күчмә утырышы башланып китте.

Казанда информатизация академиясе Халыкара информатизация академиясе президиумы карары белән төзелә. Академия ике ел эчендә халыкара фәнни һәм эшлекле даирәдә абруй яуларга өлгерде, үз тирәсенә әйдәп баручы галимнәрне, белгечләрне, дәүләт эшлеклеләрен, Татарстанның, Русиянең, чит илләрнең күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклеләрен, фәнни-тикшеренү структурасы җитәкчеләрен туплады.

Республикабыз Президенты Минтимер Шәймиевнең Татарстанда информатизацияне үстерүгә керткән өлеше, төбәктә сәяси тотрыклылыкны тәэмин итү буенча дәүләти эшчәнлеге узган ел Халыкара информатизация академиясенең халыкара бүләге һәм Алтын медале белән билгеләп үтелде.

Президиум һәм академия әгъзалары республикабыз предприятиеләре һәм оешмалары, чит илләрнең фәнни, икътисадый, житештерү һәм коммерция структуралары белән тәҗрибә уртаклашуда, яңа фәнни казанышларны һәм яңа мәгълүмат технологиясен кертүдә халыкара хезмәттәшлекне үз элемтәләре аша киңәйтәләр. Академиянең эше информацион-күзәнәкле принципка корылган. Бу тикшеренү нәтиҗәләре белән файдалану мөмкинлеген арттыра, күркәм нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә.

— Татарстан информатизация академиясен Русиянең күп төбәкләрендә беләләр, — диде ТР информатизация академиясе әгъзасы, медицина фәннәре докторы, Мәскәүдән килгән Юрий Новиков. — Бу — академия президенты, профессор Альберт Бикмуллин җитәкләгән статистика-мәгълүмат системасы институтына да кагыла. Биредә заманча информатизациянең мөһим проблемаларыннан берсе — яңа информацион технология эшләү белән шөгыльләнәләр. Кайбер күркәм нәтиҗәләр дә бар инде. Хәзерге вакытта Идел буе төбәге һәм Мәскәү дәүләт статистика комитетлары институтларында казанлылар методикасы буенча эшлиләр.

Ю.Новиков астма, пневмония, яман шеш авыруларына каршы медицина препаратлары җитештерү технологиясен тәкъдим иткән ТР информатизация академиясе әгъза-мөхбире Александр Лиакумовичның һәм традицион булмаган медицина өлкәсендә эшләүче Рәфикъ Миңнекәевнең эшчәнлеген аеруча билгеләп үтте.

Утырышта әлеге бәйрәм тантанасының мөхтәрәм кунагы Милан Зец әфәндегә, ул җитәкләгән концерн эшчәнлегенә аерым игътибар булды.

Концерн җитәкчесе Милан Зец әфәнденең сүзләренә караганда, алар безнең республикабыз белән берлектә биш программа — конверсион, агропромышленность, төзелеш, белем бирү, нефть чыгу кимегән урыннарны яңарту буенча эшләргә ниятлиләр.

— Хәзер иң мөһиме — Татарстан Республикасына чит ил капиталын кертү, — дип белдерде Милан Зец әфәнде. — Русиянең үзәгендә урнашкан Татарстанның башка төбәкләрдән өстенлеге бәхәссез. Хәзер барлык көчне кыска гына вакыт эчендә тулаем милли табышны арттыру программасын тормышка ашыруга юнәлдерергә кирәк. Конверсион программалар булдыру һәм кадрлар әзерләү халыкара бизнес өчен бик тә кирәк.

Утырышның ахырында «Белмос» концерны президенты Милан Зец әфәндегә, Мәскәү өлкәсендәге «Правда» санаторие директоры Игорь Андреевка, икътисад фәннәре докторы Елена Ермакка, «Планетаны яңарту» ассоциациясе вице-президенты Рәфикъ Миңнекәевкә Халыкара информатизация академиясе әгъзалары булулары турында диплом һәм таныклыклар тапшырылды.

* * *

Вахитов исемендәге күмәк хуҗалык 500гә якын шәхси хуҗалыкны берләштерә. Әмма, чәчүлек җирләре шактый зур (2700 гектар) булса да, кырлардагы чисталык һәм пөхтәлеккә — сокланырлык. Эскертләр матур итеп бер рәткә тезеп салынган, кырларның ямен җибәреп, тиешсез урында яткан бер сәнәк салам күрмәссен.

Авылда шәхси хуҗалыкларның эшләре дә гөрләп бара кебек. Халыкка хезмәт хакы да үз вакытында диярлек бирелеп барыла икән. Шәхси йортлар янындагы терлек абзарларының да күбесе кирпечтән салынган. Байтак өйләр янында гаражлар күренә. Болар барысы да биредә уңган, булган һәм тырыш, эшчән кешеләр яшәве турында сөйли түгелме соң?

Вахиттә һәр кешенең үз шөгыле, мавыгуы бар. Күмәк хуҗалык эшләреннән бушап торган арада да алар кул кушырып утырмыйлар. Кышкы озын кичләрдә һәр йортта эш гөрли: кемдер итек баса, яисә тун, бүрек тегә, кемдер шәл бәйли, тире или, күн ясый. Мул тормыш белән яшәү, хуҗалыктагы тәртип, муллык Вахит авылы кешеләренең холкында да чагыла кебек. Бөтен тирә-як авылларны үзенә җыйган Сабантуйда азып-тузып, эчеп-исереп, мәгънәсезгә бәйләнеп йөрүчеләрне бөтенләй дә күрмәдек.

... Сабантуйга килгән халык чын күңелдән бәйрәм итә: Юнир Салаватов җитәкчелегендә Башкортстаннан махсус килгән җырчылар, биючеләр концертын тыңлый-тыңлый, көч бирә-бирә, пәһлевандай көчле егетләрнең бил алышканын карый, ат чабышыннан килүчеләрне сәламли, тауга каршы җилдәй җитез йөгереп менүчеләргә карап тел шартлата...

**Сөембикә КАШАПОВА.**

# Диңгез кайда да диңгез



**«Идел» күргәзмәләр залында ачылган, балаларның — яшь рәссамнарның иҗат җимешеннән торган бу гаҗәеп күргәзмә республикабыз мөстәкыйльлеге көненә багышланган иде.**

**Ә инде 1 сентябрьдә күргәзмәне карарга Казандагы 8 нче гимназия укучылары һәм дә «Уленшпигель» ансамбле артистлары килгән иде. Чыннан да, рәсем белән җыр бергә кушылса — гаҗәеп бер күренеш була икән. Балалар җырга да кушылды, диңгез булып та шаулады-дулкынланды. Кыскасы, күңелдә иң матур, дулкынландыргыч хисләр-төсмерләр калды...**

**Әкрам ШАФИГУЛЛИН.**
Автор фотолары.



И ГЪТИБАР: КӨНДӘЛЕК МАТБУГАТКА ЯЗЫЛУ БАШЛАНА

# Көзнең бер көне ... ел туйдыра

*Мөхтәрәм җәмәгать, газета укучылар! Тагын берничә көннән 1996 ел өчен газета һәм журналларга язылу башлана. Сезгә хәбәр итәргә ашыгабыз: үткәннәреннән аермалы буларак, быел көндәлек матбугатка ярты елга түгел, ә еллык подписка игълан ителәчәк. Мәгълүм булганча, әлеге алым, әйтик, күрше Башкортстанда инде берничә ел кулланыла, һәм мондый тәҗрибәнең уңай яклары шактый. Беренчедән, язгы фасыл белән чагыштырганда, көз муллыклырак вакыт, кешеләрнең кулына азмы-күпме акча керә торган чак һәм кеше-төне эштән бушамаган авыл хезмәтчәннәренең, ниһаять, билен турайтырга, тормышның башка ихтыяҗлары, рухи азык турында кайгыртырга җай чыккан айлары. Берьюлы унике айга килешү төзүнең икенче уңай ягы шуннан гыйбарәт: әгәр көзен яраткан басмаңа язылсаң, ул ел буе өеңә килеп торачак. Җаның тыныч. Өстәвенә, син әле отышлы каласың, чөнки подписка бәясе, илдә бара торган инфляция аркасында, берничә айдан артырга да мөмкин. Ә менә ел буена язылган мөштәриләрдән инде өстәмә акча сорап җөдәтмәячәкләр. Менә бит ул еллык подписканың уңай яклары!*

*Әлбәттә, элекке еллар тәҗрибәгенә кайту газета укучыларыбызның теләк-ихтыярын кысу булып чыкмасын. Әгәр басмабызга ярты елга гына язылырга телисез икән, рәхим итегез, андый мөмкинлек тә каралган. Әмма болай иткәндә, әлеге дә баягы, подписка бәясе кыйммәткәрәк төшәргә мөмкин. Аннары кабат-кабат язылу шактый мәшәкатьле.*

*Бәя, дигәннән, шуны игътибарга алсагыз иде: һәр атнаның җомга көнендә 24 битле булып чыга торган «Мәдәни җомга» газетасының еллык бәясе иң арзаннардан санала: нибары 36 мең. Ә бер саны 750 сумга гына төшә. Дөресен генә әйткәндә, бүгенге көндә 750 сумга базардан 1 килограмм шалкан да алып булмый.*

*«Мәдәни җомга» атналык газетасы «Роспечать» акционерлык җәмгыяте бастырып чыгарган каталогка да кертелде. Димәк, безнең басмага җөмһүриятебездән читтәге төбәкләрдә дә язылырга мөмкин. Русия Федерациясендә подписка 1 сентябрьдән 1 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк. Ә Татарстанда аның сроклары 15 сентябрьдән 15 декабрьгәчә билгеләнә.*

*Хөрмәтле укучыларыбыз! Искәртмәделәр, дип, соңыннан безгә үпкәләмәгез. Тиздән, бик тиздән киләсе ел өчен көндәлек матбугатка язылу башлана.*

*Исегезгә төшерәбез:*

***«Мәдәни җомга» газетасының индексы — 54129. Еллык язылу бәясе — 36 мең.***

*Әгәр подписка дәвамында бер карарга килеп, әлеге яңа басмага язылсагыз, ышандырып әйтәбез: көзнең бер көне ...ел туйдырыр, ягъни рухи ельязма булырлык атналык газетадан өзлексез рухи азык алырсыз, киң җәмәгатьчелектә яратып кабул ителгән «Мәдәни җомга» унике ай дәвамында өегезне нурландырып торыр.*

К ЫЗ ЙОЛДЫЗЛЫГЫ АСТЫНДА ТУГАННАР

## КОТЛЫЙБЫЗ!

**8 сентябрь**

**Зарипов** Максуд Мөхәммәтҗан улы Россия Фәннәр академиясенең Казан Фәнни үзәге физика-техника институты лаборатория мөдире, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе әгъза-мөхбире, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе.

**Үзбәкова** Разия Әнвәр кызы – М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры солисты.

**9 сентябрь**

**Мишкина** Вера Егоровна – Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты, Татарстанның һәм РФнең халык артисты.

**10 сентябрь**

**Горбатов** Иван Николаевич — Әлмәт драма театры артисты.

**Песошин** Валерий Андреевич – Казан техника университетының кафедра мөдире, профессор. Татарстан Фәннәр академиясе әгъза-мөхбире.

**12 сентябрь**

**Иванов** Виктор Алексеевич – Казан технология университетының кафедра мөдире, профессор, Татарстанның атказанган фән һәм техника эшлеклесе, Татарстан Фәннәр академиясе әгъза-мөхбире

**Муллагалиев** Сафуан Галәветдин улы – шагыйрь.

**Хәйруллин** Хәниф Гыйздулла улы – язучы.

**Хәйруллина** Роза Вакыйф кызы – Казан Яшьләр театры артисты. Татарстанның атказанган артисты.

**13 сентябрь**

**Шәрифуллин** Шамил Ками[illegible] улы композитор.

**14 сентябрь**

**Йосыпов** Рүзәл Габдуллаҗан улы – Казан дәүләт педагогия университеты ректоры, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе әгъза-мөхбире, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе.

Т АШ ЕЛАТЫРЛЫК СҮЗ

## Өзәләр бит у үзәкне!

Әйе, өзәләр. Башланган эшне өзәләр. Үзәкне өзәләр! «Русия Фәннәр академиясенең Казан фәнни узәге» дип, «ү»не «у»га бутап язалар да, аннары без — академиклар, дип мактаналар. Татар теленең дәүләт геле булуын бәгъзе академикларыбыз шулайрак аңлый, күрәсең.

Ү З ИЛЕМ — АЛТЫН БИШЕК

# Татарстан гөлләре

«Казан» милли-мәдәният үзәге сәнгать сөючеләрне шул исемдәге күргәзмәне карарга чакыра.

Аны икенче төрле «Татарстан натюрморты» дип тә атарга мөмкин булыр иде. Чөнки монда җөмһүриятебездә иҗат итүче күп кенә танылган рәссамнарыбызның шушы жанрда ясалган картиналары урын алган.

Монда өлкән буын рәссамнарыннан «тын табигатьне» сурәтләү осталары Евгений Зуев, Кондрат Максимов, Сергей Неустроев әсәрләре белән танышырга мөмкин. Илдар Зарипов, гадәттәгечә, үзенең төрледән-төрле натюрмортлары белән катнаша.

Казаннан Александр Дорофеев, Алабугадан Рәбис Сәләховлар гаҗәеп үзенчәлекле, фәлсәфи картиналары белән үзләренә игътибарны җәлеп итә.

Экспозициядә Чаллы рәссамнары шактый урын алып тора.

Аларның берсе – Виктор Анютин. Аның «Шайтан таягы», «Юл чатындагы йорт» h.б. пейзаж-натюрмортлары хыялга, фәлсәфәгә корылган.

Хәмзә Шәриповны Чаллыда батик тукымага төсле рәсем төшерү остасы буларак беләләр. Аның иҗаты милли бизәккә, орнаментка заманча карашы белән аерылып тора.

Күргәзмәдә шулай ук һөнәрчелек сәнгате үрнәкләре дә бар. Бу, беренче чиратта, Светлана Гарбузованың күннән эшләнгән бик матур композицияләре.

Ә Чаллы рәссамы Земфира Бикташева халык иҗатында гасырлар буе яшәгән чигү, каю, бизәү алымнарын өйрәнеп һәм үзләштереп, иҗатында гаҗәеп гүзәл образлар тудыра.

Аның «Сөембикә» дигән панносын күргәзмәнең йөзек кашы дип әйтергә була.

**Рауза СОЛТАНОВА,**
«Казан» милли-мәдәният үзәге фәнни хезмәткәре

*Бу санда Эрот Зарипов (1, 8, 16 нчы битләр), Айдар Үтәганов, Ринат Хәсәншин, Әнәс Әмирханов рәсемнәре, Әсрар Шакирҗанов, Әкрям Шәфигуллин төшергән һәм авторларның шәхси архивыннан алган фотолар файдаланылды.*

Татарстан Язучылар берлеге һәм Чаллы язучылар оешмасы, Түбән Камада яшәп иҗат иткән шагыйрь **Мизхәт Хәбибуллинның** (Мизхәт Гиндулла улы Гиндуллин) вакытсыз вафат булуын белдереп гаиләсе һәм туганнарының тирән кайгысын уртаклашалар.



Мәдәни ҖОМГА
Татарстан Республикас[ы]
Мәгълүмат
һәм матбугат,
Мәдәният
министрлыклары
химаясендә чыгарыла

Баш мөхәррир
Зиннур
МАНСУРОВ

Баш мөхәррир урынбасарлар[ы]
Газинур МОРАТ,
Миншәех ЗӘБИРОВ

Җаваплы сәркатип
Альберт САБИРОВ

Телефоннар:
32-41-79 — кабул итү бүлмәсе;
32-45-78, 32-06-76 — баш мөхәррир урынбасарлар[ы]
32-57-36 — җаваплы сәркатип;
32-57-76 — җаваплы сәркатип урынбасарлар[ы]
32-62-79 — публицистика, очерк, сәясәт бүлеге
32-58-91, 32-68-22 — әдәбият бүлеге;
32-60-11 — сәнгать бүлеге;
32-12-08 — тәнкыйть, фән, тарих бүлеге
32-62-79 — мәдәният яңалыклары, мәгълүмат, тәрҗемә бүлеге
32-59-55 — халык тормышы, рухиятне як[лау]
32-69-54 — хатлар бүлеге;
32-66-28, 32-59-22 — рәссамнар
32-69-26 — фотохәбәрче;
32-57-94 — бухгалтерия.

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк бу[лмаска] да мөмкин

Хатлар, кульязмалар, фото[графияләр], рәсемнәргә бә[я] бирелми һәм алар кайтарылмый

Газетада басылган язмалар[ы], фотографияләрне файда[ланганда], шулай ук өземтәл[әр] китергәндә, «Мәдәни җомга»дан алынганлыгын [күрсәтү] мәҗбүри

Реклама урнаштыру өчен [гаризалар] кабул ителә

Реклама һәм белдерүләрнең [эчтәлеге] өчен реклама бир[үчеләр] үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме [күрсәтергә] теләүчеләр өчен р[едакциянең] исәп-хисап счет[ы]
609403 МФО 265566
в Бауманском отд. ПСБ

Газета
Татарстан Республикас[ы]
Мәгълүмат һәм матбуга[т]
министрлыгында
428 нче таныклык белән
теркәлдә

Индекс — 5412[9]

Редакция адресы:
420503, Казан,
Бауман урамы, 19

Нәшрият адресы:
420066, Казан,
Декабристлар урамы, 2

Басмаханә гаебе белән [...]
бәрелгән сыйфат җитешсез[...]
кларе уңаеннан 49-36-62 но[мерлы]
телефон буенча шалты[...]
тырга

Газета редакциянең комп[ью]
тер үзәгендә эшләнде

Газетаның сатулары
бәясе килешү буенча

Татарстан газета һәм
журналлар нәшрияты
басмаханәсе

Тираж 8000
Заказ 4456